7
июль 2021
ISSN:2500-011X

# Безнең Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

## «Күңелем иркәсе булган авыл кызлары»
*50 бит*

## Мәхәббәт тоткыны
*61 бит*

ШӘЙХИ МАННУР ХАТЫНЫ ТӘГЪЗИМӘ ХАНЫМ БЕЛӘН

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +

7
(331)
**июль 2021**

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

16

*Баш мөхәррир*
**Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)**
(843) 222-09-83 (17-92)

*Баш мөхәррир урынбасары*
**Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)**
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

**Ирада Әюпова**
*(ТРның мәдәният министры)*
**Айрат Зарипов**
*(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)*
**Айдар Сәлимгәрәев**
*(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)*
**Васил Шәйхразиев**
*(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)*

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рузәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

*Җаваплы мөхәррир*
**Ленар Гобәйдуллин**
89196911406

*Дизайнер һәм битлә салучы*
**Алмаз Фәйзуллин**
(843) 222-09-83 (17-92)

*Мөхәррир*
**Ләйсән Данилова**
(843) 222-09-83 (17-91)

*Сайт мөхәррире һәм корректор*
**Энҗе Хөсәенова**
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)**
**Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал**
**(на татарском и русском языках)**

# Эчтәлек

**ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...**

3 Шәехзадә Бабич

**ТАРИХИ МИРАС**

4 Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге. *Руи Гонсалес де Клавихо*
8 Яңавыл (Ирнур) – Мари Илендәге татар авылы. *Ф.Мусин*
16 Татар көймәсе. *Н.Гариф*
18 Кем ул Тогайка Беляков? *Р.Мәрданов*
26 Садри Максуди: «Фәкыйрь булмыйк, бетәрбез!» *М.Гайнанова*
32 Мамадыш җырулары. *Г.Дувалова*
34 Владимирда Василий Тимофеев эзләре. *Л.Пасыева*
37 Ижау каласын ямьләгән якташыбыз. *Р.Муллахмәтова*
41 Аның тырышлыгы белән тоткыннар азат ителгән. *Н.Михайлов*

**Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.**
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

**«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.**

44 Коточкыч ачлык. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
48 Зәйтүнә Мәүлүдованың кабер ташы. *А.Гайнетдинов*
50 «Күңелем иркәсе булган авыл кызлары». *М.Фәйзи*

## ТАТАР ГАМЕ

56 Бабичның беренче адымнары. *Г.Толымбай*
61 Мәхәббәт тоткыны *Ш.Бабич*
62 Хөррият бүләге *Ш.Бабич*
63 «Безнең мирас» котлый!
64 Чын халык шагыйре *Р.Шәрәфиева*
66 Шәехзадә Бабич музее

## ДИНИ МИРАС

68 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
74 Ризаэддин Фәхреддин милләтләр үсеше турында. *Л.Байбулатова*
76 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

## ӘДӘБИ МИРАС

78 Әхмәд Ләбиб Каран (1887-1964) шигырьләре
82 Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә. *Г.Утыз-Имәни*
88 Тәңре юлында. *Т.Галиуллин*
90 Мамадыш шагыйре
92 Тугры Шәйхи шигырьләре

## ХӘТЕР САНДЫГЫ

94 Мамадышның мәшһүр рәисләре. *Р.Хәйруллин*
98 Сүз һәм сурәт
102 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
104 Истә, һаман да истә!

## СӘНГАТИ МИРАС

106 «Ярмәк вагы». *И.Диндаров*
108 Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*
110 «Хәмдия» җыры

## ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

## БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Июль*

Заказ №Е-2236. Тираж – 2890 данә. Формат 70x100 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 25.06.2021. Чыгу көне: 01.07.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Шәйхи Маннур хатыны Тәгъзимә ханым белән

*Шагыйрь булсаң — ялындырмый җырлау яхшы,*
*Милләт чирен җырлый-җырлый чирләү яхшы.*

*Шәехзадә Бабич*

***Ш.Бабич (уртада), артта – В.Хангилдин һәм И.Мостафин. Уфа, 1916 ел***

# ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ
(14.01.1895-28.03.1919)

***

Бетә тиз дөнья малы, мәңге тормый,
Белем бетми, юылмый һәм дә черми.

***

И китап! Мин аңгыраны
төз юлга күндерсәнә!
Мине баскан «җәһел»* утын
су сибеп сүндерсәнә!
Мин – юаткыч, син – уяткыч,
син миңа чын-чын атам;
Булмасаң син, мин сине
сагынып кына чирләп ятам.

***

Зәңгәр күк – таҗым, чуар җир – тәхтем,
Үзем – азат хан, ак кояш – бәхтем...
Йолдызлар һәм ай – серче дусларым,
Сандугач, тургай – җырчы кошларым.

***

Һич кайгырма, шатлан әүвәлгечә!
Бәхет җиңәр әле, иншалла;
Җәһәннәмнәр аша узмаенча,
Оҗмах табарбыз дип ышанма!..

***

Нәфес – шайтан, бик явыз ул,
һәр адәмне аздыра,
Аздыра торгач, наданнарны
юлыннан яздыра.
Әмма аннан да явыз бер
нәрсә бар: ул – эчкечелек,
Ул халыкны йорт-җиреннән
һәм диненнән яздыра.

***

Ике нәрсә: әүвәл Алла, икенче кыз
Бәндәләрне кодрәтенә табындырган.

***

Һәркайчан тик тор,
берәр ахмак сүз сөйләсә,
Бел, аңа артык сүз кайтарудан
тик тору артык ләса.

***

Ярсынмаса күкрәк яшьнәп-күкрәп,
Телләрендә ялкын яналмый,
Аһ ормасаң сыкрап, тетрәп-тетрәп,
Кулларыңнан алтын тамалмый.

*Текстны журналга*
***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

** Җәһел – наданлык.*

# Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1403-1406) көндәлеге

Руи Гонсалес де Клавихо

Ахыры. Башы журналның 2 нче (2021) санында.

Хәзер инде Сәмәрканд, илчеләр язмышы, бәк белән ни булып беткәнен тәфсилләгәннән соң, Тарталия ханы Туктамышны, – бу гаярь һәм данлыклы хан төрекнең Баязидыннан күпкә көчлерәк, – Тимербәкнең тар-мар итүе, буйсындырылган Тарталиядә Идегәй дигән ир-егетнең калкуы һәм бүгенге көндә Тимербәк өчен шул Идегәйдән дә зуррак дошман юклыгы хакында сөйлим.

Моннан унбер еллар элек күп җирләрне, төрле халыкларны үзенә буйсындырган Тарталия ханы Туктамыш Фарсы иленә яу чыга, Тәбризне һәм Әрмәнстанның өске өлешен басып ала, шәһәрләрен утка тота, талый, кальгаларын җимертә. Испан илчеләре сугыш узган урыннарны карап үттеләр: әрмән җирендәге Сюрмари, Сисакан калаларын, тагын күп җирләрне үз күзләре белән күрделәр. Тимербәк карамагындагы җирләрне дер селкетеп чыккан Туктамыш үзенең Тарталиясенә әйләнеп кайтырга чыга. Бу хәбәрне ишеткән Тимербәк тиз генә гаскәрен туплый, Терек елгасы буенда Туктамышның эзенә баса. Туктамыш гаскәре елганың бердәнбер кичү урыныннан аргы ярга чыгып өлгерә. Кичү урынына агачлар аударып, сак гаскәре куя.

Тимербәк, килеп җиткәч, күрә: кичү урыны Туктамыш кулында. Шунда ул ханга үзенең һич тә сугышырга теләмәвен, аны элеккечә дус итеп күрүен һәм аңа бернинди дә явызлык кылмаячагын белдерә. Шуңа да карамастан, Туктамыш барыбер шикләнә, бәкнең мәкерле икәнен белә.

Икенче көнне Тимербәк гаскәрен елганың югаргы агымына таба кузгата, Туктамыш хан да кузгала. Елганың ике ярыннан гаскәр агыла, бер як тукталса, икенче як та туктый. Шушылай күзгә-күз карашып алар өч көн буена баралар. Бер як та алга да китми, артка да калмый. Өченче төндә Тимербәк бөтен хатын-кызларга да хәрби кием киеп, ирләр кыяфәтенә керергә боера. Ә инде яугирләр, һәрберсе икешәр ат алып, артка таба зур тизлектә чаптырырга тиеш булалар. Ирләр кыяфәтенә кергән хатын-кызларны, әсирләрне, колларны ыстанында калдырып, Тимербәк үзе дә кичү урынына әйләнеп кайта. Өч көн үткән юлны бер төндә үтеп, алар кичүдән аргы ярга чыгалар. Шулай итеп, өч сәгать эчендә Туктамыш гаскәренең язмышы хәл ителә, яу кырыннан ул үзе качып китә. Аның бөтен байлыгы төялгән йөкләр Тимербәк кулына күчә. Чагыштырмача азрак санлы гаскәре белән җиңү яулаган Тимербәк өчен бу сугыш төрекләрне җиңүгә караганда да әһәмиятлерәк, данлырак орышларның берсе була. Җиңелү Туктамышның намусына тия, ул, тагын зур чирү туплап, Тимербәккә каршы яуга әзерләнә. Әлеге җиңелүдән соң, татарлар сынып калалар; ханга ышанычлары кими, үзара низаглар башлана. Шушындый болгавыр халәттән файдаланып, кайчандыр Туктамышка хезмәт иткән Идегәй исемле морза калкып чыга. Тимербәккә, бөтен дошманнарга каршы торырлык көч туплый башлый. Тимербәкне җиңгән очракта ул бөтен Тарталия җирләренә хуҗа булырга омтыла. Тимербәк аны эзәрлекләп бара, әмма Идегәй качып котыла. Бәкнең хәтәр дошманына әверелгән Идегәй урдасында ике йөз мең атлы яугир туплана.

Ул арада Тарталия ханы Туктамыш белән Тимербәк, үзара килешеп, Идегәйне хәйләле тозакка каптырырга сүз куешалар. Тимербәк, аны (Идегәйне. – *Тәрҗ. иск.*) яратуын, бөтен гөнаһларын да кичерәчәген, тату-дуслык урнаштырачагын, туганлыкны ныгыту өчен, үзенең бер оныгын аның кызына өйләндерәчәген әйтеп, хәбәр җибәртә. Сөйләүләренә караганда, Идегәй аңа мондый җавап биргән, имеш: «Синең катыңда мин егерме ел яшәдем, иң ышанычлы зат итеп

санадым, мин синең бөтен хәйләләреңнең дә асылын яхшы беләм, юмакайлык белән генә мине алдый алмассың, әшнәлекне без сугыш кырында кылычка-кылыч килеп кенә яулый алачакбыз». Менә шулай дип җавап бирә ул аңа.

Идегәйдән качып, Туктамыш хан үзе Сәмәркандка якын урынга килеп төпләнә, ә улы Генуя каласы Кафага китә. Идегәй, аның эзенә төшеп, Кафага һөҗүм оештыра, Туктамышның улы, аннан качып китеп, Тимербәккә килеп сыена. Туктамыш һәм аның уллары исән, алар Тимербәк белән якын мөнәсәбәттә иделәр. Ә бу, Идегәй дигәне, бернинди дә дин тотмаган татарларны Мөхәммәд (с.г.в.) диненә дүндереп бара. [...]

Тимербәк Сәмәркандта дөнья куйгач (Тимербәк 1405 елның 18 февралендә Отрарда үлә. – *Тәрҗ.иск.*), аның яраннары, якыннары, мәмләкәтне, казна эшләрен тәртипкә китерми торып, бу кайгылы хәбәрне халыкка белдермәскә җыеналар. Әмма мондый серне яшереп саклый алмыйсың, кем дә булса барыбер читкә чыгара. Тимербәк соңгы сулышын алганда, янында оныгы Хәлил Солтан була. Бабасы үлү белән, ул гаскәр туплый, бәк исеменнән ил-йорт белән идарә иткән өч әмиргә каршы яуга чыга. Берсенең башы киселүгә, калган икесе Тимербәкнең Хорасандагы Герат каласында яшәгән улы Шаһрух янына качып китә.

Хәлил Солтан, бабасының якынын үтергәннән соң, шәһәрне, казна йортын үз кул астына ала, Тимербәкнең җәсәден соңгы юлга озатуны оештыра. Хакимлекне алгач, ул әтисенә казнаны тапшырачагын әйтеп хәбәр җибәртә: Сәмәрканд халкы сине таныса, син, һичшиксез, илбашы булачаксың, казнада байлык мул, ул синең кулга күчә икән, акчага хирыс чыгытайлар синең аягыңа егылачак, бу көч белән син бәк булачаксың! [...]

Хәлил Солтанга ул чакта егерме ике яшь иде. Ак йөзле, әтисенә охшаш таза гәүдәле. Сәмәркандта чакта ул испан илчеләренә бик зур игътибар күрсәтте.

Күпләрнең чын йөзен ачар өчен сынап карарга дип, Тимербәк үзе исән чакта ук үлгәнлеге хакында ике мәртәбә хәбәр ирештергән булган. Бу хәбәрне ишетеп кем сөенә, кем баш күтәрә – аларны рәхимсез җәзага тарттырган. Шуңа күрә бу үлем хәбәренә дә, хак булуга карамастан, берәү дә ышанырга җөрьәт итмәгән. Күпме вакыттан соң да, илчеләр Турис шәһәренә килеп җиткәч тә, Тимербәк исән, гаскәре белән Бабил солтанлыгына каршы яу чыккан, дигән сүзләр йөри иде әле.

Гыймраншаһ морза, әтисе Тимербәкнең чынлап та үлгәненә ышанып, улы Гомәрнең очрашырга дигән үтенече буенча икенче улы Әбүбәкер морза белән Багдадтан юлга чыга. Юлда ул шуны белеп ала: улы Гомәр морза элеккегә караганда да отыры күбрәк гаскәр туплаган, Турис, Солтания калаларына үз күрсәтмәләрен көтәргә әмер биргән. Моны белгән ата кеше сагаеп калган, улына барудан тыелып, аның теләкмаксатын ачыклау өчен чапкын җибәргән. Улыннан: «Гаскәрне тупладым ил эчендә һәм чик буйларында дошманнар көчемне белеп торсыннар өчен», – дигән җавап килә. Шуннан соң Гыймраншаһ белән юлга чыккан улы Әбүбәкер абыйсы янына башта үзе генә барып, аннары атасы катына аның үзен китерергә ниятли. Гомәр морза белән Әбүбәкер морза – икесе бер анадан туган карындашлар. Әниләре, Гомәр морзага барып:

«Улым, синең әтиең бәк булырга тиеш, ә син каршы барасың!» – ди. «Әтием теләгенә каршы килүдән Аллам сакласын», – ди улы. Әнисе, кайтып, ире Гыйммраншаһка бу сүзне җиткерә. Шуннан соң гына Гыйммраншаһ Әбүбәкерне бертуганы янына ил-йортны үзенә ничек тапшыруны хәл итү өчен гаскәрсез генә җибәрә.

Гомәр морза, бертуганының юлга кузгалуын белүгә, аны кулга төшерергә әзерләнә башлый. Ул килеп җитүгә, Гомәр тирмәсеннән чыгып каршы ала, бертуганын кулыннан тотып, кунакчыл кыяфәт белән эчкә уздыра һәм шунда ук эләктереп алырга әмер бирә. Әбүбәкернең тышта калган илле җайдагы, тезгенне борып, кайту ягына җилдерә. Гомәр морза, бертуганын богаулап, Солтаниядәге зинданга яптыра да әтисен дә кулга алу нияте белән юлга чыга. Әтисе кияве Сөләйманшаһ морза белән чыгытайлар яшәгән Рея җирләренә китеп сыену таба. Улларының шундый хәлгә таруын авыр кичергән әнкә, Гомәр морзага килеп, үз күлмәген умырып төшерә, күкрәген ачып елый-елый: «Мин сезне тудырып үстердем, син хәзер абыеңны үтертергә җыенасың, карындаш икәнен дә, аны бөтен кеше яратканын да беләсең бит», – ди. Улы бертуганын акылсыз, ярсу булганы өчен, теләсә ни сөйләп йөргәне өчен генә ябуда тотканын, ә әтисен исә илбашы итеп күрергә теләвен белдерә.

Әбүбәкер морзаны үтә тәвәккәл, чая булганы өчен чыгытайлар бик яраталар, Гомәр моңа чик куярга була. Аннары ул әтисен кулга алырга дигән төп максатына керешә. Сәмәркандка таба юлга чыккан әтисе артыннан ул да кузгала. Болай гына кулга төшерә алмаслыгын белгәч, әтисенең абыйсы Шаһрухны үз ягына аудара. Гыйммраншаһ исә, абыйсы һәм улының бер тотамда икәнен белеп алуга, юлын бүлеп, Хорасанда калырга ниятли. Бераздан ата белән ул килешәләр, ләкин ата кеше улына инде беркайчан да ышана да, таяна да алмый. [...]

Шушы чорда Гомәр морза Турис каласында тукталган испан илчеләренә хат җибәрде. Анда: «Тоткарланганыгыз өчен рәнҗемәгез, әти белән ике араны җайлаганнан соң, мин сезне җибәрермен», – диелгән иде.

Шуннан соң сишәмбе, 29 апрельдә, изге Петр газап чиккән көнне, илчеләр өйдә чакта шәһәр бәге, бөтүче һәм тагын ниндидер кешеләр килеп керде. Ишекне эчтән бикләп, шпага, тагын башка коралларны җыеп алдылар, өстән шулай кушылды, бөтен әйберләрегезне дә алып китеп, ышанычлы урынга куябыз, диделәр. Без сезнең ихтыярда, диде илчеләр. Безне король үзенең якынына – Тимербәккә илче итеп җибәрде, безгә мөнәсәбәт гел шулай җылы буласына ышанган идек, бөек илбашы үлеп киткәч инде безнең язмыш сезнең кулда.

Сезнең иминлекне кайгырту өчен шундый боерык булды, дип аңлатты шәһәр бәге. Әмма алар әйтелгәнчә эшләргә җыенмыйлар иде шикелле. Илчеләрнең өстендәге киемнәрен генә калдырып, бар мөлкәтләрен – кием-салым, акча янчыкларын, иярләрне, атларны, бөтен кирәк-яракларны икенче йортка алып китеп, сак куйдылар. Бабил солтаны һәм төрек илчеләре дә шундый ук мөнәсәбәткә дучар булды. Әйберләрне яңадан кайтарып биргәндә, шактые шуытылган иде инде.

*Урысчадан* ***Марсель Галиев*** *тәрҗемәсе* ■

# Яңавыл (Ирнур) – Мари Илендәге татар авылы

**Фәнил Мусин**

**Яңавыл (Ирнур) «Уржум өязенең Генераль ызанлау планы»нда**

Мари Иленең Бәрәңге районында бүген 11 татар авылы бар. Элек аларның саны 22гә җиткән. Соңгы елларда бу төбәкне өйрәнүдә зур эшләр башкарылды.

Яңавыл район үзәгеннән 7 чакрым ераклыкта, көньяк-көнбатыш якта җәйрәп ята. Төбәкне өйрәнүче Рафаиз Гайнанов тапкан архив мәгълүматларына караганда, әлеге торак пункт элгәре башка җирдә – Ировка елгасының сул ягында, хәзерге «Батыр» агрофирмасы җирендә урнашкан булган.

Рафаиз Нурмөхәммәт улы раслаганча, *Ировка буендагы пүчинкә* (авыл элек шулай аталган) татарлар тарафыннан XVI-XVII гасырларда салынган. Бәрәңге, Кугунур (Түбән Мазарбашы), Кукмара (Иске авыл), Морзабаш (Югары Мазарбашы) авыллары белән беррәттән, *Ировка буендагы пүчинкә* дә безнең якларда иң борынгы татар торак пунктларыннан санала.

XVII гасыр ахырларыннан алып җанисәп документларында Ировка елгасының уң ягында да татар авылы күренә башлый. Мондагы иң беренче йортлар 1690 нчы елларда нигезләнә. Писарьлар яңа торак пунктны *Ировка аръягындагы пүчинкә* дип яза, татарлар арасында исә ул Яңавыл буларак таныла.

1716 елгы Беренче ревизия мәгълүматларына караганда, Ировка буендагы пүчинкәдә 10 ир-ат яшәгән. Шуларның иң өлкәне Рыска Утякеевка[1] 84 яшь булган (1632-1726). Документта аның уллары, оныклары да теркәлгән: Заит Рысков (1679 елда туган), Яртейка Рысков (1680-1734), Мадей Рысков (1702 елда туган), Бикмет Рысков (1707 елда туган). Уразметка Сабанаевның (1637-1734) уллары,

[1] Ялгызлык исемнәр монда һәм моннан соң җанисәп документларында теркәлгәнчә бирелә. – ***Ред.***

бертуган Сәфәр Уразметев (1687 елгы) һәм Уразгильда Уразметев (1694 елгы), аларның балалары да кәгазьгә төшерелгән. 1719-1745 нче еллар аралыгында, ягъни Икенче ревизиягә чаклы 5 кеше үлгән, шул исәптән әле генә телгә алынган Рыска Утякеев (1726 елда вафат) һәм Уразметка Сабанаев (1734 елда вафат).

1745 елгы Икенче ревизия материалларына караганда, ул вакытта 6 хуҗалыкта 11 кеше яшәгән. 1762 елгы Өченче ревизия биредәге 5 йортта 14 ир-ат һәм 14 хатын-кыз яшәвен күрсәтә.

Ировка аръягындагы пүчинкәдән (хәзерге Яңавыл) 1716-1745 нче еллар аралыгында 4 кеше киткән. Шуларның берсе – 1713 елгы Муса Якупов – 1736 елда рекрутка алынган. Бу авылда 1745 елда 8 йорт булып, аларда 26 кеше яшәгән.

Өченче ревизия 1762 елның 3 июлендә уздырылган. Пүчинкә Казан өязенең Алат даругасына караган. Монда ясаклы татарлар яшәгән, староста булып Мортаза Аппакаев, выборный[2] булып Абдри Абдулкин торган. Торак пункт шактый үсеп киткән, 10 йортта 51 кеше (27 ир-ат һәм 24 хатын-кыз) гомер кичергән.

Шушы чорда бу җирләр (крестьяннары белән бергә) Император йорты алдындагы казанышлары өчен сәнәгатьче һәм эшмәкәр Мәмәтовлар нәселеннән чыккан Манасып Максютовка (Монасыйп Мәкъсүтов) бүләк ителә.

*Ировка аръягындагы пүчинкә* 1795 елда *Иръ елгасы буендагы пүчинкә* дип атала башлый, елганың сул ярындагы авыл бөтенләй юкка чыга. Ул XIX гасырда төзелгән «Уржум өязенең Генераль ызанлау планы»на да теркәлмәгән. 1796-1801 нче елларда язылган кульъязма китапча, Бәрәңге вулысының Иръ елгасы буендагы пүчинкәсендә 84 кеше яшәгән. 1811 елгы җанисәптә 28 йорт күрсәтелгән. Бу ревизия мәгълүматларына ышансаң, 1796-1807 нче еллар арасында авылдан биш егет – Бикмурат Абдылиев, Губайдулла Абсалямов (Гобәйдулла Әпсәләмов), Фәйзулла Габитов, Баязит Вәлитов һәм Губайдулла Мустаев (Гобәйдулла Мостаев) – армия хезмәтенә алынган. Ни сәбәпледер, ике егет – Хәмит Габитов белән Муслюм Мукминов (Мөслим Мөкминов) авылдан качкан.

1816 елда пүчинкәдә 33 йорт булып, аларда 234 кеше яши. 1834 елда 35 йортта 317 кеше (168 ир-ат һәм 149 хатын-кыз) гомер кичерә. Бу вакытта авыл Уржум өязенең Буй вулысына карый. 1842 елда Хәмит Гомәровны соңгы юлга озаталар, аңа 106 яшь була. 1848 елда Ташкичү авылыннан пүчинкәгә Сираҗетдин Әпсәләмов исемле указлы мулла җибәрелә. 1850 елгы Тугызынчы ревизия күрсәткәнчә, Яңавылда 47 йорт булып, аларда 415 кеше яшәгән (шуларның 205е – ир-ат). Торак пункт Уржум өязенең Ирмучаш вулысына караган.

1858 елның 4 маенда пүчинкәдә Унынчы ревизия үткәрелә һәм 54 йортта 482 кеше яшәгәне ачыклана. Шулар арасында – отставкадагы ике солдат, бер унтерофицер (Сәйфелмөлек Мәсәгутов), җиде солдатка (ирләрен сугышта югалткан тол хатыннар), дүрт солдат улы һәм җиде солдат кызы.

1869 елга йорт саны 97гә җитә, халык саны исә 473 кешегә (алтысы – урыс) кадәр кими. Крестьяннар 194 ат, 291 мөгезле эре терлек, 288 сарык, 50 кәҗә асрый. Авылның 12 оя умартасы 3 пот бал бирә, 44 фунт балавыз ясый. Купшерка елгасы ярында су тегермәне, агачтан корылган җәмигъ мәчете була.

«Ведомости о магометанских школах Уржумского уезда» хәбәр иткәнчә, 1869 елда Яңавылда 6 ир-ат – хәлфә, 5 хатын-кыз абыстай вазыйфасын үти һәм зур иҗтимагый-җәмгыяви эш башкара. Авылда 4 шәхси мәктәп эшли, аларда Коръән

---

[2] Выборный – крепостнойлык чорында крестьяннар тарафыннан сайланып куела торган староста ярдәмчесе. – ***Ред.***

укырга, дин-әхлак асылына өйрәтәләр, барлыгы 110 укучы сабак ала. Балаларны үз йортында бушлай мулла Фәтхулла Фәйзуллин, крестьян Мөхәммәди Ибраев, указлы мәзин Абдул Мафик (Габделмәфикъ) Абтуллин, мәрхүм мулла Сираҗетдин Әпсәләмовның хатыны Махуба (Мәгубә) Гобәйдуллина укыта. Мәктәпне җылыту өчен утын әзерләп бирү ата-ана өстендә була.

1878-1883 нче елларда Яңавылда 100 утар һәм 120 торак корылма санала. Иҗтимагый биналар һәм мәчеттән тыш, кечкенә азык-төлек кибете дә булуы күрсәтелә. Документ раслаганча, Яңавыл-Портянур арасындагы су тегермәне янәшәсендә дә йорт торган, анда бер ир-ат һәм бер хатын-кыз яшәгән. Янындагы кишәрлеге 9 дисәтинә 2360 сажин тәшкил иткән һәм Бәрәңге авылыннан чыккан элеккеге дәүләт крестьяны Барганутдин (Борһанетдин) Мөхетдиновның милке исәпләнгән.

1884 елда Яңавылда 138 хуҗалык булган. Крестьяннар 2237 дисәтинә имана җире тоткан. Һәр хуҗалыкка уртача 16,1 дисәтинә җир туры килгән. Авыл халкы 136 эш аты, 18 тай, 146 сыер, 127 мөгезле эре терлек һ.б. асраган.

Урман һәрвакыт авылның төп байлыгы булып торган, җирле халык аннан бик күп файда күргән. Ибрай күле мунчала ясау өчен юкә төшерүгә хезмәт иткән, каен һәм наратлар арасында утырган Карасу күле янында агач күмере, сумала һәм дегет җитештерә торган кечкенә завод салынган. Соңрак бу урыннан 7 чакрым читтәрәк тарихта «Сәгыйть заводы» буларак калган сумала кайнату заводы корылган. Ул күмәкләштерүдән соң да шактый эшләп торган әле.

Гаиләләр ул чорларда ишле булган, балалар ата-аналары белән бергә яшәгән. Ир-егетләр, үзләре дә 2-3 сабый алып кайткач кына, йорт салып, башка чыккан. Кайбер гаилә башлыгына шул рәвешле гомере буена 5-6 йорт җиткерергә туры килгән.

Уржум өязенең Төрек вулысына кергән чакта авыл тагын да үсә, ныгый. Хәлле крестьяннар кибет ача, мәчетне карый. XX гасыр башына Яңавыл татарлар гына яши торган шактый зур торак пунктка әйләнә. 1905 елда биредә 176 хуҗалык, 1001 кеше була. Фәкать шәригать кушканча гына яшиләр. 1919 елда мәчет янында ачылган мәдрәсәдә мөгаллим Гаффар Гайнуллин ислам дине нигезләренә өйрәтә.

1920 елда Төрек вулысы составында авыл Мари автономияле өлкәсенә керә. 1924 елдан Мари-Төрек кантоннарына карый, 1931 елдан ул Мари АССРның Бәрәңге районына күчерелә.

Совет хакимияте урнашканнан соң, авыл тормышы үзгәрә башлый. Табигать тә ныклыкны сынап карый. Яңавыл халкы алабутадан башка берни үсмәгән коточкыч корылык елларын да хәтерендә саклый. 1924 елның җәендә барлык икмәк-иген коеп яуган бозлы яңгыр астында калып харап була.

1926 елда Яңавылда Авыл Советы оеша, аның беренче рәисе итеп Галәветдин Насретдинов билгеләнә. 1931 елда авылда 188 хуҗалык санала, аларда 891 кеше яши. Яңавылда төрле катлам вәкилләре була: 69,8 проценты – уртакул крестьяннар, 24,8 проценты – ярлылар һәм 5,4 проценты – хәлле крестьяннар (кулаклар).

1929 елның 2 декабрендә Яңавылда Сәгыйдуллин рәислегендә (сәркатибе – Йосыпов) халык җыелышы уза. 27 кеше, җирне күмәк эшкәртү максатыннан, «Алга» исемле коммуна төзергә карар кыла. Бер елдан аларга тагын 5 крестьян өстәлә һәм коммуна «Яңа Тормыш» күмәк хуҗалыгына әверелә. 1931 елның 15 маена «Яңа Тормыш»ка 108 кешедән торган 29 гаилә керә: 102 ярлы, 2 уртакул крестьян һәм 4 педагог. 1932 елда колхозны Нәби Галиуллин җитәкли. Хуҗалыкның 194,5 га җире, 12 аты, 22 сыеры, 33 сарыгы була.

Соңрак берлекне Фәттахов, Хәбибрахман Тәминдаров җитәкли. 1934 елда рәис итеп Әхмәт Әхмәтгалиев сайлана. Шул ук елны авылда куркыныч янгын чыга, 41 йорт күз ачып йомган арада кара күмергә әйләнә. Кайбер гаиләләр, мантый алмыйча, күрше Морки районының Октябрьский урман участогына күченеп китәргә мәҗбүр була.

1938 елда колхозчылар Мостафа Галләмов җитәкчелегендә зур уңыш җыеп ала. Шуның өчен аларга һәр эш көне (трудодень) өчен 8әр кг икмәк, бераз бал бүлеп бирелә. Әмма нахак сүз аркасында Мостафа Галләмовны кулга алалар, хөкем итәләр. Хөкем карарына карамастан, авыл халкы үзенең рәисен яклап чыга һәм аны азат иттерүгә ирешә.

Узган гасырның 20-30 нчы елларында авыл халкының мәдәниятен, белемен күтәрү максатында зур эшләр эшләнә. 1921 елда Габдулла бай Сәгыйдуллин йортында башлангыч мәктәп ачыла, анда Әхмәдиев укыта. Егерменче еллар азагында биредә Миңлебаев мөгаллимлек итә. Кырыгынчы елларда исә – Гомәр Шәйхиев, Гөлсем Мортазина, Гөлҗиһан Сөләйманова, Тәлгат Ганиев.

Укытучылар наданлыкны бетерүгә күп көч куя. Аларга башлангыч белем алып өлгергән яшьләр ярдәм итә: Гадения Сәлахова, Әсма Кәримова, Майнур (Маһинур) Бәдирова, Барый Әхмәтҗанов, Малик Сәйфетдинов.

1936 елда авылда зурлар өчен урта мәктәпнең берничә сыйныфы ачыла, анда 30 ир-ат һәм 20 хатын-кыз гыйлем эсти. Монда М.Кәшапов (1909 елгы) укыта, Г.Фәйзуллин (1913 елгы) директор була.

Утызынчы елларда мәчет ябылып, аның бинасында клуб эшли башлый. Беренче мөдир Габдулла Җәләлетдинов тамаша залы, сәхнә, озын эскәмияләр ясатып куя. Монда иҗтимагый чаралар, концертлар үткәрелә.

1938 елда авылга телефон керә, ике елдан соң Яңавыл халкы беренче тапкыр радио тавышын ишетә. Шул ук елны уку ызбасы (изба-читальня) ачыла, грамотасызлыкны бетерү өчен Татарстаннан җибәрелгән Шәмсия Закирова 1950 елга кадәр аның җитәкчесе булып тора. 1940-1963 нче елларда монда трахоматоз пункты эшли.

Сугыш елларында авыл халкы үзенең иң шәп 240 ир-егетен фронтка озата. Күбесе кулсыз-аяксыз, яралы килеш әйләнеп кайта, 150се яу кырында ятып кала. Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә 1989 елда һәйкәл куела, монда 9 май саен зурлап тантаналы чаралар уздырыла.

Авыр сугыш елларында күмәк хуҗалык белән Куян авылыннан Йосыф Хәйруллин, Нәбиулла Сәмигуллин, Фәтхулла Фатыйхов, Мөхәмәш Садыйков идарә итә. Тылда калган хатыннар һәм үсмерләр хуҗалыкны саклап калу, планны үтәү, фронтка ярдәм итү өчен кулларыннан килгәннең барысын да эшли. Дәһшәтле яуның соңгы елларында халык ачыга башлый. Бертуган Шәмсетдиновлар үләксә ашап үлә, Хафизовлар гаиләсе агулы гөмбәдән җан тәслим кыла. Әмма һичнинди авырлыкларга карамастан, кешеләр якты киләчәккә, ак бәхеткә ышанып яши, хезмәт куя. Балаларны да шуңа ышандырып тәрбиялиләр. Сугыш елларында Яңавыл башлангыч мәктәбе эшен туктатмый. 1941 елда аны 141 укучы тәмамлый.

1946-1955 нче елларда колхозны Сәмикъ Хәбибуллин җитәкли. Сугыштан соңгы хуҗалыкны күтәрү бер дә җиңел булмый. Орлыкка һәм, табигый, көзге уңышка ярлы 1946 елда бигрәк тә. Күп гаиләләр хәтта бәрәңге дә утырта алмый. Күрше мари һәм урыс авыллары күрсәткән ярдәм генә Яңавыл халкын ачлыктан коткарып кала.

Кумәк хуҗалык тора-бара ныгый башлый. Авырлыкларга карамастан, 1949 елда авылның үз электр станциясе корыла. Утын ягып эшләгән бу станциянең куәте 25 ат көченә тигез була. Электр энергиясе терлекне су һәм азык белән тәэмин итү өчен файдаланыла. 1956 елда 5 чакрымлык чыбыклар сузыла, 150 йортка ут керә. Авыл 1960 нчы еллар азагына тулысынча электрлаштырылып бетерелә.

1959 елның декабрендә «Яңа Тормыш» (Яңавыл), «Кызыл Байрак», «Яңа Юл» (Портянур), «Кызыл Октябрь» (Лажы) хуҗалыклары «Яңа Юл» колхозына берләшә.

1965 елның мартында «Яңа Тормыш» (Яңавыл) хуҗалыгы яңадан мөстәкыйльлек ала. Шул елдан башлап, КПСС ҮК Пленумы карары нигезендә, хөкүмәт авыл хуҗалыгы өчен зур суммада акча бүлеп бирә башлый. Бу, билгеле, уңай үзгәрешләргә китерә. Ул елларда хуҗалык рәисе булып Шамил Габдулла улы Габдуллин тора.

Яңа технологияләр нигезендә җир эшкәртү яхшыра, мал-туар үрчи. Колхозга югары белемле белгечләр кайта. Хуҗалык та, махсус стипендияләр булдырып, үзенә кадрлар әзерли. Югары квалификациягә ия рәисләр чоры китә: Мөхәммәтзиннәт Галләм улы Галләмов (1969-1975, 1989-1992), Габделхак Ибрай улы Ибраев (1975-1989), Әлфит Габделхак улы Ибраев (1994-2001).

«Яңа Тормыш» колхозы мул уңыш җыя. Яңавыл фермасы сөт һәм ит җитештерүдә районда алдынгылыкны яулый. Әмма 1994 елда фермадагы мал-туарны туберкулез ега, аларны суярга туры килә.

Бу авыр чорда колхозны Әлфит Ибраев җитәкли. Ул, авыл халкын мобилизацияләп, авыр чир нәтиҗәләреннән чагыштырмача җиңел котылып кына калмый, терлекчелекне яңадан рентабельле тармакка әйләндерә ала. 2001 елның 4 февралендә Әлфит Ибрай улы Бәрәңге районы башлыгы итеп сайлана һәм 20 ел буе, бүгенгәчә аны җитәкли.

2003 елның 1 июленә Яңавылда 187 шәхси хуҗалык, 607 кеше (385 ир-ат һәм 322 хатын-кыз) санала. Монда, ике урыс һәм ике маридан кала, татарлар яши. 2010 елның 5 октябрендә Яңавылда өр-яңа башлангыч мәктәп һәм балалар бакчасы 1-3 сыйныф укучылары һәм мәктәпкәчә яшьтәге сабыйлар өчен үз ишеген ача. 2020 елның 1 гыйнварына авылда 167 хуҗалык булып, аларда 471 кеше гомер кичерә.

## Мәшһүр авылдашлар

Биредә мөселман йолаларын кадерләп саклыйлар. 1997 елда авылда яңа таш мәчет ачыла. Аны салып чыгар өчен бөтен халык акча җыя. Аллаһ йортын төзү эшенә бик күп көч-куәт куйган кешеләрнең берсе – элеккеге рәис, пенсионер **Габделхак Ибрай улы Ибраев.** Аның турында аерым сөйләп узарга кирәк.

Габделхак Ибраев 1929 елның июнендә туа. Авыр тормыш юлында чыныгу үтә, бик күп җаваплы урыннар били. Малай чагында ук колхозда эшли башлый. 13 яшендә почтальон булып хезмәт итә. Эссегә, суыкка карамыйча, көн саен район үзәге Бәрәңгедән почта ташый. Һәр якка – сигезешәр чакрым. Сугыш чоры. Әтисе Ибрай Нәҗметдинов илне яклап кан коя. 1942 елда аның үлеме турында хәбәр килеп төшә. Бу «кара кәгазь» иң беренче булып Габделхакның кулына керә. Ул юл буе елап кайта, әнисенә әлеге хәбәрне ничек җиткерергә белми… Һәм, ананы хәсрәт утына салырга теләмичә, хатны яшерергә карар кыла.

Дөньялар тынычлангач, Габделхак Бәрәңге педагогика училищесына укырга керә. Әмма авылда (бигрәк тә – туган йортында) эшче куллар кирәккә күрә,



Габделхак Ибраев хатыны Гөлирә белән

аңа укуын ташлап кайтырга туры килә. Җөмләдән, шушы вакытта ул «Бөек Ватан сугышы елларында фидакяр хезмәте өчен» медале белән бүләкләнә. Бәрәңге районында бу бүләкне алучылар арасында иң яше була Габделхак.

1946 елда 17 яшьлек егет-җилкенчәк кыр бригадасының җитәкчесе итеп билгеләнә. Аннары дүрт ел буе армиядә хезмәт итә. Әйләнеп кайткач, Габделхак Ибраев яңадан бригадир булып эшли башлый һәм бик күркәм нәтиҗәләргә ирешә: аңа багышланган мәкаләләр район һәм республика газеталары битләреннән төшми. Соңрак ул Портянур һәм Бәрәңге Авыл Советларында эшли, КПСС райкомы инструкторы булып тора, партия оешмасында сәркатип вазыйфаларын башкара. Район һәм Авыл Советлары депутаты итеп сайлана.

Габделхак Ибраев 1975 елдан алып 1990 елда лаеклы ялга чыкканчы «Яңа Тормыш» колхозын җитәкли. Нәкъ менә шушы чорда ул оста оештыручы һәм нык куллы, төпле акыллы, алдан күрүчән җитәкче буларак танылa да. Эшне яхшы оештыра белүе белән колхозны, Бәрәңге районын Мари Иленнән тыш, әйләнә-тирә төбәкләрдә дә таныта. Төрле як халкы тәҗрибә туплар өчен Яңавылга агыла башлый. «Яңа Тормыш» колхозы терлекчелек тармагында Мари Илендә беренче урынны яулый.

Яңавылның социаль инфраструктурасы зур үзгәрешләр кичерә. Бакча-мәктәп, фельдшер-акушерлык пункты, ашханә һәм кибет, мал-туар абзарлары, тегермән, иген киптерү урыннары, йортлар, буа, юллар салына. Колхозны үстерүгә һәм нығытуга биниһая өлеш керткәне өчен, Габделхак Ибрай улы Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет Билгесе» орденнары, ВДНХның алтын медале, бихисап Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә.

Җәмәгате Гөлирә Гани кызы (һөнәре буенча – мөгаллимә) белән бергә бик озын, матур гомер кичерәләр. Тупырдап торган биш бала тәрбияләп үстерәләр. Аларның һәрберсе бу тормышта үз урынын табып, уңышка ирешә, һәммәсе район һәм республика күләмендә дәрәҗәле кешеләр.

Габделхак Ибраев лаеклы ялга чыккач та кул кушырып утыра белми. Аның тырышлыгы белән Яңавылда искиткеч матур мәчет торгызыла. Табигый, районда аны белмәгән кеше юк. Габделхак ага турында якты истәлек бүген дә безнең йөрәкләрдә саклана.

Авылның хәзерге тарихы турында сөйләгәндә, тагын бер шәхесне телгә алмый калырга ярамый. Ул – Россия Федерациясе Герое, В.П.Чкалов исемендәге дәүләт очыш-сынау үзәге башлыгы, генерал-майор **Радик Әбрар улы Бариев.**

Радик Әбрар улы 1961 елда хәрбиләр гаиләсендә дөньяга килә. Аның әтиәнисе – Әбрар Бариев һәм Нурания Мусина – чыгышлары белән Яңавылдан, шуңа күрә Радик Әбрар улы да бу авылны туган җире дип саный. (Өстәвенә, ул бер елга якын мондагы башлангыч мәктәптә укып та алган була әле.)

**Россия Герое, генерал-майор Радик Бариев**

1982 елда Р.Ә.Бариев, Качинск югары хәрби авиация училищесен тәмамлап, очучы һөнәрен үзләштерә, аннары 6 ел буе Карпат якларында хезмәт итә. Катапульция ясау турында боерык алуга карамастан, хәрби техниканы харап итмичә, җиргә төшереп утырта алганга күрә, 1988 елда ул Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Радик Бариев 1988 елда Ю.А.Гагарин исемендәге хәрби-һава академиясенә укырга керә. Шушы чорда Космонавтлар отрядына алына (ил җитәкчелеге «Буран» корабын экипаж белән бергә галәмгә очыруны максат иткән вакыт була бу).

1991 елда ул В.П.Чкалов исемендәге очучылар әзерләү үзәгенә укырга җибәрелә. Ике елдан соң шунда ук сынаучы-очучы, аннары өлкән сынаучы-очучы, эскадрилья командиры урынбасары булып эшли. Карьера баскычы буйлап өскә менә барган саен, ниһаять, 2003 елда В.П.Чкалов исемендәге үзәкнең башлыгы вазыйфасын башкаруга керешә. Илнең бихисап очкычлары аның җитәкчелегендә сынау уза.

Алда язып үткәнчә, Радик Бариев җитди бурыч куелып, һәлакәткә тарыган хәлдә кыйммәтле техниканы саклап кала ала, үзе дә җиргә сау-сәламәт килеш төшә. Бу өлкәдәге барлык мәгълүмат «яшерен» грифы белән йөргәнгә күрә, без, әлбәттә, Радик Әбрар улы күргән барлык куркынычларны, ул күрсәткән барлык авырлык һәм батырлыкларны белеп тә, белгертеп тә бетерә алмыйбыз. Күп еллар буе самолет кебек катлаулы техниканы өйрәнгән, аның хәрәкәт-гамәлләрен, үзүзен тотышын аңларга омтылган офицерның хезмәт юлында андый чаклар шактый булгандыр дип чамаларга гына кала. Шунысы шиксез: аның төгәл һәм урынлы киңәш-табышлары нәтиҗәсендә Россия «корыч кошлары»ның кимчелекләре бетерелә, очкычлар камилләшә-яхшыра, аларның маневр ясау сәләте арта.

2012 елның 13 декабрендә Радик Бариевка генерал-майор званиесе бирелә. Фидакяр хезмәт чорында ул бик күп мактауларга, бүләкләүләргә лаек була: медальләр, Кызыл Йолдыз һәм Батырлык орденнары, «Россия Федерациясенең атказанган сынаучы-очучысы» исеме һ.б. Якташыбыз – хәрби фәннәр кандидаты, Россия хәрби фәннәр академиясе профессоры, Әстерхан Өлкә Думасы депутаты.

Соңгы елларда без телетапшырулар аша Россиядә яңа корал җитештерү, яңа техника булдыру турында күп күрдек, күп белдек. Алар арасында вертикаль рәвештә күккә күтәрелеп, мизгел эчендә һавада эленеп калып, артка «мәтәлчек атып», аннары бөтенләй башка юнәлештә хәрәкәт итә алган очкычлар да бар. Дөньяда мондый самолетларның тиңе юк. Безнең хәрби-һава көчләренең шундый дәрәҗәгә

**Муса Галләмов көрәш мәйданында**

җитүендә Радик Бариевның да өлеше бик зур. Шулай булмыйча: тыныч тормышта тиктомалга Россия Федерациясе Герое исемен бирәләрмени?!

Авылыбызның тагын бер күрке – **Муса Марсель улы Галләмов.** Аның исеме татар көрәшен күзәтеп барган һәркемгә таныш.

Үзе сөйләгәнчә, 15 яшькә кадәр ул тормышын көрәш белән бәйләү турында уйлап та карамый. Сабан туйларында ат чабышында катнаша, хоккей уйный, бер-ике тапкыр көрәш келәменә чыгып карый.

Йошкар-Олада укыган елларында Республика татар мәдәнияте үзәгенең спортзалына килеп, татар көрәше түгәрәгенә языла. Күп тапкырлар чемпион буласы егетнең беренче тренеры Илдус Гарипов була. Аннары ул ике ел дәвамында Бәрәңгедә Илгизәр Сафин җитәкчелегендә шөгыльләнә. Соңрак яңадан беренче тренерына әйләнеп кайта.

Муса Галләмов, тора-бара, тәҗрибә һәм осталык туплаган саен, ярышларда җиңә башлый, Сабан туйларында беренчелекне яулый. Аның даны район һәм республика күләменә генә сыешмыйча, күрше-тирә төбәкләргә тарала.

Бүген Муса – билбау һәм татар көрәшләре буенча спорт остасы, ике тапкыр Европа чемпионы, дүрт тапкыр Россия чемпионы, Дамир Галиев исемендәге турнирның алты тапкыр җиңүчесе, Муса Җәлил исемендәге турнирның дүрт тапкыр җиңүчесе. Тагын Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турнирында, Румыния (Констанца) һәм Литва (Клайпеда) җирләрендә узган ярышларда да җиңү арты җиңүләр яулавы… Мусаның барлык ирешкән уңышларын санап-язып бетерәм, дисәң, бернинди кәгазь җитмәс. Бәрәкәтле Яңавыл туфрагы шундый баһадирлар да үстерә!

Муса Галләмов үзен тренер сыфатында да сынап карый әле: җиде ел буе Бәрәңгедә һәм Йошкар-Олада яшь көрәшчеләр тәрбияли. Хәзерге вакытта безнең батырыбыз 130 килограммга кадәрле авырлыкта көрәшә. Аның төп уңышлары, һичшиксез, алда булырга тиеш!

***

Мари Иленең Бәрәңге районына кергән татар авылларын өйрәнү буенча эш, әлбәттә, ары таба да дәвам итәчәк. Туплаган материалларны аерым китап рәвешендә нәшер итәргә дә ниятләп торабыз. Насыйп булсын!

Файдаланылган әдәбият:

1. Государственный архив Кировской области. – Ф.176, оп.2, Д.353, Л.11-13/об.; Д.612, Л.26-36; Д.908, Л.722-734; Д.1347, Л.11об.-26об.; Д.1858, Л.328-358.; Д.1136, Л.906об., 907.;
2. Российский Государственный архив древних актов. – Ф.350, оп.2, Д.1175, Л.173-176, 371-373, 716; Д.1151, Л.716, 739.
3. Сборник очерков «История сел и деревень Параньгинского района Республики Марий Эл». Коллектив авторов. – Йошкар-Ола, 2004. ■

# Татар көймәсе*

**Нурулла Гариф**

**Тарихчы Нурулла Гариф «У самовара» кафесы музеендагы көймә янында**

* Минзәлә районының Бикбау авылында яшәүче Фәнзир Габдеразый улы Хаҗиев (1950) телефон аша мәгълүмат бирде. 24.08.2020 ел.

Фотодагы көймә 1960 елда Минзәлә районының Ык елгасы буенда урнашкан Бикбау авылында яшәгән Габдеразый Шәйхиразый улы Хаҗиев (1916) тарафыннан ясалган. Ул моңа кешеләрдән карап өйрәнгән. Әлеге көймәләрне Ык елгасы буендагы татар авылларында элекке чорлардан ук ясаганнар. Бу – ата-бабалардан калган мирас-шөгыль. Ык елгасының аргы ягында күлләр дә шактый. Әлбәттә, халык балык тоткан. Авылда мондый көймәләр күп булган. Күрше Дусай-Кичү һәм башка татар авылларында да шушындый типтагы көймәләр ясаганнар.

Әлеге көймәне нинди агачтан һәм ничек эшләгәннәр соң? Көймәне тирәк, өянке һәм юкә агачыннан ясаганнар. Иң әүвәле агачның яхшы, көймә ясарга яраклы өлешен сайлап алганнар. Аны туп-туры итеп агач буен чокып кергәннәр. Төп, аскы өлешенә нечкә борау белән 2-3 см тирәнлегендә төрле урыннарга контроль тишекләр тишеп, анда чөй какканнар. (Бу тишекләр көймәнең төбен артык нечкәртмәс яисә артык калын булмасын өчен кирәк.) Чөйләрнең башы күренүгә үк, агачны чокуны туктатканнар.

Көймәнең формасын эшләгән саен, аны «мунча кертә» баралар. Агач туп-туры чокылып кына ясалса, судагы көймә әйләнеп капланыр иде. Шул сәбәпле, аның чокырына кайнап торган су салып яисә кайнар себерке белән «кыйнап», урта өлешен яссылата, киңәйтә барганнар. Бу процессны акрынлап, берничә тапкыр башкарганнар. Көймә эшләнеп беткәч, нарат сагызын кайнатып, яисә каен тузы дегете, ә соңрак чорларда керосинда төрле майларны эретеп, көймәгә сылаганнар. Аңлашыла ки, әлеге эш көймәгә су үтмәсен һәм ныклык өчен кирәк булган.

Фотодагы көймә бер кеше өчен көйләнгән. Кешенең авырлыгына яисә санына карап, аның ян-ягына өстәмә такта – күтәртмә куйганнар. Авыл күлдән ерактарак урнашкан. Коры җирдә көймәне күчереп йөртер өчен махсус арба ясаганнар, аны бер кеше үзе генә дә тартып бара алган. Бу көймә бер ишкәкле генә. Аның, чайкалып кергән суны түгәр өчен, агач соскысы бар. Җәйге көннәрдә көймәне судан чыгарып, җилле урынга киптерергә куйганнар. Яңгырлы көннәрдә өстен каплаганнар. Кышын түбәдә сакланган.

**Контроль тишекләргә кагылган чөйләр**

Фотодагы көймәнең озынлыгы – 4,2 м, киңлеге – 1 м, тирәнлеге – 0,5 м. Көймә соңрак чорда, сыешлыгын зурайту һәм йөк күтәрү авырлыгын арттыру өчен, 10-15 см биеклеккә күтәртелгән.

Әлеге көймә бүгенге көндә Казан-Чаллы юлының 925 нче чакрымында урнашкан «У самовара» кафесы (хуҗасы – Тәлгать Мотыйгуллин) җирлегендәге музейда саклана.

***

Без, гадәттә, Обь, Иртыш, Енисей кебек елга һәм аның кушылдыклары үзәнлегендә яшәүче милләттәшләребезне көймә ясауның чын осталары булган дип беләбез. Бактың исә, үзебезнең Татарстанда да әлеге көймәләр эшләнгән һәм аны балыкчылар бик теләп файдаланган икән. ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# Кем ул Тогайка Беляков?

*(Бәзәкә авылы тарихына бәйле кайбер сәхифәләр)*

**Раиф Мәрданов**

**1689 елда вафат булган Йөзекәй Таңай улының каберенә куелган ташъязма. Бәзәкә авылы зираты**

Тарихчыларның хезмәтләрендә архив документларыннан алынган шундый исем күренгәли. Аның татар кешесе булганлыгы турында сүз барса да, исеме рус телендәге чыганакларда шактый бозып язылган.

Тогайка Беляков хакында Бәзәкә авылы (хәзерге Менделеев районында) тарихы китабында бераз язылып, анда үзенчәлекле һәм ялгыш аңлатма бирелгән иде[1].

Танылган галимә, тарих фәннәре кандидаты Альта Мәхмүтова Бәзәкә авылы җир биләмәләре турында язганда Айкилде Тәмәй улы белән Айман Йөзекәй улы исемнәренә 1696 елның октябрендә бирелгән грамотаны[2] һәм аларның бабалары Тогайка Беляковка бәйле мәгълүматларны буташтырып, ялгыш нәтиҗәләр чыгарган. Ягъни, калын архив эшләренең берсендә элекке христианча 7205 дигән датаны (хәзергечә 1696 ел) чиновник-писарь тарафыннан ялгыш саннарның урыннарын алыштырып, 7025 дип язылган елны Мәхмүтова, хәзергечәгә күчереп, 1517 ел дигән нәтиҗә ясаган. Һәм ул грамота, имеш, Тогай Беляковка бирелгән, ә Тогайның исеме Таһир булгандыр, ул үзе Нократ татары булса кирәк, дип, дәлилсез фаразлар язган. Нәтиҗәдә, 2017 елда Бәзәкә авылы нигезләнүенә 500 ел тулуны үткәрүгә әлеге китаптагы дата (1517 ел) нигез булды. Сүз дә юк, авыл бәйрәмнәрен уздыру бик кирәкле һәм файдалы. Ләкин Бәзәкә тарихы ялгыш исәпләнгән 1517 елдан гына башланган дип чикләү дә дөрес булмас. Чөнки Кама кебек зур елгага якын урыннарда аннан да борынгырак чорларда төрле төркем-ырулар яшәп, күпмедер вакыт өзеклекләр кереп, авыл яңадан яңарып киткәнлегенә мисаллар аз түгел.

1517 елга бәйле ялгыш дата турында А.Мәхмүтова Бәзәкә тарихына багышланган китабы чыкканчы ук фәнни җыентыкларда белдергән иде. Аның тарафыннан искечә стильдәге 7025 ел григорианча 1517 елга туры килә дигән дата да дөрес исәпләнмәгән. Чөнки 7025 елга караган документ булган дип фаразлаганда да, 7025 елның октябре хәзергечә 1516 елга туры килер иде.

Архив документларында Тогайка дип язылган исемне Таһир дигәннән үзгәргәндер дип фаразлау да нигезле түгел. А.Мәхмүтова аны Бәзәкә шәҗәрәсенең бер битендә «Таһир баба 1545 елда вафат» дигән, ләкин бер нәсел тармагына да тоташмаган Таһир исеменә бәйләргә тырышкан. Шәҗәрәдә Таһир бабаның кайсы нәсел бабасы итеп күздә тотылганлыгы билгесез. Әмма Айкилде һәм Айман исемле кешеләргә бәйле, 1696 (элекке христианча 7205) елның октябрендә патша Петр Алексеевич исеменнән бирелгән архив документында «старинная де вотчина за ними деда Тогайки Белякова на речке Безяке и по Каме реке» дигәндә, Таңай Бигәш улы күздә тотылган. (Таңай Бигәш улы исемен күптөрле чыганаклардан ачыклаган идек.) Чөнки ул, чынлап та, Айкилде һәм Айманның бабасы, ягъни аларның әтиләре Тәмәй белән Йөзекәй – Таңайның уллары булганлыгы архив материаллары белән раслана. Әгәр дә Таңай бабай борынгырак чор кешесе булса, элекке архив документында аны «прадед» яисә «прапрадед» дип атаган булырлар иде. Ә 1696 елгы архив документына нисбәттә А.Мәхмүтова, «борынгы бабайлары Тогайка Беляков», дип, «борынгы» дигән сүзне үзе өстәп җибәргән. (Гәрчә архив документында «деда»

[1] Мәхмүтова А. Бәзәкәм – туган бишегем. – Казан: Яз, 2016. – Б.24-28.

[2] Бу документның русларда элек кулланылган «7205 елның октябре» датасын хәзергечәгә А.Мәхмүтова ялгыш 1697 ел дип күчергән. Хронология үзенчәлекләренә күрә, һәр ел сентябрь аеннан башланган андый искечә ел исәбен хәзерге календарьга күчергәндә аерым ел саныннан гыйнвар-август айлары өчен 5508 саны киметелергә тиеш булса, сентябрь-декабрь айлары өчен ел саныннан 5509 саны алынырга тиеш. Ягъни, 7205 елның октябреннән 5509 санын алгач, ул 1696 елга туры килә.

дип кенә язылган.) Өстәвенә, Бәзәкә авылына бәйле 1689 елгы башка архив эшендә Таңайның бер улы «Аднагул Тогаев» рәвешендә аерымачык язылган дәлил дә бар.

Бәзәкәлеләргә 1696 елның октябрендә бирелгән грамотаның *«От... царя Петра Алексеевича 7205 года октября _ дня»* дигән мәгълүматы Казан, Киров һәм Мәскәү архивларындагы эшләрдә күп кабатланган, әмма, 7025, дип, датасы ялгыш язылган очрак берәү генә. А.Мәхмүтова кулланган архив эшендә ул: *«Грамота 7025 года октября _ дня, засвидетельствованная в Оренбургской Гражданской Палате, копия с сей грамоты от Царя Петра Алексеевича...»*, – дип язылган. Мәхмүтова, имеш, грамота 1517 елда Казан тәхетендәге Мөхәммәтәмин хан яисә Мәскәү кнәзе Василий III чорына туры килә, дип, Мәскәүдән бирелгән дигән фикер-фаразын язган[3].

Бәзәкә авылының борынгы бабаларын китап авторы Нократ татарларына бәйләргә тырышса да, фәнни дәлилләре юк. Әгәр дә андый грамота нократлылар исеменә бирелгән булса, моңарчы ул факт билгесез калмас иде. Чөнки Нократ татарларына бәйле тарихи документлар күптәннән башлап җентекләп өйрәнелгән, алар мәгълүм һәм бик күп китапларда басылып чыккан. Әгәр дә А.Мәхмүтова фаразлаганча, Болгардан чыккан бәкләргә бирелгән рәсми документ булса, ул 1517 елда Казан ханының ярлыгы булыр һәм аның датасы, һичшиксез, элекке татар документларындагы кебек, мөселманча язылыр иде. Һәрхәлдә, «октябрь» дигән ай исеме булмас иде. 7025 дигән датаның архив эшләрендә бары тик бер генә мәртәбә очравы шик астына куелып, кабат тикшерүгә мохтаҗ булуы да игътибарга алынып җитмәгән. Югыйсә, чынлап та, шул елгы датага бәйле мәгълүмат булса, мәхкәмә эшләрендә ул кабат-кабат күчерелер һәм тикшерелер иде. Ләкин Алабуга өяз судындагы бер тапкыр ялгыш язылуыннан тыш, Бәзәкә җирләренә бәйле тикшерү эшләренең югарырак – губерна дәрәҗәсендәге һәм бигрәк тә, Мәскәү архивындагы «Генераль межалау» эшләре фондында саклана торган Бәзәкә биләмәләре турындагы сәхифәләрендә 7025 датасы язылмаган, ә 7205 дигән дөрес дата күп кабатланган.

Шул рәвешчә, бары тик саннарның урыннарын бутап язудан гына исәпләп чыгарылган 1517 елны һәм Тагай исемен 1545 елда вафат булган Таһир белән тәңгәлләштереп, имеш, Бәзәкә авылына Нократ татарлары нигез салган, дип, А.Мәхмүтова бөтенләй дәлилсез нәтиҗә ясаган. Галимәнең «Казан ханлыгының көнчыгыштагы чикләре Нократ (Вятка) һәм Агыйдел елгалары белән билгеләнә» дигән һәм Казан ханлыгының бу чиге, гүяки, «Вятка буендагы Хлынов Республикасы карамагында булган...», дип, бүгенге Әгерҗе, Менделеев һәм Алабуга районнары территорияләрен күздә тотып, «Хәзерге Татарстанның төньяк-көнчыгыш җирләре XV гасыр азагында ар бәкләре кул астына кергән һәм Мәскәү Казанны яулап алганга кадәр үк Мәскәү дәүләте йогынтысына эләккән булып чыга», дигән бөтенләй ялгыш фаразлар белән буталган[4]. Болар, әлбәттә, тарихи дөреслектән ерак тора. Чөнки Казан ханлыгының чикләре һәм аңа буйсынган биләмәләрне тасвирлап язылган китапларда, шулай ук карта-сызымнарда андый нәрсә юк. Китап авторының «ар бәкләре» дигәндә күздә тоткан Нократ татарлары һәм «Хлынов Республикасы» Вятка елгасының югары агымындагы төбәктә урнашкан булган. Нократ татарларының биләмәләре шартлы рәвештә «Кама буйлап» дигән сүзләр Кама елгасының да югары агымы өлешенә генә туры килгән. Нок-

[3] Мәхмүтова А. Бәзәкәм – туган бишегем. – Казан: Яз, 2016. – Б.25.
[4] Шунда ук. – Б.25-26.

рат татарларының XVI гасыр башында төрле еллардагы биләмә хокукларына бәйле, А.Мәхмүтова искәрткән грамоталары да шул ук төбәккә – Вяткага коя торган Чүпче (Чепца) елгасы буенда төпләнеп яшәгән җирлеккә бәйле. Мәсәлән, 1505-1548 нче еллар арасында Нократ татарларына бирелгән сигез грамотада Нократ авылы (Карино), Чепца елгасы, калалардан Хлынов, Слободской, Котельнич тирәләре турында гына әйтелгән. Казан ханлыгы чорын җентекләп өйрәнгән М.Худяков һ.б. галимнәр Алабуга һәм Сарапул төбәкләрен Казан ханлыгы җирләре дип язганнар. Иж буендагы татар җирләренә Нократ татарлары иң әүвәл XVI гасырның ахырында гына килеп урнашкан. Иж буендагы кайбер авылларда яшәгән Нократ татарларының XVI гасыр башындагы, әле Казан ханлыгы яулап алынганчы рус патшалары биргән грамоталарга ишарә итүләре, гадәттә, үзләренең рус патшаларына тугры хезмәт иткән аксөяк заты булуларын раслау өчен искәртелгән («…в прошлых годех прадеды и деды служили в Вяцком уезде в князьях»). Ләкин андый документларны XVI гасырның беренче яртысында хәзерге Менделеев һәм Әгерҗе районнары тирәсен безнең төбәкне биләүләренә дәлил итеп кулланган фактлар юк. Вяткадагы рус җирләре һәм Нократ татарлары тарихын өйрәнгән галимнәр дә аларның биләмәләре төньяк тарафта гына булганлыгын язалар. Мәсәлән, А.В.Эммаусский XVI гасырның беренче яртысына карата болай дип язган: «Территория собственно Вятской земли в то время включала лишь северную часть края – бассейн реки Вятки до линии рек Пижмы и Вои. Вятские земли, лежавшие к югу от этих рек, находились под властью Казанского ханства»[5]. Ә Пижма һәм Вой елгалары Бәзәкә авылыннан 200 чакрымнан да артыграк төньяк тарафта. (Патша заманында Бәзәкәдән Вятка шәһәренә кадәрге ераклык 460 чакрым дип исәпләнгән.)

Бәзәкә авылы тарихы авторының Иж-Кама-Алабуга тирәләренең XV-XVI гасырлардагы тарихына карата язган һәм төгәл фактлар белән расланмый торган, хаталы фикерләре бары тик 1517 ел дигән ялгыш датаны ничек тә дәлилләргә тырышудан гына килеп чыккан.

Мәгълүм булганча, Нократ татарларының (элекке архив документларында алар «каринские татары» дип язылганнар) Кара бәк исеменә бәйле борынгы бабаларыннан тармакланган күп буынлы, XVIII гасырда ук рәсмиләштерелгән һәм хәзерге дәвамчыларына кадәр билгеле нәсел шәҗәрәләре китапларда һәм матбугатта күп басылды. Ул ыру кешеләре Арча һәм Мамадыш якларында, Әгерҗе районының Исәнбай, Үтәгән, Олы Барҗы (хәзер беткән), өлешчә Салагыш һәм башка авылларында, бүтән төбәкләрдә дә яшәгәнлеге билгеле. Ләкин Кара бәк нәселләренең хәзерге Менделеев районындагы авылларга бәйлелеге булмаган. Әгәр дә Бәзәкәне Нократ татарлары нигезләсә яисә аларның бу авылга берәр төрле мөнәсәбәтләре булса, шулай ук нократлыларның XVI гасырга туры килгән буыннарында Таһир дигән исем очраса, андый фактлар шәҗәрәләрдә, һичшиксез, күренер һәм архив документларында да язылыр иде. Әмма шәҗәрә текстларында да, архивлардагы бер генә чыганакта да Бәзәкә авылын Нократ татарлары нигезләве генә түгел, ул ырудан кайчан да булса кемнеңдер монда яшәгән булуы турында һичбер төрле ишарә һәм дәлил очратканым юк. Андый дәлилләр А.Мәхмүтова китабында да күренми.

Альта Мәхмүтова китабында телгә алынган Таһир исеменә тагын бер игътибар итик әле. Бәзәкә авылының кульязма шәҗәрәсендәге бер битендә «Таһир баба

[5] А.В.Эммаусский. История Вятского края в XII-середине XIX века. – Киров, 1996. – С.43.

1545 елда вафат» дигән язудагы дата, безнең фикеребезчә, ялгыш. Гомумән, элекке татар кульязма шәҗәрәләрендә кешеләрнең туган һәм үлгән елларын язу гадәте булмаган. Бигрәк тә, XVI гасырда яшәгән затлар турында андый мәгълүматлар теркәлмәгән. Хәтта XVII гасырның икенче яртысында дөньядан киткән шәхесләрнең кабер ташлары сакланган булса да, шул ук авыл һәм нәсел шәҗәрәләрендә дә үлгән еллары язылмаган. Аерым шәҗәрәләрдә XVIII гасырның ахырындагы кайберәүләрнең вафат булу еллары теркәлгән аерым очраклар бар. Даталар әле XIX һәм хәтта XX гасырлардагы шәҗәрәләрдә дә киң кулланылмаган. Бәзәкә шәҗәрәсендә XVI гасырдагы төгәл ел күрсәтелгән дип фаразлаган очракта да, ул заманнарга бәйле еллар һиҗри – мөселманча гына, һичьюгы ике төрле – мөселманча һәм григорианча язылган булыр иде. Гомумән, Бәзәкә авылы шәҗәрәсе элекке кульязма нөсхәсе 1934 елда янып юкка чыккач хәтердән генә яңартылган вариант булганга, андагы башка хаталар һәм ялгышларның да күплеген истә тотып, 1545 дип язылган ел җентекләп тикшерелергә тиеш иде. Шулай ук Бәзәкәгә Алабуга янындагы Саралы авылыннан күчеп урнашкан борынгы бабайлардан алып һәм Саралыда яшәгән чорларына караган XVI гасыр архив документларында теркәлгән кеше исемнәре арасында Таһир дигәнне бер мәртәбә дә очратмадык. Бары тик Бәзәкәгә бәйле XVIII гасыр ахырындагы татарча документларда (мәсәлән, 1798 елда) Таһир Таймас улы дигән исем теркәлгән. Бу кеше һәм аның бертуган энеләре Бәзәкә авылының 1811 елгы исәп алу документында да язылганнар. Анда «Таир Таймасов» 44 яшьтә дип күрсәтелгән. Ә 1816 елгы җанисәп документында аның 1815 елда вафат булганлыгы искәртелгән. Нәкъ менә шул Таһир бабайның 1815 елда вафат булу датасының саннарын бутау аркасында шәҗәрә язмасына ялгыш 1545 дип куелган дип уйлыйбыз. Марсель Әхмәтҗанов китабында басылган «Бәзәкә шәҗәрәсе»нең эчтәлек өлешендә «36. Таһировлар, Габдуллин, Хәкимнәр» диелгән мәгълүмат бар һәм «XLIX шәҗәрә» исеме астында: «I буын. Таһир баба, 1546 елда вафат. II буын. 2. Тайгон, аның дәвамчылары – улы Бәхтияр, аның улы Гайнулла, аның улы Нуриәхмәт», – дип бирелгән[6]. Әлеге нәсел – 1811 елдагы исәп алуда теркәлгән Таһир Таймас улының тармагы. Ул нәсел А.Мәхмүтова китабындагы таблицада да (381 биттә, «Таймасов» урынына ялгыш рәвештә «Таймагов» дип) бирелгән.

Бәзәкә авылы тарихына бәйле архив документларында теркәлгән Тогайка Беляков исеме күптән түгел тагын бер мәкаләдә күренде[7]. Тарих фәннәре кандидаты Таһир Кәримов язган әлеге мәкаләдә күтәрелгән мәсьәлә бик актуаль һәм мөһим. Анда Ык елгасы буендагы авылларның әүвәлдәге «башкорт» сословиесенә нисбәтле булуына нигезләнеп, хәзерге башкорт галимнәренең ул төбәктәгеләр, имеш, чып-чын башкорт халкы дип саташуларын фаш итүгә багышланган. Әүвәлге «юрми» олысы Ык елгасының ике тарафына – хәзерге Азнакай районы һәм Башкортстанның Бакалы районы җирләренә туры килгән. Газета мәкаләсенең Таңай исеменә бәйле өлеше белән танышыйк (андагы кайбер мәсьәләләргә аерым аңлатмаларны ахырда бирербез):

*«...Юрми олысы җирбиләүчеләре турында элек тә «Материалы по истории Башкирской АССР» җыентыгында байтак мәгълүмат басылган иде. Әмма «История башкирских родов» сериясендә чыгарылган китапларның «Юрми» ыруына*

---

[6] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре: I том. – Казан: Татар. китап нәшр., 2012. – Б.357, 370. Мондагы 1546 ел дигәндә шәҗәрәдәге 1545 датасы ялгыш басылган.

[7] Кәримов Т. Татарларның Юрми олысы // Мәдәни җомга. – 2021. – 2 апрель (№12). – Б.8-9.

*багышланган 21 нче томында моңа кадәр билгеле булмаган бер чыганак дөнья күргән. Вотчинниклар саналган Сартай Диязбаев белән Тогай Беляковка багышланган документ аерым тикшерүне таләп итә.*

*Документ китапта «Юрмий волостендагы Казан башкорты Тогай Беляковның 1620 елгы шикаяте» дигән яңгыравык исем астында бирелгән. Беренчедән, чыганакның үзендә «юрми» сүзенә «й» өстәлмәгән, чынында сүз «Юрминск» олысында булган хәл турында бара. Икенчедән, чыганакта «Казан башкорты» дигән сүз дә юк, андый терминны комментарийларга гына өстәгәннәр. Ә архив фондының описендә документ «7134 (-5509 = 1625)[8] ел тәмамланып килүүңаеннан «чуаш» Урасай Тюкунов белән Ивашка Мордвиновка Ык елгасы буеннан вотчина, балык тоту урыны һ.б. гамәлләр өчен кишәрлекләр бүлеп бирү турында күрсәтмә» дип атала. Ул елларда Казан өязеннән күчеп килгән татарларны «чуаш» дип атаганнар.*

> «
>
> **Янә бер кабатлыйм: олыс исеме – ыру исеме түгел!» – дип, башкорт галимнәренең фальсификацияләрен ачык күрсәтеп язган.**

*Документта Казан өязендәге Җөри юлының Бәрсөт-Берсут авылындагы Тогай Беляковның Юрми волостенда вотчина тотуы турында хәбәр ителә. Вотчина аңа ерак бабасыннан ук калган була. Ул үзе дә Мәнәүс елгасы буена даими рәвештә килеп йөргән чакта куллану өчен йорт һәм мунча төзеп куйган. Олысның башка «башкортлары» шикелле, Уфа каласына сусар тиресе белән ясак түләп торган. Төп яшәү урыны Берсутта булганга күрә, Казанга да ясак түләгән, властьлар каршында башка бурычларын да башкарган. Бер үк вакытта Юрми олысында да мәҗбүри эшләрдә катнашу мөмкин булмаганга күрә, ул үзен монда олау белән ярдәм итү бурычыннан азат итүләрен үтенгән. Аның үтенече хаклы булуын искә алып, (Уфа) воеводасы Григорий Васильевич(?) Юрми олысы «старостасы» Сартай Диязбаевка әлеге вотчинникны «олау һәм хезмәтчеләр сорап» рәнҗетмәскә боерган.*

*1620 елда язган аңлатмасында Тогай Беляков үзенең Җөри юлында «чуаш» булып яшәвен хәбәр итә, әмма Ык ярында ерак бабасыннан калган вотчинасы булу сәбәпле, үзен «асабалар» катламыннан төшереп калдырмауларын сорый. Татар Тогайның хәйләкәрлеге, бинокльләр аша күзәтмәсәң дә, күзгә ташланып тора. Ләкин китапны төзүчеләргә Тогайны Җөри юлына барып кына йөргән «асаба башкорт» дип күрсәтү отышлырак. Аның фамилиясен һәм «асаба»лыгын кулланып, бөтен Юрми олысына «башкорт» исемен тагу, ә анда яшәүчеләрнең һәммәсен дә «башкортларның юрми ыруы» дип тамгалау файдалы. Шунысы гына сәер: алар ерак бабаларының йорт вә мунча төзеп «вакланмыйча», XVIII гасыр ахырына кадәр киез тирмәләрдә күчмә тормыш алып баруын гына бик тиз онытканнар...*

*Юрми олысына кайтсак, Мәнәүс елгасы Азнакай районы буенча үтеп, Әстәрлегә килеп кушыла. Шушы төбәктә Әгерҗе, Азнакай, Әстәрлетамак авыллары утырган. 1747 елда үткәрелгән II ревизия Казан өязенең Арча һәм Җөри юлларында яшәүче татарларның әлеге төбәккә массакүләм рәвештә күчеп утыруын рас-*

[8] Иске рус хронологиясендәге 7134 ел дигән дата бу очракта 1625 елга туры килә. Газетада ул «-5508 = 1622» дип ялгыш күрсәтелгән. Мәкаләдә әйтелгән 7134 ел ахырының хәзерге календарьга туры килүен билгеләү өчен 5509 саны киметелергә тиеш.

*лый. Аларны, беренче чиратта, Тогай Беляков кебек милләттәшләре чакырып китергәндер, дип нәтиҗә ясау нигезле. Элек «кыпчак җире» дип аталган төбәктә Туйкә, Балтач кебек авыллар үсеп чыга».*

Мәкаләнең авторы: «…олыс исеме белән бәйләп кенә, әлеге төбәктә яшәгән халыкларны ыруга әверелдерү – тарихи зур хата… Янә бер кабатлыйм: олыс исеме – ыру исеме түгел!» – дип, башкорт галимнәренең фальсификацияләрен ачык күрсәтеп язган.

Менә бу – газетада басылган архив документында Тогай Беляковның Бәрсөт-Берсут авылында яшәгәнлеге һәм «чуаш» итеп (ягъни дәүләткә ясак түләүче татар катлавында) теркәлгән дигәне Бәзәкә исеменең (рус документындагы «Безяк») әүвәлге канцелярия писарьләре тарафыннан ялгыш Берсут рәвешендә язылганнан чыккандыр дип уйлыйбыз. Ул чорлардагы административ бүленеш буенча әлеге авылларда (Бөрсеттә һәм Бәзәкәдә) яшәгән «ясаклы татарлар» бер үк Җөри юлына (даругасына) кергәннәр.

Кәримов телгә алган 1625 елгы архив документындагы Берсут атамасы Бәзәкә дигәннән үзгәртеп язылмаган булса, бәлки, Алабуга янындагы Саралы авылында яшәгән борынгы татарларның Кама елгасы буенда әүвәл биләгән җирләре көнбатышта шул Берсут елгасы буенча чикләнгәндер дип фаразларга мөмкин. Андый очракта Таңай Бигәш улы, чынлап та, хәзерге Мамадыш һәм Балык Бистәсе районнары чигендәге Берсут елгасы буена урнашкан татар авылларының берсендә вакытлыча (бәлки, берәр кардәшләре янында) яшәгәндер. Камага коя торган Берсут елгасы буенда Берсут-Сукачы, Югары Берсут (Югары Кыерлы) һәм Кама елгасы буендагы Берсут пристаненең атамалары әүвәлдән калган.

Архив документында Тогайка Беляков дип язылган кеше төп-төгәл Таңай Бигәш улы булганлыгына һичбер шик юк. Чөнки Т.Кәримов мәкаләсендә дә әйтелгән Ык буе биләмәсенең борынгы бабаларыннан ук килгәнлеге турында язган идек[9]. Ягъни, Саралы Мең ыруы татарларының Казан ханлыгы чорында ук (1523 елдан) Ык елгасы биләмәләре расланып, алар гасырлар дәвамында шуңа хокуклары өчен көрәшеп килгәннәр. Таңайның Бәзәкәдә яшәгән оныкларыннан Айман Йөзекәй улы һәм Айкилде Тәмәй улы 1696 елда үз биләмәләрен раслату өчен яздырып алган грамотада бабаларының әүвәлге җирләре дип «старинная де вотчина за ними деда Тогайки Белякова на речке Безяке и вниз по Каме реке» диелгәнен алдарак әйтеп үттек. Мондагы «Тогайка Беляков» – газета мәкаләсендә язылган шундый ук исемгә туры килгән адашлык очрагы гына түгел. Таһир Кәримов мәкаләсендә күрсәтелгән «Юрминск» волосте дигәннең дә нигезендә борынгы ыру исеме «мең» («мин») атамасы ята. Бәзәкәлеләрнең элекке бабалары Алабуга шәһәре янындагы Саралы авылында яшәүләренә һәм «мең» дигән әүвәлге ыру исеменә бәйләп, документларда «Саралы Мең» яисә «Мең» волосте дип теркәп йөртелгән.

Азнакай һәм Бакалы районнарындагы авылларга бәйле шәҗәрә язмаларында Саралы авылында яшәгән бабаларының 1643 елгы биләмә хокукын раслаган грамота турында мәгълүмат саклануы – югарыда әйтелгәннәрнең ачык дәлиле. Әйтелгән мәкаләбездә бу хакта да язылды[10]. Югарыда исеме күрсәтелгән Тогайка Беляковның үзенең һәм әтисенең чын исемнәре моңарчы «Безнең мирас»

---

[9] Мәрданов Р. Саралы Мең ыруы татарлары // Безнең мирас. – 2019. – №1. – Б.36-43; №2. – Б.26-31; №3. – Б.22-29.

[10] Шунда ук // Безнең мирас. – 2019. – №2. – Б.28-31; №3. – Б.24-26.

журналында басылган күләмле мәкаләбездә Таңай Бигәш улы рәвешендә телгә алынган иде[11]. Ул мәкаләдә төп яшәгән урыннары – Саралы авылына нисбәт ителеп Саралы Мең ыруы буларак билгеле борынгы татарларның Ык һәм Кама елгалары буенда биләмә тотканлыклары, 1523 елда Казан ханы Сахибгәрәй исеменнән бирелгән ярлык белән расланган җир-сулары 1562, 1567, 1574, 1577, 1580, 1595 нче елларда һәм аннан соңгы гасырларда рус патшалары тарафыннан да танылган булуы турында мәгълүматлар бирелде. Шул ыру кешеләренең Кама һәм Ык елгалары буйларында бихисап авыллар нигезләп яшәүләре, элекке җирбиләүче аксөяк затлары булганга һәм тарихи сәбәпләр аркасында «башкорт» катлавында язып йөртелә башлаулары, хәзерге Менделеев районындагы авылларда әлеге нәсел вәкилләренең XVII гасыр кабер ташлары, Кама һәм Ык буйларындагы авылларда шәҗәрәләре саклануы, шул рәвешчә күпсанлы архив мәгълүматларын башка чыганаклар тулыландыруы турында да бәян иткән идек. Төрле төбәкләрдә һәм төрле чорларда яшәгән Саралы Мең ыруы вәкилләренең нәсел тамгалары да бер үк төрле булуы һәм охшашлыгы, шулай ук башка дәлилләр дә китерелде. Мәкаләбездә Таңай Бигәш улы башка кардәшләре белән бергә Бәзәкә авылында 1639 елда яши башлаган дип язган идек. Ихтимал, анда элегрәк төпләнгән булганнардыр, ә рус документларында 1639 ел дип күрсәтелгәндер.

Моңа кадәр язганнарыбызга өстәп, рус телендәге архив документларында «Тогайка» дип теркәлгән исемнең татарчасы Таңай (Тагай) булып, ул Таңгатар (Таңатар) исеменнән кыскартылган, ә фамилиясе рәвешендә «Беляков» дип бик бозылган исем чынлыкта Бигәш булган. Шул бер үк кеше хакында сүз барган архив документларында әлеге Бигәш исеме төрлечә – Бегеш, Бимик, Билгик, Беляк рәвешләрендә теркәлгән. Болар исә бары тик канцелярия («приказная изба» һ.б.) писарьләре тарафыннан күчереп язганда бозганга гына бәйле. Русча архив документларында төрки-татар кеше исемнәренең һәм географик атамаларның танылмаслык дәрәҗәдә «гарипләндерелгәне» мәгълүм күренеш. Чагыштырмача соңрак чордагы шундый бозылган мәгълүмат Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм һәлак булган кешеләргә бәйле XX гасыр архив документлары белән эш йөрткән күпләргә таныш. Шунлыктан, элеккерәк гасырлардагы архив чыганакларындагы исем-атамаларның тагын да зәгыйфьрәк икәнлеген күзаллау читен түгел.

Бәзәкә авылы биләмәләренең бер өлеше әүвәлрәк Таңай исеменә нисбәт ителеп йөртелгәнен дә искәртик. Мәсәлән, хәзерге Менделеев районындагы Тагай исемле авылда XVIII гасыр урталарына кадәр мөселман татарлар яшәгән. Алар күчеп киткәннән соң, руслар һәм керәшен татарлары төпләнгән. Бу авыл тирәсендәге җир-сулар әүвәл Таңай Бигәш улы биләмәләренә кергән һәм аның исеме белән аталган булуы гаҗәп түгел. Шулай ук 1650 елгы архив документында Бәзәкә авылы биләмәсе даирәсендә «речка Казандыш, словет Тагаевская» дигән гыйбарә шуны дәлилли. Ул тирәдәге җирләр соңрак Таңайның улы Йөзекәй исеме белән бәйләп язылган. 1689 елда вафат булган шул ук Йөзекәйнең кабер ташы хәзерге вакытта да Бәзәкә авылының зиратында саклана. Аңарчы фәнгә билгесез булып килгән әлеге ташъязманы 2004 елда табып ачыклаган идем.

Таңай Бигәш улының хәзергәчә дәвам итеп килә торган күп тармаклы нәсел шәҗәрәсе дә эшләнгән. ■

---

[11] Шунда ук // Безнең мирас. – 2019. – №2. – Б.30.



II нче чакырылыш Дума депутатлары. Икенче рәттә уңнан өченче – Садри Максуди

# Садри Максуди: «Фәкыйрь булмыйк, бетәрбез!»

*Россия империясенең Дәүләт Думасы 1905-1917 нче елларда дүрт чакырылыш үткәрә. Әле яңа гына Париж университетын тәмамлап кайткан яшь сәясәтче Садретдин Максудов (Садри Максуди, 1878-1957) II һәм III чакырылышның әгъзасы була. Ул Дума трибунасыннан, Россия мөселманнарының хокукларын яклап, унбиш чыгыш ясый. Аның чыгышлары, мәкаләләре «Йолдыз» газетасында һәрдаим басыла. С.Максуди аларда милли проблемаларны күрсәтеп, чишү юлларын эзли, дәлилләр китерә һәм татар халкының якты киләчәген уку, белем белән бәйли. Депутат татар милләтен саклап калыр өчен милли икътисадны да үстерергә кирәк дип саный.*

*Игътибарыгызга С.Максудиның «Йолдыз» газетасында 1910 елда (№526. – 11 апрель; №528; – 15 апрель) басылып чыккан «Милли сохбәтләр (әңгәмәләр)» исемле мәкаләсен тәкъдим итәбез. Биредә ул татар халкы алга китә алмавының икътисадый сәбәпләре турында уйлана. Аяныч ки, Садри Максуди күрсәткән проблема һәм мәсьәләләрнең шактый өлеше бүген дә актуаль.*

Садри Максуди

# Милли сохбәтләр

## Заманыбызда хәят *(тормыш)* өчен көрәшүләр вә моңа милләтнең мөнәсәбәте

Һәр мәмләкәттә, һәр җирдә, һәрбер эштә дөньяда яшәр өчен көрәш бара. Хәят өчен көрәштә ошбу нәрсәләр мәгънәви хезмәт итәдер: дин, әхлак, гадәт. Болар инсаннар арасындагы хәят көрәшен бераз йомшата, инсаниятләндерә, бизәкли, ләкин бөтенләй бетерми.

Мәдәниятсез инсаннарда тормыш ихтыяҗлары аз була. Мәдәният тәрәкъкый иткән *(үскән)* саен адәм балаларының тормышлары төрлеләнәдер, хаҗәтләре күбәядер. Күп акча табу кирәк була, моның өчен күп эшләргә кирәк була.

Һәркем күп эшләргә, күп эшләп күп акча табарга һәм табып, яхшы яшәргә тырышадыр. Берәүләр акчаны күп, икенчеләре азрак таба, шулай итеп тормыш өчен көрәш мәйданга чыгадыр. Хәят көрәшүләрендә кемнең эшкә сәләте, ни эшли алуы артык булса, шул кеше җиңәдер. Эштә җиңү өчен эшлекле булу кирәк, ә моның өчен куәт булу, бу куәтне урынына сарыф итәргә гакыл вә фикер бердәмлеге кирәк. Мәдәният тәрәкъкый иткән саен, матди куәтнең әһәмияте азаядыр, мәгариф куәтенең роле зураядыр.

*Безнең халкыбыз бу хәят көрәшендә ни хәлдә? Бу көрәштә ул җиңелеп, егылып калмаячакмы?*

# Гомуми милләтләр арасындагы хәят көрәшләре эчендә безнең милләтнең хәле

*– Көрәш мәйданына атылырга куәтебез бармы?*

– Һич куәтебез юк! Ләкин, алай булса да, бу мәйданга атлаганнарыбыз теләр-теләмәс көрәшә алмасак та, тыпырчынырга мәҗбүрбез.

*– Куәтебез булмагач, тиз егылу ихтималыбыз юкмы?* – дисәк, моның да җавабы читен түгел:

– Без инде егылган, бары тапталып кына бетмәгән, актык куәтләребезне сарыф итеп тибрәнсәк, торырга, яңадан кеше шикелле көрәшә башларга ихтималыбыз бар. Әгәр егылган көенчә тагын бераз ятсак, тапталып изеләчәкбез – бу көн кебек ачык!

**«**

**– Без инде егылган, бары тапталып кына бетмәгән, актык куәтләребезне сарыф итеп тибрәнсәк, торырга, яңадан кеше шикелле көрәшә башларга ихтималыбыз бар. Әгәр егылган көенчә тагын бераз ятсак, тапталып изеләчәкбез – бу көн кебек ачык!**

***

Бу җавапларның һәрбере бераз озынрак аңлатылуны тели. Безнең милләт икътисадый җиңү коралына ия түгел, дидем. Бу ачык билгеле булса кирәк. Бу заманның икътисад мәйданында сугышу вә җиңү коралы нидер? Бу корал безнең халыкта бармы? Юк. Русиядә яшәгән мөһим кавемнәр арасында безнең төрек кавемнәре кадәр надан, мәдәниятсезе юк. Бу хакта, өмид итәм, шөбһә иткән кеше булмас. Мәдәнияттә без поляк, рус, әрмән, яһүдиләрдән артта түгел дип әйтү безнең хәлне әз генә дә яхшыртмый!

Икътисадый көрәш мәйданына атылырга куәтебез юк, дигән идек. Җиңү коралына ия булмагач, әлбәттә, мәйданга атылырга куәт булмыйдыр. Кылыч уены мәйданына кереп көрәшү өчен иң әүвәл кылычың булу кирәк. Кылычы булмаган кешегә бу мәйданга атылу файдасыз-мәгънәсез, көлке генә буладыр. Ләкин кылыч уены мәйданына, кылычың булмаса, кермәскә мөмкин. Хәлбуки, икътисад көрәшләре кылыч уены мәйданы кебек түгел. Бу сугыш мәйданы кебектер, җиңәргә теләсәң, өмет бирә торган коралың булса да, булмаса да, мәйданга керергә, көрәшергә мәҗбүрсең. Сугыш мәйданында дошман сиңа һөҗүм итүдән әүвәл: «Синең коралың миндә булган коралга тиңме?» – дип сорап тормыйдыр.

Шулай ук хәят вә икътисад мәйданында көрәшүчеләр: «Көрәшергә миндәге кадәр көч-куәт бармы?» – дип тә сорамыйдыр. Икътисадый көрәшүләр кылыч уены кебек ихтыярлы түгел, бәлки, мәҗбүри. Дошман синнән, көрәшәсеңме, дип сорап тормый, үзенең икътисадый укларын өстеңә яудыра башлыйдыр. Син теләсәң дә, теләмәсәң дә, булган кадәр ватык-сынык коралың белән айкарга, бер дә коралың булмаса, коры йодрыгың белән кизәнергә мәҗбүрсең, кулдан килгән кадәр өметсез бер хәлдә тыпырчынасың. Икътисад мәйданындагы көрәшүләр бик каты, бик рәхимсез. Бу хәлне аңламаган милләтләргә хәсрәт вә азагында бетү, инкыйраз килер.

Өченче җавабымда, безнең милләт икътисад җәһәтеннән егылган, бары тапталып кына бетмәгән дигән идем. Бу җавабым, фикерем бераз озынрак итеп, әтрафлырак язуны телидер. Чөнки чын хәлебез хакында бик күп фикер йөртмәгән кайбер оптимистлар безнең милләт ничек егылган дигән кебек игътиразлар *(каршы фикерләр)* әйтәләр. Шуның өчен бу хакта мисаллар белән, икътисад мәйданында без егылган икәнне күрсәтергә телим. Икътисад мәйданында егылган дип нинди кешеләрне вә нинди милләтләрне атарга мөмкин? Икътисад мәйданында егылган милләтләр шул милләтләр: кайсылары төрле гамәл-эш мәйданында иң авыр вазыйфаларны эшләп, иң аз файда күрәләр.

Икътисад мәйданында егылган милләтләр заманча көрәшә белмәгән, заманча эшне күп нәтиҗәле, файдалы итә белмәгән кавемнәрдер, заманча эшкә сәляхиятсез *(сәләтсез)* кавемнәрдер. Эшкә сәляхиятле булу ике нәрсәгә бәйле. Берсе – матди куәт, икенчесе – мәгънәви куәт, табигый гакыл вә кәсеби гакыл. Бу ноктадан караганда, җиңелгән, егылган милләт нинди милләт булыр? Без башка милләтләр илә көрәшү өчен башка милләтләр кадәр үк матди куәткә ия булсак та, мәгълүмат бездә башка милләтләргә караганда бик түбән яки бөтенләй юк. Шуның өчен без бу икътисадый көрәшү мәйданында егылган, ягъни һәр эштә бик авыр вазыйфаны өстебезгә алып, байтак матди куәт сарыф итсәк тә, эшнең нәтиҗәсендә бик аз файда күрәбез. Агачны без үстерсәк тә, җимешен башка милләтләр ашыйлар. Инде бу урында берничә төрле гамәл-эшне алып, безнең халык, иң авыр эшләрне эшләп тә, бик аз файда күрә килгәнен мисаллар белән күрсәтергә телим.

Иң гади мисал алыйк. Ашлык сәүдәсе. Безнең Волга буендагы никадәр авылларда, басуларда җәйнең яндырган кызу көннәрендә тирләп-пешеп никадәр авыл халкы чәчеп-сукалап ашлык үстерә, мәшәкатьнең ахырында, әгәр ел бәрәкәтле булса, бер-ике йөз пот арыш яки бодай аладыр. Моны көзге пычракларда төяп ерак шәһәргә алып барып сата да бераз акча хасыйл итә. Бу акчаның байтагын имана түләргә тота. Калганы кая китә? Бишмәтлек, күлмәклек, читек-кәвешлек һәм кәләпүшкә китә.

Икенче төрле әйткәндә, бу мужикның җан тирләрен чыгарып алган акчасы ситса-комач, постау ясаучыларга, читек тегә белүчеләргә, боларны сатучыларга китәдер. Мужик бөтен җәй тирләп-пешеп хасыйл иткән 100 пот бодаеның нәтиҗәсен шәһәрдә бер-ике көндә комаччы, кызыл малчы, читекчеләргә биреп бетерәдер. Бу саналган кешеләрнең һичберсе, мужик кадәр авыр эшләмәсәләр дә, бодайның нәтиҗәсеннән артыграк файдаланалар. Ник? Чөнки болар мужикка караганда үткенрәк, мәгълүматлырак: матди куәт бик аз сарыф итеп, гакыл вә белем илә аз-аз коралланып, күп файда күрү юлларын мужиктан артыграк беләләр, көрәшергә осталар. Тән куәте белән күп көчәнмичә, гакыл, осталык белән эш итәләр.

Шул ук икмәк, ашлык сату турында тагын бер мисал алыйк. Бер дә азапланмыйча, ничә мең мужик ашлыкларын башка кешеләргә кушып, үлчәп алдырып кына бер оста рус сәүдәгәре бер яһүди илә ничә мең сумнар файда итә. Ник? Чөнки ул мужиктан артык икмәкне ничек җыярга, кайда сатарга, кай вакытта сатарга, кайсы мәмләкәткә бирергә икәнен беләдер вә төрле мәмләкәтләрдә төрле сату юлларын, телләрне беләдер, сату-алу гыйлемендә күлдә йөзгән үрдәк шикелле йөзәдер. Бөтен нәтиҗәләрне алдан күрмәенчә, бер адым атламый, һәр эшне белеп-уйлап, карап эшли. Икмәк белән сату итүче яһүди бер Русиядә генә түгел, ә бөтен дөньядагы икмәк бәясен көн саен белеп-күзәтеп тора, шуңа сирәк вә аз ялгыша, аз зарар итә.

**Садри Максуди Дума депутатлары белән Англиядә. 1909 ел**

Кайсы дәүләттә ни чыкканын белгән кеше, һәрберсен алдан яхшылап хисаплый белгән, һәр мәмләкәтнең телен белгән европалы яки яһүди ашлык сәүдәгәре бөтен эшне дөрес йөртә, бик сирәк ялгыша. Инде шуның янына безнең милләттән булган ашлык белән сату итүче бер байны ал. Ул бичара нигә ышанып, ни хисапка нигезләнеп икмәк җыя? Кая сатарга уйлый? Берсен дә белеп эшләми. Аллага тапшырып, Василий алган бәягә, яһүд Соломон Гроссман биргән бәягә ул да җыя башлаган була, Гроссман бәяне төшерсә, ул да төшергән була…

Мин укучыны мисаллар белән ардырырга теләмим. Шулай да тагын берничә мисал китерәсем килә. Сезнең Русиянең күп сулы, матур шәһәрләрендә Волга-Камада пароходта йөзгәнегез бардыр. Пристаньнарда йөк ташучылар арасында милләт балаларыбызның беләкләрен күп күргәнсездер: көчлеләр! Таза-каһарман буларак, җилкәләренә бау салып йөк ташучыларны бурлак диләр.

Безнең халык Волгада пароходлар йөрүеннән бары бурлак булып кына файда итәдер. Волганың күп сулы булуыннан, монда күп пароход вә баржалар булуыннан башка төрле файдалану мөмкин түгелме? Әлбәттә, мөмкин, ләкин аннан Сафиулла Әхмәтҗанов файдаланмый, Любимов, Калинский, Булычев файдалана. Ник? Любимов, һич шөбһәсез, Әхмәтҗановтан белемлерәк. Бурлак мөселманда гынамыни? Руста юкмыни? Бар, әлбәттә. Бу хакта руслар алга киткән бер кавем түгел. Ләкин, русларда бурлак булса, пароход йөртүчеләре – капитаннары да бар. Бурлагы да, пароход хуҗасы да, капитаны да булу табигый хәл. Ә капитаны, пароход хуҗасы да, матрослары ду булмыйча, бурлагы гына булган милләтнең хәле уңайсыздыр!

Икенче мисал: менә Казанда, Алафузов заводында. Бу заводта меңнән артык кеше эшли. Моның һәрберсе дә простой рабочий түгел, боларның 100дән 6-10ысы кара хезмәтче булмыйча, чистарак эш күргән кешеләр: язучылар, конторщиклар һ.б. Болар, көчне азрак сарыф итсә дә, хезмәт хакын күбрәк алалар

– бу заводның агырак хезмәтен башкарып, бераз чибәррәк жалованье алган кешеләредер, әмма алар арасында мөселманның һичбер кешесе юк. Ник болай? Чөнки ак хезмәтләр белү мәгълүмат иясе булуны телидер, моның өчен азмыкүпме укыган булырга тиешле. Безнең бичара халыкта бу нәрсә юк, шуның өчен без заводта бары авыр эшләрне эшләргә генә ярыйбыз. Завод-фабрикаларда рус байлары миллионнар казанган вакытта, рус приказчиклары меңәр сум жалованье алган вакытта безнең агайлар көненә илле тиен белән калалар. Чөнки наданнар, мөселман булгач, укымасаң да ярый дип беләләр.

Университетта укытучылар – руслар, идән себерүче, мичкә ягучылар – мөселманнардыр.

Бу мисаллар минем бер фикеремне куәтли. Мин әйткән идем: без, мөселманнар, икътисад мәйданында егылганбыз, дип. Егылган милләтләр һәр эштә иң авыр вазыйфаларны өстенә алып, нәтиҗәдә, аз файда күргән милләтләр, дидем. Икътисад мәйданында егылган милләтләр – заманга туры китереп көрәшә белмәгән милләтләр, күп файда итә белмәгән милләтләр, заманча эшне күп нәтиҗәле, күп файдалы итә белмәгән милләтләр, эшкә, хәяткә сәләтле булмаган милләтләр, дидем. Безнең милләт нәкъ икътисад мәйданында егылган, заманга яраклы итеп көрәшә белмәгән, күп җәфаланып та аз файда күргән бер милләт, дидем.

Безнең халык һәр эштә иң авыр хезмәтләрдә булса да, мәшәкать, зәхмәтләреннән файда бик аз ала. Иген эшеннән тирләп иген иккән мөселман файдаланмый – Гроссман күбрәк файдалана, пароход эшләреннән татар файдаланмый – Любимов, Калинскийлар файдалана, заводлардагы вак хезмәттә мөселманнар бик аз файдаланганда завод хуҗалары булган руслар миллионнар ясый, профессорлар меңнәрчә жалованье алганда, татар сторожлары 15-20 сум гына ала.

Нинди генә мисал китерсәк тә, без, мөселманнар, һәр җирдә иң ямьсез, иң авыр хезмәтләрдә эшләсәк тә, бик аз хак алабыз, бик аз файда күрәбез. Чөнки мөселманнар эшне күп файдалы итә алмыйлар. Ник алай? Чөнки мөселманнар эшне күп нәтиҗәле итү коралына, бу замандагы икътисадый сугышларда җиңү коралына ия түгел.

***

*– Бу заманның икътисад мәйданында көрәшү вә җиңү коралы ни ул?*

– Бу икътисад мәйданында җиңү коралы – уку, белү, мәгълүмат. Болар мөселманнарда юк. Моннан ни килеп чыга? Без икътисад ягыннан фәкыйрь, егылганбыз, чөнки бу заманда башка милләтләр белән көрәшеп җиңәргә куәтебез юк, белемебез юк, укымаганбыз. Надан кавем һәрвакытта икътисад җәһәтеннән егылырга мәҗбүр. Әгәр бу кавем шушы юлын дәвам итсә, наданлыктан чыгарга тырышмаса, бу кавем, бу милләт икътисад җәһәтеннән изелептапталып бетәчәктер.

Икътисад җәһәтеннән изелү милләт җәһәтеннән бетә башлауның башыдыр. Башы гына да түгел, уртасыдыр. Шуның өчен, әгәр миллият җәһәтеннән югалып китәсебез килмәсә, икътисад җәһәтеннән көчле булырга тырышыйк! Икътисад җәһәтеннән көчле буласыбыз килсә, заманча көрәшергә өйрәник. Заманча көрәшә беләсебез килсә, укыйк, мәгълүмат тәхсил итик *(өйрәник)*, укырга тырышыйк. Надан булмыйк, фәкыйрьләнербез! Фәкыйрь булмыйк, бетәрбез! Укыйк, зинһар, милләттәшләр, бетмик!

*Кереш мәкалә һәм текстны **Миләүшә Гайнанова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# Мамадыш җырулары

## «Ак та пәкеләрне мин сапладым»

*Җырак бабам Арсентий Егоровтан (1903 елгы)*

Ак та пәкеләрне мин сапладым
Мәчет манарасын сырларга.
Уникедә җыруымның берсен куйдым
Сез туганнарга дип җырларга.

Иртәләрдән торып ипи бастым,
Арышыннан түгел, бодайдан.
Сезнең исәнлекләрне без сорыйбыз,
Иртән иртүк торып Ходайдан.

Урман авызлары, әй, тар авыз,
Юкә чәчәккәе балавыз.
Сагынганнар саен күрешергә
Җыраграк безнең арабыз.

Түгәрәккәй куак башы уак,
Мәк чәчәккәенә охшаулы.
Әй, җөзләргә бер, меңгә икәү
Безнең туган айга охшаулы.

Урман буйларында, әй, имәнлек,
Имәнлек буйлары, әй, игенлек.
Игеннәрне бергә, әй, игәек,
Гомерләргә бергә җөриек.

Бәйрәмнәрдә без җөриек,
Ике кулыбызга гөл учлап.
Сез дуслар белән бер күрешкәч,
Калыр инде күңел тынычлап.

Килсение болыт, яусын яңгыр,
Яусыные болын буенда.
Сезнең белән безнең йөрешүләр
Барсыные гомер буена.

Кара урманнарның, әй, артында
Карчыгалар канат кагынган.
Очкылыклар тотса, тот исеңдә,
Без булырбыз сезне сагынган.

## «Ай, әйтәмен, туганнар..»

*Җырак әбием Анна Герасимовадан (1904 елгы)*

Түшләренә таккан биш тәңкәнең
Чәнчелмәгән җире бер дә җук.
Килгәннәрдән бирле карап торам:
Килешмәгән җирегез бер дә җук.

Ал кирәкмәс безгә, гөл булгач,
Җат кирәкмәс безгә, сез булгач.
Ай, әйтәмен, туганнар, ай, әйтәмен,
Ак укадин үргән кәйтәнем.

Андыйдин да мондыйдин мин әйтмимен,
Җаным сөйгән буенча мин әйтәмен.
Минем чәчкәйләрем бигрәк озын,
Ука белән кушыпдин аны үрәмен.

Китмәгез, туганнар, күз алдыннан,
Күргән саен күрәсем бик килә.
Ашны ашап булмый әйрәнсез,
Җырлап җөреп булмый бәйрәмсез.

Инде бетте әйтер сүзләрем,
Күреп туймый ике күзләрем.

*Язып алучы: Степанова Анфиса Ивановна*
*(1971 елгы). Ташлыяр авылы*

*Текстларны журналга **Гөлфинур Дувалова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# Владимирда Василий Тимофеев эзләре

Лидия Пасыева

Владимир авылы күренеше

Керәшеннәрнең беренче священнигы, мәгърифәтче Василий Тимофеев Владимир авылында 1865 елда була. Ул анда бер ай чамасы яши, халык белән аралаша. Василий Тимофеев халыкка Казан Үзәк керәшен мәктәбендә укучы ир балалар белән керәшенчәгә күчерелгән иман кенәгәләреннән өзекләр укып күрсәтә, мәктәп турында сөйли. Ул авылдагы балаларны керәшен букваре белән дә таныштыра. Әлбәттә, бу очрашу нәтиҗәсез калмый. Берникадәр вакыттан соң Владимир авылының малай һәм кызлары Казандагы Үзәк керәшен мәктәбен бетереп, үзләре дә төрле җирдә балалар укыта яисә приходларда священник булып эшли башлыйлар. Кызганыч ки, бу балалар турында әлегә кадәр берни дә мәгълүм түгел. Бары тик Изге Гурий туганлыгы хисабыннан гына 1877 елда – Сергей Кузьмин, 1888 елда Степан Тупай исемле үсмерләрнең Керәшен мәктәбен тәмамлаганын беләбез. Владимирда Кузьмин фамилияле кешеләрне инде белүче юк, ә менә Тупаев фамилиялеләр күп.

Василий Тимофеев үзенең истәлекләрендә Владимирда булуы, ул авылның зурлыгы турында яза. Чыннан да, нибары бер урамлы, әмма 3 чакрымга кадәр сузылган булган ул. Халыкның руслар йогынтысыннан аерылганын, укый-яза белүчеләрнең юклыгын да күрсәтә. Монда элекке мәҗүси йолалар өстенлек итүенә һәм авыл халкының күрше-тирәдәге мөселманнар белән мөнәсәбәтенә дә игътибарын

юнәлтә. Бу вакытта авылда 70ләп йорт була, анда иске керәшеннәр яши, халык элеккеге традицияләргә, гореф-гадәтләргә тугрылык саклый.

*«...Когда мы въехали в деревню Владимирову, попалась нам на встречу много женщин, одна за другой; они несли в руках чашки, покрытые салфетками. Я просил своего проводника: что это такое у вас было? Он ответил: сегодня у нас женщины совершают моленье об урожае кудели, льна, конопли и т.п.*

*– Как же совершают? – спросил я.*

*– А вот как. Бабы утром советуются и согласятся между собою; а около обеда искупаютися в реке, наденут чистое бельё, потом всякая несёт в чашке муки, яиц, коровьего масла и варят из всего этого сборного материала болтушку. И молятся о куделе. Тут собирается весь женский пол, а мужчин не бывает. Сядут и едят болтушку; оставшиеся несут в чашках домой, чтобы домашние также поели моленной болтушки»* – дип яза ул.

Василий Тимофеев истәлекләрендәге гореф-гадәтләр бүгенгәчә сакланган. Әбиләр сөйләвенә караганда, су буенда мул уңыш теләү йолалары җәй айларында еш булып торган. Аның беренчесе оннан ясалган боламык белән уздырылса (Василий Тимофеев нәкъ менә шул вакыйганың шаһиты булган, шулардан чыгып, кайсы айда килүен дә белергә мөмкин), икенчесе – ярмалардан пешерелгән боламык – мул уңыш теләү йоласы. Бу йола авылның әбиләре тарафыннан хәзер дә «Корман ашы» *(ягъни корбан ашы. – Ред.)* исеме белән уздырыла.

Тимофеев истәлекләре белән танышуны дәвам итик: *«... После обеда, с двумя мальчиками, я отправился на гору, отстоящую от деревни верстах в двух. На горе прежде был лес, теперь же она обращена в поля и пашут, но впрочем, лес не весь ещё расчищен. На той горе есть источник.<...> Я пришёл туда по рассказам жителей деревни. Они говорят, что этот бугорок каждого дня поднимается по немногу, как будто растёт, поэтому думают не похоронен ли тут какой угодник. Там приносят жертву о хлеборождении, режут белого быка, варят мясо и кашу. И магометане приходят на это место, делают свои намазы».*

**Изге чишмә**

Әйе, монда Владимир авылы халкына бик таныш булган Изге чишмә – Биек тау чишмәсе турында сүз бара. Халык телендә бүген дә изге кабер барлыгы турындагы сүз йөри. Шулай булмаса, чишмә тау башыннан түгел, ә тау астыннан бәреп чыгар иде, дип әйтә халык. Изге чишмә турында минем дә Федора түти Бахрова һәм Марҗый түти Такмиевалардан (алар инде мәрхүмәләр) сораштыргалаганым булды. Тимофеев язмалары белән танышканчы ук, алар миңа безне әби-бабайларыбызның Югары, Кече Сон мөселманнары белән бергә җыелып, корман – ак үгез чалулары турында сөйләгәннәр иде.

Биек тау чишмәсендә теләнгән яңгыр барыбер ява дигән ышану бүген дә яшәп килә. Күрше-тирә татар авылларыннан әле дә (һәрхәлдә, колхозлар таралганчы) корман *(корбан)* чалу өчен сарык алалар. Хәтта 2010 елның коры җәендә дә, бу йоланы башкарганнан соң, болыт чыккан һәм яңгыр яуган.

**Владимирның элекке чиркәве (хәзерге клубы)**

***

Әлбәттә, Василий Тимофеевның Владимирга килүе эзсез генә калмый. Изге Гурий туганлыгы 1869 елда авылдагы ир балалар өчен мәктәп ача. 1899 елда анда 36 малайны Колышчы авылыннан килгән, Үзәк керәшен мәктәбен тәмамлаган Иван Матвеевич Усачев укыта.

Кызлар өчен мәктәп 1897 елда эшли башлый. 1899 елда анда 21 кыз бала белем ала. Укытучылары Чия башы авылы кызы Праскофья Захарова була. 1899 елда Владимирда 143 хуҗалык исәпләнеп, анда 426 ир-ат һәм 441 хатын-кыз яшәгәнлеге билгеле. Бу саннардан күренгәнчә, кыз балаларның бик азы гына керәшенчә укырга-язарга өйрәнгән.

Ә Владимирда бер престоллы чиркәү 1890 елда төзелә башлый, ул 3 ел эчендә төзелеп тә бетә. 1897 елга кадәр аның беренче настоятеле Семен Гаврилович Гаврилов була. Шуннан соң, 1912 елга хәтле А.А.Миропольский священник булып тора. 1930 нчы елларда, чиркәү ябылганда, священник булып Игнатий атакай эшли.

Владимир чиркәве 1893 елда төзелеп бетсә, күрше Албай чиркәве 1873 елда, аннан 20 ел алданрак салына. 1874 елда Албайда чиркәү ачылу тантанасына Николай Иванович Ильминский үзе килә. Шул вакытта ул Югары Әрнәштәге ир балалар өчен мәктәп ачу тантанасында да катнаша. Алай гына да түгел, балаларга бер ай буе үз дәресләрен бирә, монда Лаеш өязенең Үри авылыннан килгән укытучыларны да укыта. Алар арасында Владимир кешесе Василий Такмиев та була.

***

Дин әһелләренең чиркәүләр ачуы, керәшен телендә әдәбият таратуы эзсез югалмый: келәүгә йөрүчеләрнең саны арта. Шуңа да карамастан, авыл халкы гасырлар буе сакланып килгән борынгы йолаларына да тугры кала, ата-бабалары рухына «корман» чала, Изге чишмә буенда гыйбадәт кыла. ■

# Ижау каласын ямьләгән якташыбыз

Рәйсә Муллахмәтова

**Рәссам Владимир Захаров янында. Ижау**

*Күптән түгел Ижауда яшәүче рәссам, якташыбыз Владимир Захаровта кунакта булып кайттым. Инде 80 яшен тутырса да, хәзер дә иҗат итүче, төрле күргәзмәләргә чакырылып хөрмәт ителүче шәхес ул. Аның исеме районыбызда моңарчы ишетелгәне юк иде әле.*

Әнисе В.П.Зелинова портреты

Әтисе И.С.Захаров портреты

## Бер фото тарихы

В.И.Захаров туган-үскән җире Шәдчебашы (Старое Мочалкино) белән Уткиноны бер дә исеннән чыгармый. Ял вакытларында, бәйрәмнәрдә авылына, туганнары янына кайта. Яраткан математика укытучысы, хезмәт һәм сугыш ветераны Вагыйзә Хөснетдинованың хәлен белергә Вахитка да төшә иде. Аны бик хөрмәт итте ул. Укытучысы авылда гына түгел, районда да танылган педагогларның берсе, милли мәгарифебез үсешенә зур өлеш керткән шәхес булды. В.И.Захаров соңгы кайтканында, рәсем сәнгатендә ветеран шәхес образын күрсәтү өчен, аннан портретын ясарга рөхсәт сорый. Кызганыч ки, укытучысы риза булмый. Үзен озатырга чыккач, фотога төшүен үтенә. Ул фото хәзер дә саклана.

## Онытылмаслык балачак...

1937 елның 17 ноябрендә Тәкәнеш районының Шәдчебашы авылында икенче малай булып дөньяга килә ул. 1938 елда гаилә Уткино авылына күченә. Әтисе Иван Сергеевич Захаров, әнисе Варвара Павловна Зелинова колхозда хезмәт куя. Гаиләдә өч бала: Семен, Володя һәм Анастасия. Володя үзенең балачак елларын искә алган вакытта: «Әтиемне бөтенләй дә хәтерләмим диярлек. Бары тик ике эпизод кына исемдә калган. Мине ул үзенең җилкәсенә утырта иде дә өй буйлап ишектән тәрәзәгә таба йөри иде. Йөгереп тә, сикертеп тә ала иде. Ә мин шуңа

чиксез шатлана идем. Ә икенчесе – аның йөк төягән арба белән ишегалдына керүен күзәтүем...» – ди. Әтисе һәм әнисе хезмәт сөючән, үз чорының тырыш колхозчылары булалар. Иван Захаров сугышның беренче көннәреннән үк үз теләге белән сугышка китә. 1941 елның 26 ноябрендә дәһшәтле Ленинград яны сугышында мәңгелеккә күзен йома. 4 яшьлек Володя, кечкенә булса да, хат ташучы әтисенең үлеме турында кара пичәтле хәбәр алып килгәнен төгәл хәтерли. Бу хәвефле тынлыкта барысы да елый. Әлеге похоронка хәзер дә абыйсы Семенның төпчек улы Юрийда саклана. Володяга да шуның күчермәсен җибәрә. «Вакытлар узу белән тагын да таушалган, гаиләбезне ятим иткән үлем турындагы похоронканы кулыма алып, һәр юлын укып чыгам, балаларыма һәм оныкларыма, хәзер инде онықчыкларыма күрсәтәм», – ди ул. Иван Захаровның абыйсы да була. Ул да сугышта һәлак була.

## Тамак гүргә кертә...

Әнисе өч бала белән тол кала. Өйдә балаларның үзләрен генә калдырып, көне-төне эшли ул. Аларны ачлыктан саклап калу өчен Варвара түти кесәсенә бер уч бодай салган була. Әмма әниләре өйгә кайтып җитә алмый, аны кулга алалар. Ярсып елавына, ялынуына карамастан, Мамадыш төрмәсенә озаталар. Балалар берүзләре кала. Ярый әле авылда әби-бабай бар. Алар үзләре дә ачлыктан интегә... Шул китүеннән әниләре ел ярым үткәч кенә кайта. Ачлыктан бик авырлык белән генә исән кала алар. Сеңлесе Настя авырып, шешенә дә үлеп тә китә. «Ул шешенде, шешенде дә үлеп китте», – дип сөйләгән олы абыйлары Семен кечкенә Настяның үлеме турында әнисенә. Абыйсы Семен 12 яшьтән колхозда эшли башлый.

1945 елның көзендә, 8 яше тулгач, Володя мәктәпкә укырга керә. Яхшы укый, күбрәк рәсем ясарга ярата. Колхозда эшләп тормыш алып бару авыр булгач, 1949 елда әнисе, ике баланы алып, урман хуҗалыгына күчеп китә, урман кисүдә эшли. Иртәдән кичкә кадәр аударылган агачларның ботакларын чаба, баракта яшиләр. «Бер елдан яңадан авылга кайттык», – дип дәвам итә Володя.

## Максатчан яшьлек

Булачак рәссам Казан сәнгать училищесына укырга керергә теләк белдерә. Әнисе каршы килми. Бөтен имтиханнарын да яхшы билгеләренә тапшырып, конкурстан үтеп, беренче курска кабул ителә ул. Кызганыч ки, әнисенең улын укытырга мөмкинлеге булмый. Шулай итеп, Володя 1957 елда урта мәктәпкә укырга бара һәм аны уңышлы гына тәмамлый. Декабрь аенда Володяны Совет Армиясенә алалар. Өч ел хезмәт итеп, 1960 елда туган авылына кайта. Бер ел клуб мөдире булып эшли. Рәсем сәнгатенә мәхәббәте бер дә кимеми. Володяның кулына карандаш һәм буяулар эләккән саен, аның белемгә омтылуы көчәя генә бара. Барлык авырлыкларны җиңеп, 1961 елда Владимир Захаров Ижевск шәһәрендәге Удмуртия педагогика институтының сәнгать-графика бүлегенә читтән торып укырга керә. 1967 елда аны тәмамлап, рәсем, сызым һәм хезмәт укытучысы дипломы ала.

Укыган вакытта ук ул иптәшләре белән «Машиностроитель» мәдәният сараенда урнашкан сәнгать студиясенә йөри. Шунда рәсем, сынлы сәнгать, композиция серләренә төшенә. Әлеге чорда изостудия укытучылары һәм студентлары сәнгать темасына әңгәмәләр уздыра, иҗади эш буенча фикер алыша, пленарларга йөри,

күргәзмәләр оештыра, сәнгатьтә яңалыклар уйлап табу алымнарының яңа ысулларын эзли. Үзе белән бергә эш башлаган рәссамнар арасында актив, булдыклы Валерий Кононов, Петр Коняшин, Василий Герасимов, Александр Мартынов, Федор Мерзляков, Юрий Кулышевлар була.

Владимир Захаров бу чорда уку белән эшне бергә алып бара. Ижевск шәһәренең «Спартак» һәм «Дружба» кинотеатрларында рәссам-оформитель булып эшли. Аннан Механика институтына китә. Анда 1 Май, Җиңү көне, Октябрь демонстрацияләренә, коммунистик субботникларга бәйрәм колонналарын бизи. Аның ярдәме белән институтның уку корпуслары да бәйрәм төсен ала.

## Үсеш юлында

1967 елда ул фикердәше һәм рәссам, укытучы, яшь, чибәр, шәфкатьле, кайвакыт таләпчән дә һәм эшенә бик җаваплы караучы Анна Дмитриевна Шевгенюк белән гаилә кора. Хатыны – иҗатындагы барлык башлангычларында терәк һәм ярдәмче. Захаровлар гаиләсендә бер-бер артлы ике малай – Олег һәм Павел туа.

1977-1996 нчы елларда Владимир Захаров Ижевск иҗат мастерскойларының Сәнгать фондында эшли. Шәһәрнең матурлыгы, архитектурадагы эстетикасы өчен җирле рәссамнар көче белән бик күп эшләр башкара. Ижевск шәһәренең бик күренекле урыннарында аның хезмәтләрен күрергә мөмкин. Мисал өчен, Механика заводы бинасы фасадындагы мозаиканы, Пионерлар Сарае фасадын, 4 нче профессиональ-техник училищеның вестибюлен эшли. Рәссам көче белән эшләнгән төрле масштабтагы пыяла витражлар композициясен «Ижевск» ресторанында, Төньяк базарның павильонында, тимер юл вокзалының пассажирлар залында, Радиозавод ашханәсендәге витражда, Сарапул шәһәренең балалар бакчасында, «Платформа» спорткомплексындагы «Октябрь» кинотеатрында, «Металлург» шифаханәсе фойесында тамаша кылырга була.

## Гамьле әңгәмә

Туган авылын хәзер дә еш искә төшерә Владимир Иванович. Петр Иванович Иванов эшләгән вакыттагы мәктәп тормышы, фермаларның мал белән тулы чаклары турында сөйләде ул. «Бик хөрмәткә лаек шәхес иде!» – ди аның турында. Абыйсы Семен белән дуслар булуын да искә алды. Мамадыш районында хакимият башлыгы аның уртанчы улы Анатолий Петрович икәнлеген белгәч, бик шатланды. «Мин аны хәтерләмим шул инде. Үземнең яшьрәк чактагы рәсемемне җибәрим әле истәлеккә. Бәлки, мине танып, искә алыр», – дип, үзенең портретын бирде. Сурәткә карап, сокланып торганда, миңа да натюрморт ясалган бер картина бүләк итте. Дөрес, ясалган портретлары, картиналары, натюрмортлары бихисап рәссамның. Алар арасында авылына кайткан чакта, аерым битләргә графика белән ясалган авыл табигате күренешләре дә бар...

Владимир Иванович хәзерге көндә олы улы Олег белән яши. Ул да сәнгатькә гашыйк. Бүлмәсенең стенасы тулы картиналар.

Рәссам – рәссам инде! Үз бүлмәсендә мольберты тора, аның янында өстәл тулы төрледән-төрле буяулар тезелеп киткән. Нинди генә пумалалар юк анда... Анна Дмитриевна белән Владимир Иванович эш кораллары турында сөйләгәндә яшәреп, җанланып китте. Өлкәннәребезгә матур картлык теләп, без кайтыр юлга кузгалдык. ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# Аның тырышлыгы белән тоткыннар азат ителгән

**Николай Михайлов**

*Мамадышның Бөек Ватан сугышына багышланган һәйкәлләр комплексында тагын бер бюст пәйда булды. Ул – легендар якташыбыз, илебезнең Баш хәрби прокуроры булган Николай Афанасьев бюсты.*

*Аны ачу тантанасында Татарстан Республикасы Президенты **Рөстәм Миңнеханов,** Үзәк хәрби округның хәрби прокуроры, юстиция генерал-лейтенанты **Александр Антюфеев,** Николай Порфирьевичның оныгы **Татьяна Соколова** катнашты.*

**Китапханәче Лилия Шәрифуллина, баш архитектор Рамил Миннеханов, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, язучы Рафаил Газизов**

*Фотолар https://president.tatarstan.ru/ сайтыннан алынды.*

## Мамадыштан башланган юл

Данлыклы якташыбыз үзенең тырышлыгы белән Октябрь инкыйлабыннан соң гади делопроизводительдән алып илнең Баш хәрби прокуроры дәрәҗәсенә күтәрелгән шәхес бит. Мондый хөрмәткә, игътибарга аның рухы лаек булган, дип әйтергә тулы нигез бар. Узган гасырның утызынчы еллар азагындагы репрессия чорларында аның тырышлыгы белән Татарстанда бер гаепсезгә кулга алынган күпме галим, сәнгать эшлеклесе, хәрбиләр, районнарның партия комитетлары секретарьлары тоткынлыктан азат ителгән. Аларны азат итүне сорап халыклар атасы Сталинга мөрәҗәгать итү ул чагында зур батырлыкка тиңләнгәндер. 1940 елда үзенә Кызыл Армиянең Баш хәрби прокуроры вазыйфасын тәкъдим иткәч, ул аны башкарырга әле әзер түгеллеген тәҗрибәсенең аз булуы белән аңлата.

**« Узган гасырның утызынчы еллар азагындагы репрессия чорларында аның тырышлыгы белән Татарстанда бер гаепсезгә кулга алынган күпме галим, сәнгать эшлеклесе, хәрбиләр, районнарның партия комитетлары секретарьлары тоткынлыктан азат ителгән.**

Бюстны каплаган ак бәзне алуга, Рөстәм Миңнеханов, Александр Антюфеев һәм мәртәбәле кунаклар аның янына чәчәк бәйләмнәре салдылар. Республикабыз Президенты үзенең чыгышында Н.П.Афанасьевның данлыклы юл үтүен ассызыклап үтте.

*– Әлеге тантанада катнашу безнең барыбыз өчен дә зур мәртәбә ул. Николай Порфирьевич – гадәти булмаган тормыш юлы узган шәхес. Аның исеме илебезнең хәрби прокуратурасы тарихы битләренә алтын хәрефләр белән язып куелган. Аның Ватанга эчкерсез хезмәт итүе мисалында без яшь буында туган җиргә, Ватаныбызга мәхәббәт тәрбияләргә тиешбез. Николай Афанасьевка һәйкәл ачу җинаятьчеләр белән көрәшеп җәмгыять мәнфәгатьләрен яклаучыларны искә алу гына түгел, прокуратура органнарына килгән яшьләр өчен дә үрнәк булып тора. Бүгенге вакыйга күркәм традицияләрнең саклануын, аларның буыннан-буынга тапшырылуын исбатлый,* – диде ул.

Үзәк хәрби округның хәрби прокуроры Александр Антюфеев үзенең чыгышында Николай Афанасьевның исеме 1942-1945 елга чаклы җитәкләгән тимер юл транспорты Баш хәрби прокуратурасын оештыру белән тыгыз бәйләнгәнлеген ассызыклап үтте. *«Аңа бюст урнаштыру – Николай Порфирьевичның тормыштагы батырлыгына, Ватан һәм халкы өчен үз-үзен корбан итүенә югары хөрмәт күрсәтү билгесе ул»,* – диде Үзәк хәрби округның хәрби прокуроры.

## Музей бүләкле булды

Якташыбызның оныгы Татьяна Соколова әлеге һәйкәлне булдыруга өлеш керткән һәркемгә, иң беренче чиратта, илнең хәрби прокуратурасы җитәкчелегенә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка, Мамадыш муниципаль районының башлыгы Анатолий Ивановка, скульптор Алексей Чебаненкога рәхмәтләрен ирештерде.

*– Минем бабамның буыны гадәти буын булмаган. Аларга башларыннан күп авырлыклар кичерергә туры килгән: Гражданнар, Бөек Ватан сугышлары... Шулай булуга карамастан, алар тормышны ярата, оптимистик рухны саклый алганнар,* – диде ул.

Татьяна Николаевна аннары Мамадыш төбәкне өйрәнү музеена бабасының көндәлеген бүләк итте. Кунагыбыз үзенең чыгышы ахырында мамадышлыларга рәхмәтләрен саф татарча ирештерде.

Сынның авторы – скульптор Алексей Чебаненко. Чыгышлар тәмамлангач, Казан һәм Татарстан митрополиты Кирилл бюстны изгеләндерде. ■

# КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

## СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

## Ач ятимнәр

*(Үткән елгы ачлык күренешләреннән)*

.............................................

**Кави Нәҗми**

Йөзләренә карама! Балчык белән сыланган, кансыз йөзләрдә барыбер шатлык эзе күрмәссең.

Карыйсың киләме? Җә, кара! Күрәсең? Кипкән имән чыбыкларына охшаган бармаклар бизгәк тоткан кебек калтырыйлар. Маңгаендагы җыерчыклар көннән-көн үсеп зураялар. Ә еллар буенча май кисәге күрмичә ярылган йөрәкләрендә мең төрле хыяллар челтәре тукыла.

Төпсез базның капкачындагы тишекләр кебек каралып торган күзләре каршыдагы йортның югары катындагы тәрәзәләргә текәлделәр. Анда... тук кешеләр. Җылы икмәк, кайнар чәй! Ә без такыр даладан китергән курайларны кибәк кушып ашый идек. Әле ул да юк.

Беләмсең, туган, аларны кайдан китерделәр? Алар йөзләп яталар иде монда. Картлар кебек кайгырырга өйрәнгән бу балаларның кайберәүләрен төрле кешеләр үзләренә дә алдылар. Йә тузган яулыклы карчык, йә иске камзоллы абзый җитәкләп китә. Алар, өйрәнмәгән иркәләү исенә чорналып, алып китүчеләргә ышанып баралар.

Саташу эчендә кайнаган өмидсез тормыш та табигый булып күренә.

Иртәгә иске чүпрәкләргә төренгән арык балаларны тагын да вокзалдан утын урынына ташыйлар.

Аһ... Карама күзләренә. Юкса һәрбер тамган күз яше сине каргап җиргә сеңәр.

Аталарының, туганнарының кайда икәнлеген дә сорама! Көмеш кебек чарылдаган көлү тавышлары белән алсу яңакларның нигә үзгәрүен дә сорама! Ул көннәр – ямьле-бәхетле көннәр, кояш нурларына чолганып, бәйләнешсез бер әкияткә әверелделәр. Ул тормышның чуар күренешләре дә бер якынаеп, бер ерагаеп җемелдәгән мәңгелек төш кебек күз алдында чуалдылар.

Тик әти-әниле тормышның шәүләсе генә ач ятимнәрнең артыннан куып, бушлык аркылы алҗыган күңелләренә сагыну катыш кайгы сирпи.

Ачлык, җылы мәетләр кимереп, арттa калды. Айлар буенча саргаеп йөргән битләрнең күбесендә яңадан туклык каны шаяра. Туклык эченә чумган күп кешеләр ачлыкның иң зур фаҗигаләрен онытып, җылы бүлмәләр эчендә:

*«Ашыйк-эчик, уйнап-көлеп*
*Бергә гомер уздырыйк»,*

– дип җыр сузалар.

Зур шәһәрләрнең салкын урамнары буенча кар туздыручы җил дә:

*«Аш-ш-ш-ыйк-эч-ч-ч-ик,*
*Бергә гомер уз-з-з-дырыйк!»*

– дип, җыртык капчыкка төренгән ач ятимне мыскыллый...

Салкын...

Чатка сөялеп каткан яшь баланың күзләренә карама... Еллар буенча тук кешеләрнең шатлыгын каргап чатка текәлгән бу төпсез күзләрдән барыбер шатлык әсәре күрмәссең.

Алар, ярдәм сорап:

*«Ашап-эчеп, уйнап, укып,*
*Эшләп гомер уздырыйк!»*

– диләр.

*Татарстан. – 1923. – 9 февраль.*

# Ач, ярдәмчесез балаларны коткарырга кирәк!

**Шәриф Байчура**

Казанда 25 гыйнвардан 10 февральгә чаклы, кантоннарда беренче февральдән 15енә кадәр бөтен Татарстан күләмендә ач, ятим балаларга ике атналык ярдәм итү көннәре ясалу дәвам итә. Казанда инде бу актык көннәренә якынлашты.

Үткән елгы шомлы ачлыкның тирән эзләре әле һаман каплана алмый. Крестьяннарның урта һәм түбән катлаулары быел да авыр көннәр алдында торалар. Үткән ачлыкта ата-аналары үлеп ятим калган балаларның саны бу елда артуда дәвам итә. Сан алу идарәләренең күрсәтүенә караганда, быел февральдән башлап Татарстанда тәрбиягә мохтаҗ ятим балаларның саны 140 меңгә тула. Искиткеч зур сан!

Менә шул хәлне күз уңында тотып, Мәгариф комиссариатының үз байлыгы гына бу чаклы күпсанлы ятимнәрнең бөтен кирәк-яракларын җиткереп, туйдырып, тәрбияләп торырга җитмәгәнлектән, шул югарыдагы ике атналык ярдәм ясала.

Ләкин бу ярдәм эшләренең Казандагы барышы гаять начар күренә. Дәүләт мөәссәсәләре *(оешмалары)* һәм аерым гражданнар бу эшкә ифрат салкын карыйлар. Мәсәлән, Татарстанның иң зур дәүләт вә хосусый сәнәгать мөәссәсәләреннән гаять аз ярдәм бирәләр. Шул ике атналык ярдәм вакытында ясалачак лотерея өчен «Татторг» – 1000 данә папирос, «Татодежда» – 20 аршин ситсы, зур сабын заводы хуҗаларыннан Алмитев ике дюжина сабын биргән. Совнархоз, «Татваленки» вә башка шундый зур сәнәгать мөәссәсәләренең кайсы бернәрсә дә бирмәгән, кайсы әле җавап кайтармаган. Бу хәл аерым халык гаммәсенең генә түгел, хәтта иң

зур мөәссәсәләрнең дә бу эшнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен төшенмәүләрен күрсәтәдер. Юк исә, югарыда күрсәтелгәнчә, «ярдәм» итүләрне күргәч, җыларга да, көлергә дә белмисең.

Ятим балаларның хәле ифрат авыр: аларның тормышы нинди икәне һәркемнең күз алдында. Һәлакәт чокырына төшеп югала торган бу ятимнәрне коткаруның тиешлеге хакында инде бик күп сөйләнде, бик күп язылды. Аларның ничаклы газап чигүләрен, кышкы салкында ач-ялангач хәлдә иңрәп йөрүләрен сукыр булмаган кеше, әлбәттә, күрә.

Әгәр дә без бу хәлгә чын игътибар күзе белән карамасак, ул ятимнәргә тиешле ярдәмне итмәсәк, алардан иң элек үзебез өчен үк зур зарар китерә торган җинаятьчеләр килеп чыгачактыр.

Мәгариф комиссариаты үз көче белән генә бу ач балалар армиясен тәэмин итә алыр дип ышанырга юл юк. Болай да Мәгариф комиссариаты үзенең бөтен сәрмаясын *(акчасын)*, бөтен көчен ач балаларны коткару юлына тота. Ләкин ул ничаклы тырышса да, хәзер дәвам итеп торган балалар йортларын бер дәрәҗә тәэмин итүдән уза алмый. Хәлбуки ач, ятим балаларның саны көнләп түгел, сәгатьләп арта торадыр.

Мәгариф комиссариатының сәрмая ягын яхшырту юллары әллә нинди өмидләр бирерлек хәлдә түгел.

Менә бу хакыйкатьләр «Ике атналык ярдәм» вакытында төрле мөәссәсә һәм хосусый гражданнарның да ятим балаларны тәэмин итү эшенә артык салкын караулары белән бергә китереп кушканда, хәзер дәвам итә торган балалар йортларындагы ятимнәрнең дә, урам чатларындагы, авыл белән шәһәр арасындагы юллардагыларның да ачлыктан кибеп-корып һәлак булу ихтималының якын булганлыгын күз алдына китереп бастырадыр. Моның өстенә, кантоннарда быел ачлыкның шактый сизелерлек булачагын күрсәткән хәбәрләр килеп тора. Бу хәбәрләр инде гәзит битләрендә күренә башлады. Ачлыктан үлү вакыйгалары тагын ишетелә башлады.

«

**Чит губерналарга барысы 11 меңгә якын бала җибәрелгән иде. Хәзер инде 1922 елның августыннан башлап 1923 елның февраленә чаклы барысы 3081 бала Татарстан Мәгариф комиссариатының карамагына кайтты.**

Шулай ук өендә һичнәрсә азыгы булмаган, эшсез, тол хатыннар тарафыннан үзләренең балаларын Мәгариф комиссариатына күтәреп килеп, балаларына паек сораулары, бирелмәгән тәкъдирдә шунда ук баласын ташлап китү вакыйгалары да җыш буладыр. Мондый балаларга чар-начар ничек тә ярдәм күрсәтергә тырышыла, ләкин Мәгариф комиссариатының сәрмаясы артык азлыктан, бу ярдәм артык аз үлчәүдә генә була аладыр.

Үткән ел Русиянең төрле почмакларына, иген булган губерналарга җибәрелгән балаларның хәзер кире кайтулары дәвам итә. Болар тагын ук Мәгариф комиссариаты өстенә авыр йөк булып төшәләр. Чит губерналарга барысы 11 меңгә якын бала җибәрелгән иде. Хәзер инде 1922 елның августыннан башлап 1923 елның февраленә чаклы барысы 3081 бала Татарстан Мәгариф комиссариатының карамагына кайтты. Шул ук мөддәт *(вакыт)* эчендә Казанның үзендәге ятимнәрдән һәм кантоннардан берәмләп килгән балалардан 2400 бала балалар йортына кабул ителде. Барысы югарыдагылар белән 5480 бала кабул ителгән була. Боларның

46 проценты – татар балалары, 50 проценты – урыс балалары, калганнар – вак милләтләр балалары.

Татарстанның кантоннарында хәзерге вакытта балалар йортларына урнаштырылган ятимнәрнең саны 20 000 хисаплана.

Якын көннәрдә мәркәздәге губерналарга киткән балалардан 6-7 мең бала якын арада кире кайтырга тиеш.

Мәркәзгә Татарстан Мәгариф комиссариатының бу чаклы баланы кире кабул итәрлек сәрмаясы булмау хакында тәкрар *(кабат)* хәбәр ителүгә карамастан, кирәк ул җирләрдәге Мәгариф шөгъбәләре *(бүлекләре)* тарафыннан, вә кирәк андагы балалар тарафыннан Татарстанга кире кайтаруны бик нык таләп итәләр.

«Бу җирләргә җибәрелгән татар балаларының хәле аларга үз ана телләрендә уку китаплары булмау, үзләре белән бергә барган укытучы вә мөрәббиләрнең *(тәрбиячеләрнең)* берәмләп кире кайтып китүләре белән тагын авырайган.

Читтәге балаларның, Татарстаннан чит губерналарга җибәрелгән балаларның тормышы начар булу хакында күп тапкыр язылды. Соңгы вакытта килә торган хәбәрләр дә шул авыр хәлләрне тасвир итәләр. Мәсәлән, Витебск губернасында хәзерге вакытта Татарстаннан күчерелгән 475 бала бар. Соңгы вакытларда паекларның азаюы сәбәпле, бу балаларның хәле тагын да начарланган. Паеклар андагы җирле балаларга да җитешми. Ачлык нәтиҗәләре белән көрәшү комиссиясенең дә бу балаларга күзгә күренерлек ярдәм бирерлек матди сәрмаясы юк икән. Аларны тәэмин итү юлында һәммә юллардан файдаланып, инде һичбер мәнбәгъ *(чыганак)* калмаган. Моның өстенә, туган-үскән җирләрендә яхшы ашлык булды, дигән хәбәрләр балаларның кайтырга омтылуларын көчәйтә икән. Бу җирләргә җибәрелгән татар балаларының хәле аларга үз ана телләрендә уку китаплары булмау, үзләре белән бергә барган укытучы вә мөрәббиләрнең *(тәрбиячеләрнең)* берәмләп кире кайтып китүләре белән тагын авырайган.

Бердән, югарыда әйтелгән сәбәпләрдән, икенчедән, мондагы балаларны мәгълүм бер план белән кайтару эшенең ничек, кайчан булачагы мәгълүм булмаганлыктан, бу губернаның Мәгариф шөгъбәсе тиздән андагы балаларны кире алуны таләп итәдер.

Кременчуг губернасындагы балалар хакында да шундый ук хәбәрләр килә. Андагы *(моннан киткән)* балалар да тормышларының фәүкылгадә *(гадәттән тыш)* авырлыгыннан, ачлыктан үләргә якынлашкан хәлдә булуларыннан зарланып язалар.

Тверь губернасына җибәрелгән балалардан килгән хатларның берсендә шул сүзләр әйтелә: *«Безне киендермиләр дә, рәтләп ашатмыйлар да. Яртылай ялангач йөрибез. Суны үзебез китерәбез, керләрне үзебез юабыз. Хәлбуки инде кар төшкән, сулар каткан. Безне ашата торган сәүдәгәрләр һәр кисәк икмәк өчен безгә михнәт итәләр, сүгәләр».* (Аларны җирле сәүдәгәрләр туйдыра.)

Читкә җибәрелгән балалар менә шул хәлдә яшиләр. Аларны, яшь балаларны, көчләре җитмәгән эшләргә, җир хезмәтләренә вә башка авыр эшләргә кушалар. Алар, ач хәлдә, үзләренең туган-үскән җирләренә кайтырга омтылалар.

*Татарстан. – 1923. – 9 февраль.*

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

# Зәйтүнә Мәүлүдованың кабер ташы

**Айдар Гайнетдинов**

Зәйтүнә Мәүлүдова – Габдулла Тукай яратып йөргән кыз. Ул 1893 елның 18 августында Чистайда дөньяга килгән. Кызның гаиләсе 1907 елның җәендә Казанга күченгән. Ул вакытта З.Мәүлүдованың атасы Хәйдәр инде үлгән булган, әниләре, иренең исән чагындагы теләген үтәп, кызларын Казандагы рус-татар мәктәбендә укыткан. Зәйтүнә башкалада Габдулла Тукай белән берничә тапкыр очрашкан, шагыйрь аңа гашыйк булган, тик мәхәббәтен белдерергә оялган. Кызганыч ки, яшьләрнең юллары аерылган: 1908 елда З.Мәүлүдова гаиләсе белән кире Чистайга күченеп китәргә мәҗбүр булган. Соңра кызны ишан Зәйнулла Рәсүлевнең улы Габделкадыйрга кияүгә биргәннәр. Аларның газиз уллары Атилла Расих мәшһүр язучы булып киткән.

З.Мәүлүдова Казан шәһәрендә вафат булган. Аның кабере атаклы Яңа Татар бистәсе зиратында (15 аллея янында). Аның кабер ташына мондый сүзләр язылган:

Алгы ягы:
1) «Мәүлүдова
2) Зәйтүнә Хәйдәр кызы
3) 1893-18-VIII – VI-8-1957.
4) Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
5) Ул шуңар да шатлана бит, чын юләр түгел диген!
6) Күргәнең бармы әле Коръандагы мәдхияни?
7) Ул синең васфыңда: «ля шәркыйя, ля гарбия», – ди!
8) Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып,
9) Ул хәзер алган «Сабах»тан бер Кәләмулла сатып.
10) Г.Тукай».

Арткы ягы:
1) «Кадир Зәйнулла улы
2) Рәсулев
3) 1891-1960».

**Күргәнебезчә, әлеге кабер ташы З.Мәүлүдовага гына түгел, ә ике кешегә – аңа һәм аның иренә куелган. Күпләр, ташбилгенең алгы ягын гына күреп, арткы ягына игътибар итмиләр һәм бу кабер ташы фәкать Зәйтүнәнеке дип уйлап нык ялгышалар.**

«Очраган юлда...» шигырен күренекле шагыйребез Габдулла Тукай әлеге кабер иясенә багышлап язган булган, шуңа күрә ташбилгене куйдыручылар З.Мәүлүдованың ташына әлеге сүзләрне яздырганнар. Гадәттә, татар кабер

ташларының язуларында хаталар очрый, бу ташбилгенең текстында да аларны табарга мөмкин. Мәсәлән, «Коръәндәге» сүзе «Коръандагы» дип, «мәдхияңи» сүзе «мәдхияни» дип, «Кәлямулла» сүзе «Кәләмулла» дип язылган.

Шигырьне аңлавы кыен, чөнки гарәп алынмалары, ислам терминнары очрый, шуңа күрә аны хәзерге татар теленә күчерик:

*«Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул (Тукай үзе турында сөйли) бүген;*

*Ул (автор үзе) шуңа да шатлана бит, чын юләр түгел диген!*

*Күргәнең бармы әле Коръәндәге сине (Зәйтүнәне) мактау сүзен?*

*Ул (Коръән) сине (Зәйтүнәне) сыйфатлаганда: «Көнчыгышныкы да, көнбатышныкы да түгел», – ди!*

*Күк китабының (Коръәннең) сине белгәнлегенә шаккатып,*

*Ул (автор) хәзер алган «Сабах»тан («Сабах» китапханәсеннән) бер Кәләмулла (Коръән китабын) сатып».*

Бу шигырьдә шагыйрь «Нур» сүрәсенең 35 нче аятенә ишарә иткән:

۞ ٱللَّهُ نُورُ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلْأَرْضِ ۚ مَثَلُ نُورِهِۦ كَمِشْكَوٰةٍ فِيهَا مِصْبَاحٌ ۖ ٱلْمِصْبَاحُ فِى زُجَاجَةٍ ۖ ٱلزُّجَاجَةُ
كَأَنَّهَا كَوْكَبٌ دُرِّىٌّ يُوقَدُ مِن شَجَرَةٍ مُّبَٰرَكَةٍ زَيْتُونَةٍ لَّا شَرْقِيَّةٍ وَلَا غَرْبِيَّةٍ يَكَادُ زَيْتُهَا يُضِىٓءُ وَلَوْ لَمْ
تَمْسَسْهُ نَارٌ ۚ نُّورٌ عَلَىٰ نُورٍ ۗ يَهْدِى ٱللَّهُ لِنُورِهِۦ مَن يَشَآءُ ۚ وَيَضْرِبُ ٱللَّهُ ٱلْأَمْثَٰلَ لِلنَّاسِ ۗ وَٱللَّهُ بِكُلِّ
شَىْءٍ عَلِيمٌ ﴿٣٥﴾

Аятьнең мәгънәсе:

*«Аллаһ күкләрне һәм җирне яктырта. Аллаһ нуры эчендә шәм янып торган өйнең тәрәзәсе кебек, ул шәм пыяла эчендә, пыяла энҗе кебек бер йолдыз. Ул ут яндырылыр* ***зәйтүн*** *агачының мае белән, ул агач көнчыгышта да түгел, көнбатышта да түгел. Аның мае, ут ирешмәсә дә, яктырырга әзер. Нур өстенә нур! Аллаһ теләгән кешесен нурына ирештерә. Аллаһ кешеләр өчен мисаллар китерә. Аллаһ – һәрнәрсәне белүче».*

Коръәндә очраган шушы «зәйтүнә» («зәйтүн») сүзен Г. Тукай, шаяртып булса кирәк, үзенең яраткан кызы Зәйтүнәгә бәйләп күрсәтә. Чынлыкта, аятьтә сүз зәйтүн агачы һәм мае хакында бара. Шул агач маен Аллаһы Тәгалә, «ут кагылмаса да, яктырырга әзер», дип мактаган. Изге китапта «зәйтүн» сүзе биш урында очрый, ә менә шул ук мәгънәне аңлаткан, тик берлек санда торган «зәйтүнә» сүзе фәкать бер җирдә – «Нур» сүрәсендә генә китерелә.

Шулай итеп, Коръән китабында кызның исеме телгә алына дип шаккатып, шигырьдәге лирик герой бертуган Әхмәдуллиннар китапханәсеннән Изге китап сатып алган.

З.Мәүлүдованың кабер ташы инде бераз тузган, шуңа күрә аны яңартырга кирәк, дигән сүзләр дә ишетелә. Тик бу эш эшләнсә дә, аның бу иске ташын зират кырыена алып чыгып атмасыннар, ул якты бер истәлек булып берәр музейда урын алсын иде. Чөнки байтак шәхесләргә куелган иске ташлар зират кырыенда әвәләнеп яталар. Хәтта Тукайның иске ташы да беркемгә кирәк булмады (бәлки, ул һаман шунда ятадыр әле). Андый хәлгә барып җиткәнче, ташны бөтенләй алыштырмаулары күпкә хәерлерәк. ■

# «Күңелем иркәсе булган авыл кызлары»*

Мирхәйдәр Фәйзи

**1923, июнь**

***17сендә.*** Җыен гөрли. Урамда халык кайный. Атларга төялеп, гармуннар белән сиптереп үтәләр. Җәяүле төркемнәр дә уйнап-йөреп торалар. Хатын-кыз ыгы-зыгы килә. Алдагы ишек төбе мулла белән абыстайларны ала килгәннәр белән буш тормый. Мине дә чакыргалыйлар. Берсенә дә бармыйм. Җиңги төяп-төяп күчтәнәчләр алып кайта. Барган бер җирләрендә бәлеш икән. Кунакка бармасак та, төпләре кайта.

Закир алып кереп чәй эчерде. Габдулла да шунда иде. Ике бутылка кумушка (көмешкә) эчтек. Җиңелләндек. Кунер җегетләре урамнан уйнап уздылар. Һәммәбез җабырылып урамга чыктык та, Закирның әткәе Шакир абзый: «Дәҗҗал артыннан да шулай йөгереп йөрербез микән?» – ди. «Шулай күңелле булса, ник иярмәскә?» – дип, бөтен халыкны көлдердем.

Күрше Гыйльметдиннең матур кызы Гыйльмебану белән күрешеп, бергә уйнарга вәгъдәсен алып куйдым. Уен вакыты җиткәнче, башка бер җегет алып куймаса ярар иде, дип, шуның өчен көеп йөрдем. Икенче җегет кулында йөргәнен күреп, буыла яздым…

Болында тагын кичәге үк хәл. Болын тагы ямь-яшеллек хәзинәсе булып әверелгән. Уен янына җитүем белән, аннан да моннан җегетләр җитәкләшкән кызларын тәкъдим итеп уенга катышырга кыстый башладылар. Кайсысы: «Кемне телисең? Алып килеп бирәм!» – ди. Бөтен парларны аралап, Гыйльмебануны эзләп таба алмагач: «Миңа кирәк кыз шул», – дияргә туры килде. Аны җегетенең кулыннан тартып алып бирмәкче булдылар һәм җегетнең уступить итүендә дә шик кылмадылар. Ләкин, җегетнең Мөхәммәтгали икәнен белгәчтен дә, мин ваз кичтем. Кызын яраткан кебек, җегет тә кызны әрәм итәрлек түгел иде.

Шоданың бик күп җегетләре белән үзләшеп, дуслашып беттем. Җыен вакытында әллә кай почмакларда яткан җегетләр пәйда булдылар. Җырлауларын тыңлап җуандым.

*Абау Алла, Ходакаем, дисәң дә, димәсәң дә;*
*Каласың бит, сөям, җаныем, дисәң дә, сөйсәң дә,*

– дип, тәмам бирелеп, башын чайкап җырлаган Ризван дигән җегетне дә күңелемнең түренә утыртып куйдым.

Күп йөри торгач, Гыйльмебануны кулга төшердем. Аның белән булганга, һичбер армыйча уен беткәнче уйнадым. «Алда килеп алмадың», – дип шелтәләде зимагур кыз.

Уеннар барганда исерекләр килеп мешать итүләре булгалады. Авыл председателе Хәйри, исереп килеп, хуҗалык итеп йөреп, кәефне алды. Үзен дә җуя

* Көндәлекләрдән кыскартып бирелә. – ***Ред.***

Мирхәйдәр Фәйзи

яздылар бәдбәхетнең. Матуррак кызларны җегетләрнең кулыннан тартып алгалап, ухарь купес ролен уйнаштыргалап, канны бозгалады.

***18ендә.*** Бүген болында уен тагы да матуррак булды. Кунаклар сирәгәйгән, исерекләр азайган, ләкин уенга катышмадым. Гыйльмебану юк иде.

Уйнаган уеннары, бер уйлаганда, уен дип әйтерлек тә, кызык та түгел; бер уйлаганда, бик кызык, бик күңелле. Бертөрлелек, тынлык, күңелне канәгатьләндермәгән кебек тоелса да, андагы төп сер бөтен наразыйлыкларны *(ризасызлык)* себереп түгә. Егет-кызларның бер-берсе белән хәвефсез, иркен сөйләшеп, вәгъдәләрне беркетеп калуына бина ителеп, шундый уен чыккан. Элек кызлар кулдан-кулга күчеп тора. Шулар арасында гына «үзенеке» дә кулга кереп чыга. Аның беләнме, башкалар беләнме, чынлап сөйләшкәнен кем, кайдан белсен? Круг уйнаганда да эзен яшерүчеләр була. Шулай ук батыр рәвештә, хәвефсез йөргәннәре дә тулып ята. Һәм пар-пар читкә китеп сөйләшеп торулар да гаҗәп эш түгел.

Күрше Хәмит малае Газиз белән кайттым. Бу малайда да үзем сөя торган хасият табам мин. Кич тә аның белән яктырып беткәнче бергә утырдым. Урамнарда гармун белән йөрдек. Күңелле булды.

***19ында*** җыенның вакыты тулды. Кунаклар таралды. Бүген дә болында уен ясыйлар әле. Газиз, Идрис, Габдулла белән чишмә янына төшеп яттык. Кызлар су алалар, җегетләр сөйләштерәләр, шаярталар. Мөхәммәтгали, аръяк Газиз, Ибрай, Шәрәфетдин вә башкалар килделәр. Җегетләр дә күбәйде, кызлар да. Кызлар су ала, җегетләр чуала. Гармун белән тагы бер төркем килде. Җыйналып, җырлап-уйнап, болынга төштек.

Бүген саран җыеналар. Кеше җыелып беткәнче, Идрис, Шәрәфетдин, Ибрай, Гыйрфаннарның арасында ятып, берсе уйнап, өчесе җырлаганда рухан бәйрәм иттем. Үзләрен папирос белән сыйладым.

Бу уенны карап кына торырга теләсәм дә, җегетләр чакыра, кыстый, сөйри башладылар. Ахыры аръяк Газиз җиңде. Үз урынына мине кертеп, үзе икенче урынга күчте. Ике ямьле кызның уртасында дәүран сөрдем *(вакыт уздырдым)*. Берсе әйткән була: «Без сиңа тиң түгел инде, синең тиңнәрең әнә», – дип, Ламига, Мәгъмүрәне күрсәтте. Мин әйттем: «Аларны тиң күрмәгәнгә күрә дә, аралары җегетсез булса да, кермәдем. Сезнең белән күңелле миңа», – дим. «Алдыйсың», – дигән була, ышанмаган була акылсыз кыз.

Бу йөрешләрнең мине азрак аптыраткан җире шул булды: җегетләр, ирләр оят саналган сүзләрне теләгәнчә әйтәләр, сүгенәләр. Ә кыз-хатыннар аларны чүпкә дә санамыйлар. Гадәти сүз ничек сөйләнсә дә, бу да шулай китә бирә. Һичнәрсә бозылмый да, нитми дә; кызлар да битен басып китми, күзен дә җоммый хәтта.

Кичәле-бүгенле берәүнең кемлеген белү мәрәкына бик нык бирелдем. Ул үзе җегет кеше. Элек биюе аша таныдым. Бер якта егет-кызлар уены барганда, бер якта биюләр барадыр иде. Биючеләр шундый бер закон чыгардылар: кыз белән йөргән җегетләрне китереп биетмәкче, наказание бирмәкче булдылар. Шул кызык рәвештә гамәлгә куелды. Берничә кеше яшьләр төркеменә бара да, җегетне кызы белән сөйрәп алып килә. Кызын тотып торып, җегетен биетәләр, биеп беткәч, кызын кулына биреп җибәрәләр. Бу җегетне дә шулай китерделәр. Биюенең мөмтазлыгына *(шәплегенә)* дикъкать иттем. Кулы белән гармунчы кар-

шында ясалган фигураларына гашыйк булдым. Чылбырда йөргәндә, аның нәфис хәрәкәтләрен кәшеф иттем *(күзәттем)*. Кызлар белән могамәләсен дә сөйкемле, нечкә итеп таптым. Шушы авыл малае икәнен белсәм дә, кем икәнен белмәдем. Кемлеген белү мәрәкында калдым, вәссәлам!

***21ендә*** кич Өре очында Фәттах, Сәгъдулла дигән җегетләр белән ирмәкләндем. Фәттахтан байтак авыл серләрен өйрәндем.

Бер җирдә утырып торганда власть хакында ялгыш кына сүз чыгарып җибәрдем. Агайлар советка каршы төште, турыдан-туры, Николай кирәк, диләр. Ә шундагы яшь егетләрнең (Фәттах, Хәкимҗан, Вахит) советны яклап картлар белән тартышулары рухландырды.

Иртәгә, насыйп булса, Һашим белән Сәрдек җыенына барабыз. Ике көннән бирле Һашим белән морҗасыз өйдә ята башладым.

***23ендә*** Һашим сәгать дүрттән уятты. Чәй эчтек тә, икәү Сәрдеккә киттек. Миңа Һашим белән йөрү күңеллерәк. Энем дә, дустым да итеп карый алам. Ул да тартынмый, гади генә кылана.

Сәгыйтьнең фатиры Гарифҗанга төштек. Бару белән кумушка авыз иттерделәр. Коймаклап чәй эчтек. Тагы самогонка, тагы сыра эчтек. Гарифҗан әле бер мөнәсәбәт, әле бер мөнәсәбәт табып эчерә дә тора. Бер кеше алып кереп бал эчерде.

Тарантаска пар ат җигеп, Гарифҗан, Сәгыйть, Һашим – дүртебез Пужмарага барып йөгертеп йөреп кайттык. Бу атнада Сәрдек, Пужмара, Әтнә, Комбашы авылларында җыен.

Сәрдек зур гына, бай гына бер авыл. Кумушканы да күп ясатканнар. Кунаклар да күп. Шодадагы чуарлык, җанлылык, ямьлелек, форсить монда да полный ходта.

Төштән соң чишмә буена – болынга – уенга төштем. Бер ягы – авыл, бер ягы чыршылы-урманлы тау булган су буендагы чуар киемле... (бер-ике сүз киселгән. – **Р.Ш.**) бирә күңелгә. Карап торуы зур бер зәвык. Мин монда караңгыга кадәр йөрдем. Кунакка чакыручылар да, хуҗа хатынының, өйгә кайтмый, дип рәнҗүләре дә, мөгаллим-мөгаллимә кебек «зыялы» халыкларның бергә йөрергә тәкъдимнәре дә мине моннан – крестьян яшьләре арасыннан аера алмады.

Сәрдек җегетләре кунак җегетләрен обижать иткәлиләр кебек күренде. Хәтта миңа да: «Үз кызларыбызның чит җегетләр кулында йөрүенә тыныч карый алмыйбыз», – кебек сүз әйтеп алдылар. Кунакларның кулыннан кызларны тартып алу кебек хәлләр дә күренгәләде. Кунак җегетләр дә, ачуланып: «Сез дә барырсыз әле», – дип, теш кайрап йөрделәр.

Исереклекне тыярга билгеләнгән кешеләр, үзләре исерек көе килеп, тәртипне бозып, яшьләрне тузгытып йөри башлаганда, егетләрнең нык торулары: «Без – совет балалары», – дип кычкырулары; Вәлид исемле бер авыл җегетенең: «Без исерек тә, тәртип бозучылар да түгел. Төрмә безгә түгел, сезгә, совет балаларына түгел, Нико-

> «
> **Монда җегетләр кызлар белән тагы да хөррәк маташкан кебек күренделәр. Анда да, монда да җегетләр бер кыз алдында иркәләнеп яталар. Кыз аягын сузып утырган, җегет аның ботларына башын куеп сузылып яткан.**

лай ялчыларына», – кебек көчле сүзләр белән каршы торуы, ямьле күренеш өстендә ялтыраган бер ...нәт тоелды.

Монда җегетләр кызлар белән тагы да хөррәк маташкан кебек күренделәр. Анда да, монда да җегетләр бер кыз алдында иркәләнеп яталар. Кыз аягын сузып утырган, җегет аның ботларына башын куеп сузылып яткан. Кыз аны башыннан сыйпап, иркәләп утыра. Аталарның, аналарның, агаларның күрүеннән сакларлык һичбер пәрдә булмаса да, аның өчен хәсрәтләнүче күренми. Кызын куып алып кайту, икенче көн чыгармау кебек вакыйгалар күзгә ташланып тормый. Андый хәлләр бик сирәк кенә булса буладыр.

Исерекләр, сугышу-кыйнашулар да күренгәли. Яшьләр арасында әтәчләнеп, бәргәләшеп алуларны да күргәләдем. Шул эчүе аркасында уеннарга да зарар килгәләп, ямьсезлек хасил булгалап ала.

Сәгыйть белән урамнарда йөрдек. Төркем-төркем уйнап үтәләр. Атка төялеп чабалар, песи генә булып кыз янына керергә баручылар үтәләр. Пышын-пышын сөйләшеп шуның хәстәрендә йөрүчеләр дә очрый.

Таңга якын Һашим белән Малмыжга чыгып киттек. Төн матур, рәхәт. Йокы нишләтер инде, җитик. Пожмараны, Күчкимне үткәч, сызылып таң ата башлады.

***24ендә*** су буенда кичәге хәл – уеннар дәвам итә. Бу җыенда бер кыздан гаҗиз булдым. Алдымнан да, артымнан да килеп чыгып тәмам туйдырды. Бәхетләрем арасына җылан булып сузылгалады. Уен вакытларында гел кул астыма килеп керергә җитешләтеп, уеннан качуларыма сәбәп булды. Күңелем иркәсе булган авыл кызлары белән ике арамда «кара гарәп» ролен уйнап, «мәнфурә» булып әверелде.

Җиткәннәр рәтенә тезелә алмаган үсмер җегет-кызлар аерым җирдә уйныйлар. Үзләренең тиңнәреннән гармунчылары бар. Араларында исерекләр булмаганга, боларның уены тагы да тәртиплерәк. Яннарында озак тордым. Бу төркемгә туры килгән кызлар зур кызлардан аерым бер җирдә утыралар. Малайлар җитәкләп-җитәкләп алып киләләр. Кызык!

Шулай да бик хөр мин хәзер. Бәхетсез түгелмен. Ирегемә кагылырга берәү дә чынлап кыя алмый. Үз җаемарак яшим. Шуның белән рухлымын. Сау гына булыйм, бирешмәм.

***25ендә*** иртәнге чәйгә бер әби чакырды. Анда Гайсә Дәүләтшин, Сәгъди, Нәҗип, Мөбарәк исемле Йөрек җегетләре бар икән. Бергә күңелле булды. Гайсә дигәне педтехникум бетергән, гармунчы, коммунчы, матур бер җегет. Каймак, май, сөтле шулпа, коймак, чәйләр белән сыйландык. Чыккач, келәткә кереп озак утырдык. Гайсә гармун уйнады. Кызлар да күп булды. Араларында утырдык. Сәгыйтьтән кичкә таба гына китү хакында әмер булды. Җаңгыр яуды.

Тагы Йөрек җегетләре янына кереп утырдым. Гармун гел уйнала. Сәгъди дигәне белән бергә утырып дусландым. Чуар җеп белән тоташ чиккән яулыгының тарихын сөйләттем. Түгәрәкләнеп утырып папирос тарттык.

Су буена уенга төштем. Гайсә белән бергә утырып, сөйләштек; аңлаштык. Ул гармун уйнады. Кайтканда Мөбарәк белән кайттым. Бер Сәрдек кызы белән сөйләшеп торганында авылның үз җегетләренең килеп сүгүләрен,

сөйләшергә ирек бирмәүләрен сөйләп: «Безгә дә барырлар әле», – дип үчләнеп кайтты.

Шулпа, бәлеш, итләр ашап, Сәрдектән киттек. Мәзин малай Габделхак та безнең белән кайтты. Һашим белән парлап җырлыйлар, күңелле! Уйныйкөлә кайттык.

***27сендә.*** Ибрай ямьле җегетне күргәч тә яраткан идем. Әмма Гыйльмебану белән йөргәнен белгәч, ямьсез күренә башлады, дуслыгым бетте. Гыйльмебануны алдан көнләп көя башладым. Гыйльмебану Шодадагы көннәремнең таҗы булды. Аның белән кара-каршы килеп бер сөйләшү мең рәхәттән дә рәхәтрәк тоела. Аның, матур йөзләрендә нур уйнатып, матур күзләреннән уклар атып, органнарга хас тавыш белән ачык сөйләүләре хатирәмне аллар-гөлләр белән бизәде. Гыйльмебану исемә төшкәндә, сөенеп-сөенеп; Ибрай исемә төшкәндә көенеп-көенеп китәм...

Ламига туташ безгә килде. Бакчада икәү генә карлыган җыеп ашадык, сөйләштек, көлештек, уйнадык.

Кич җегетләр белән урамда утырдым. Урынга яткач, Һашим белән авыл кызларын сөйләшеп яттык. Ул – Фәрхәнәне, мин Гыйльмебануны алга куйдык.

***30ында.*** Иртәгә китәргә булдым. Гает үткәреп китәргә бик димләсәләр дә, үзем дә китәргә бигүк теләмәсәм дә, тәвәкәлләдем инде, хәерле булсын! Гаеткә кадәр Орскига кайтып җитәргә дип уйлап, ашыктым.

Иртә белән җиңги бик тәмле борай ярмасы пылавы пешерде. Төшкә бәрәңге куырды. Хатыннар җиләкне китерәләр генә абыстайга. Алдан җиләк өзелми. Җиләк җиткәч кенә мин китәм, черт возьми.

Иген басуына чыгып йөрдем. Шода өстенә яратып карап тордым. Урбар урамының башыннан-башына кадәр барып кайттым.

Шода белән хушлашып йөри башладым. Түбәнге күпергә төшеп Кантур урамына чыктым. Аннан җыенда уен булган тугайга төшеп, сагынып йөрдем. Су буйлап үрләп Өре урамының башыннан төшеп очладым. Шурма күпереннән тагы Кантур урамына чыгып, Шәрәфетдинне очраттым. Икәү яр башындагы бүрәнәләргә утырып тәмәке тарттык. Их, су буеның күренеше! Сулар, күперләр, тирессез ямь-яшел су буйлары, агачлар, күренеп торган тегермән, агачка чумылган авыл... Китәргә торган күңелне сихерләп тарта шул үзенә. Ник китәргә булуым өчен үкенә яздым.

Су буйлары һичбер тирессез, таза, саф, матур бит, малай! Тирес басуга сибелә шул монда. Су буйларын пычратып ятмый шул ул. Шуңа күрә су буйлары ямьле шул әникәем.

Китү белән йомшаган күңел, бу юлы Ибрайны дошман күрмәде. «Ямьле җегет бит, хәерсез; Гыйльмебану белән икесе пар бит. Барыбер миңа бер файда да юк», – дип уйладым. Шулай да Гыйльмебануны бик күрәсем килеп йөрдем бүген. Күрә алмый өзелдем.

Кич, актык кич итеп, абый, җиңгиләр белән утырдым. Урамга чыкмадым. Гармун уйнап, күңелемне кытыклап йөрделәр. Саулыкта абыйлар белән күрешүне, Шоданы да килеп күрүне теләп киттем инде мин. Хәерле юл! Сау булыйк, сау булыйм!

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# Бабичның беренче адымнары

*(Яңа табылган истәлек дәфтәре буенча)*

**Гомәр Толымбай**

*Язучы, әдәбият галиме Гомәр Толымбайның (1900-1938) бу мәкаләсе «Яңалиф» журналының 1929 елгы 16 нчы санында басылган. Текст шуннан кыскартып бирелә.*

**Бабич (уртада) дуслары белән**

Бабич күп кенә истәлек дәфтәрләре язган. Боларның күбесе табылган-сакланган булса да, байтагы юк әле. Менә шул дәфтәрләрнең берсе шушы арада табылды. Бу аның истәлек дәфтәрләреннән 12 нче кисәк булыр, 1913 елның сентябрь башларында язылган. Язылган урыны – казакълар арасы. Бабич үзе дә истәлек дәфтәрләренең тышына «Себер сахрасында, казакъта уздырган көннәрем» дип язып куйган. Казакъстанның кай җирендә булуы турында ачык бер күрсәтмә дә юк. Бары истәлектәге ишарәләргә карап кына, Бабичның хәзерге Акмулла округындарак булуын чамаларга мөмкин.

Әлеге истәлек дәфтәре Бабич турында нинди материаллар бирә соң? Бу истәлек дәфтәре Бабичның казакълар арасында булуын, аның казакъ әдәбияты белән нык кызыксынуын, үзенә тән һәм социаль яктан биргән кайбер бәяләрен һәм аның шул чагындагы сыйнфый йөзен яхшы гына ачып сала. Бабичның матбугат дөньясына кайчан чыгуы бик ачык билгеле түгел. Ләкин ул шушы 1913 нче еллардан да соңга

калмаган булырга тиеш. Менә шушы моментны да искә алсак, материалларның кыйммәте шактый гына арта. Карыйк берәм-берәм.

## Бабич казакълар арасында

Әлегә чаклы чыккан материалларда Бабичның казакъ арасында булуы, казакъ әдәбияты белән танышлыгы турында бер сүз дә әйтелмәде. Бу истәлек дәфтәре шушы моментка беркадәр ачыклык кертә. Без әлеге истәлек дәфтәрендә Бабичның казакъ арасында кем булып күпме торуы һәм нишләп йөрүе турында түбәндәге юлларны очратабыз (сүзләр бер җирдә дә үзгәртелми):

*«Дәресләремне моталлага (өйрәнеп) кылып вә башка әллә нинди эшләр белән мәшгуль булып үткәрмәкче булган 4 аем ялт итеп кенә калды. Мин «кап» дип авыз ачтым да калдым. Теге исәпләр коп-коры хыялый мөрәккәб булды да калды.*

*Инде кайтырга күп калмады. Гәрчә муллалык мөддәтем (вакытым) Покрау башына кадәр булса да, мин теләгәнчә булса, сентябрьнең 20сеннән калмый китәм, Алла кушса. Чөнки «Галия»дә 15 сентябрьдә имтихан, 22сендә дәресләр башланачак. Шуңар күрә ашыгам. Үз теләгемчә булса, кайтырга 16 көн, таң атса – 15 көн, ягъни ярты гына ай калды инде...*

*Унбиш көннән соң тагы көннәр туар. Әмма Дүсәнбай авылыда мин булмам. Казакълар: «Муллабыз фәлән иде, төгән иде», – дип сөйләшеп утырырлар, әмма 15 көннән соң мин булмам. Гәзитләр атна саен килеп торыр, ләкин төгәл укучы булмас, чөнки ул чакта мин булмам...»*

Истәлекнең икенче бер җирендә мондый юллар бар: *«Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер. Бу сентябрь аенда мин дә һичкемнән ким булмасмын. Алла теләсә, бөтен хәер сәдакалары белән 30 сум жалунияне мин дә кесәгә бөкләп салырмын.*

*Көн салкын. Болытлы, көзге җил. Бүген, Нурмөхәммәт өенә кунак килеп төшкән мөнәсәбәт илә, көндез бер җирдә, кич өч җирдә мал суелды. Бер генә өйгә килгән бу кунакларның әллә ничә өйгә кисәре тиде. Син теләгәндә бер җапрак ит таба алмайсың, ә теләмәгәндә өсте-өстенә ит пешерелә. Гаҗәп бу тормыш!»*

Әнә шул югарыдагылардан Бабичның казакъ арасында 4 аен 30 сумнарга хезмәт итеп мулдәкә булып йөрүе, ул замандагы мулдәкәләр нишләсәләр, аның да, тулаем алганда, шуларны ук башкаруы ачык күренеп тора.

Ләкин Бабич мулдәкә булып кына калмый. Ул әдәбият белән дә шөгыльләнә. Гәҗитләр укып бару белән бергә, матур әдәбиятны да истән чыгармый. Истәлегенә Бабич әдәбият турындагы зарын да язып куя. *«Романнар, шигырьләр укырга мин яратам һәм аңа иренмим дә, ләкин «манигы коргыры» бар, авылда «гайрәтханә» юк. Үзең алуга акча такыр. Гомерне бигрәк тиккә җибәргәнче «гайрәтханә» булса, каһәр ару гына булыр иде дә, ни әйтәсең, юк»,* – ди ул.

Уку турында гына уйламый Бабич, язуны да искә ала. Ул бу истәлекләр дәфтәрендә «Җырчыны көткәндә», «Күңелсез чакта җырланган», «Күңелле чакта җырланган» дигән исемнәр астында өч кисәк шигырь яза да шуннан ачынып куя: *«Ни булды икән минем галәмгә? Былтыр яз ике-өч язган галәмем быел яз ике-өч сәрләүхәдән артык булмады. Әллә язу дәрте елдан-ел сүнә бара инде»,* – ди.

Болар гына түгел, Бабичның халык әдәбиятына күңел куйганын беләбез. Ул кыска гына гомерендә күп кенә әкиятләр, күп кенә җырлар, күп кенә көй тарихлары һәм башкаларны туплады. Казакъ арасында йөргәндә дә ул бу эшкә күңел куйган. Шушы истәлек дәфтәрендә сиксән казакъ мәкале, әйтешләре булу безгә шуны күрсәтә. Бабич: *«Сентябрьгә каршы Мортаза мулладан төне буе*

*мәкальләр әйттердем. Әйткән мәкальләренең мәҗмугы 79 булып, шуларны монда күчереп язам*», – дип башлап китә дә шул 79 мәкаль һәм әйтешләрне байтак кына аңлатмалар белән язып куя.

Бабич халык әдәбиятына бик нык игътибар итә. Аның бу дәфтәрендә теге 79дан башка тагын бер мәкале бар. Ул шул мәкален язып куя да аннан мондый сүзләр әйтә: *«Земләнкәгә барып, анда торган чакларымны хәтерләп йөрдем. Алла сакласын! Борчалар чикерткәләр кеби сикергәләп йөриләр иде. Тышка чыксам, итекләремә сырлан кебек ябешкән. Шаккатып, сыпырып ташладым. Җирдә яткан бер-бер кәгазьне алып карасам, бер мәкаль язылган. Тәтәй тапкан бала кебек куанып кайттым да язып куйдым».*

Бабич казакъның фольклоры белән генә чикләнми, аның язма әдәбиятын да өйрәнә, тикшерә, аңа үз карашын йөртерлек хәлгә килә. Бу истәлек дәфтәрендә шушы мәсьәләгә кайта торган мондый сүзләр бар: *«Хаҗи бу көннәрдә Оренбургтан «Кырык мисал»ны алдырып, соңрак Кызылъярдан «Ибраһим Кунакбай үләңдәре»н алдырды. Мин әүвәл «Кырык мисал»ны яратып укыдыгым кеби, Кунакбайга артык мәхәббәт вә ихлас бәйләгән идем. Ләкин соңра таба Кунакбайның үләңендә артык фәсәхәт вә ләззәт табып, Кунакбайны татарның Тукае, гарәпнең Имрәлгәйсе дәрәҗәсенә мендердем. Әүвәл башта Кунакбаев үләңдәрен тәкъдир итә алмавым китапның имлясы бозыклыктан вә үземнең төшенеп укый алмаганлыгымнан булган икән».*

Шулай итеп, Бабич казакъның фольклоры һәм матур әдәбияты белән танышкан. Алар турында үзенең карашын йөрткән, чагыштыргалаган да. Кунакбайны Байторсыннан яхшы итеп табып, бу истәлек дәфтәренә «Нәмүнә өчен» дигән булып, Кунакбайның 7 кисәк шигырен дә керткән. Тагы бер характерлы як бар: Бабич инде шул заманда казакъчалабрак үләң әйтүне дә булдыра алган. Без моны да шушы ук истәлек дәфтәрендә күрәбез.

Бабич казакълар арасына берничә тапкыр барган. Вәләкин башкалары турында икенче дәфтәрләрендә бардыр. Боларны җыярга, өйрәнергә кирәк. Шуның белән бергә казакъ әдәбиятының Бабич әсәрләренә беркадәр йогынты ясавы (мәсәлән, ритм ягыннан) искә алынырга тиеш. Бабич аркылы без башкорт әдәбиятына тоташкан кебек, казакъ әдәбиятына да бераз гына чикләшәбез.

## Бабич үзе турында нәрсә әйтә?

Бабич бу дәфтәрендә үзен тән ягыннан тикшерүгә алты биттән артык урын биргән. Ул: «*Язарга сүз таба алмый аптырап торганчы, үземне-үзем тикшереп үтү кирәк. Әйдә, язулардан бер язу булыр!*» – ди. Тикшергәндә, башыннан башлап аяк очына чикле барып чыкмаса да, башы, чәче, маңгае, колаклары, күзе, борыны, авызы, теше, теле, муены һәм җилкәсе турында язып ташлый. Шул ук вакытта психологик якларын да бераз чагылдыра.

Кайбер характерлы урыннарын күчереп китәм. Бабич башы, нервлары турында мондый сүзләр яза: *«Китаптан күрепмедер, кешедән ишетепмедер, ни булса да абый әйтә торган иде: башы артка чыккан кеше артык гакыллы, сабырлы була, башы алга чыкса, артык зирәк вә хәссас була һәм дә очлайган башлы кеше артык хыялланучан вә уйга батучан була, ди торган иде. Мин үз башыма карап шушы сүзнең чынлыгына ышанган идем. Чөнки минем баш никадәр очлы булган кеби, уемның да очы-кырые юк. Башыма бер курку төшеп уйланган вакытта, яхут бер нәрсәдән тәэсирләнеп хыял дәрьясына чумган вакытта дөньямны онытам. Күз*

*алдым томанлана, саңгырау кеше кеби, сүзне ишетммм. Кутыр, таз, пеләш кеби нәрсәләрдән, Ходайга шөкер, башым сәламәт. Әмма авырган вакытымда күбрәк авыруым башымда була. Бәләкәй чакта баш авыруы мине ничә мәртәбә түшәккә еккан иде. Бу яз башым ике мәртәбә авырды. Ләкин захири сәбәпләре бар иде – эссе сугу, йокы калу. Кайвакытта бер сәбәпсез-нисез авырта. Моны мин нервныйлык галәмәте дип беләм. Валлаһи әгъләм биссавап».*

Маңгай вә шуның белән бәйләп, холкы турында мондый сүзләр әйтә: *«Минем маңгай бик киң дә, бик тар да түгел. Уртача. Бездә халык маңгае тарның холкы да тар була, ди. Моңа караганда, минем холкым уртача дияргә ярый. Әмма холкымның уртачамы, түгелме икәнен тәгаен әйтә белмәдегем кеби, теге халык сүзен дә чын дия, ышана алмыйм. Минем холык бик бозылырга да, бик төзәлергә дә мөмкин. Бу мәсьәләне бер Аллаһка тапшырдым. Маңгаем сәламәт».*

**Шәехзадәнең сеңлесе Нәҗибә Бабичева**

Үзенең теле, телдәрлеге турында мондый сүзләр әйтә: *«Телем зур, җалпак, кәефе килгәндә сөйләргә иренми торган тел. Исәрләнеп кеше көлдерергә дә кулыннан килә торган тел. Минем тел әүвәл башта гаять тупас вә нәзакәтсез иде. Соңга таба дөньяны күрә килә, әзрәк шомарырга, төзәлергә юл алды. Хәйлә, мәкер, тәдбирне аз-азлап белә башлады».*

Җилкәсе, шуңа бәйләп ялкаулыгы хакында да әйтми калмый. Характеры турында ул фольклор белән бәйләп фикер йөртергә ярата: *«Җилкәсе чокыр кеше ялкау була, диләр иде. Бу сүз ялганнардан булган бер ялган. Хәлбуки, җилкәм тип-тигез булса да, мин ялкаулардан булган бер ялкау. Җилкәм киң түгел, тар, озын».*

Аның күзе дә сәламәт булмаган икән. Бу турыда мондый юлларны күрәбез: *«Әлхәмдүлилләһ, ике күзем дә бар, сәламәт. Әмма җилгә каршы күздән яшь килә, ерактан артык күрә алмый. Әлбәттә, моның сәбәбе үземнең сагышлыгым һәм керфекнең бик аз вә бик сирәклеге булса кирәк дип уйлыйм. Сул күземә бик нык ак төшү сәбәпле, әти мине духтырга илтте. Бер атна ятып, көчкә төзәлде. Шул сәбәптәндер ки, сул күзем бик ачык күрми. Ялтырап торган нурлы кара күз миңа мөяссәр булмаса да, сәламәт торганына куанам».*

Авызы, чәче һәм колакларына килгәндә, Бабичның шул турыдагы сүзләрен карап үтик: *«Минем чәчем сары, килешсез. Пумала кебек тузып торудан башка эше юк. Үзе тагы ефәк шикелле йомшак. Колакларым сәламәт, бик яхшы ишетә. Ләкин бик зур һәм калкаеп тора. Кайбер казакъ: «Калкан колак мулла», – ди. Авызым бәләкәй авыз түгел, күз тимәсен! Әй, торна дип мыскыл итәләр иде мине малайлар. Вәләкин мыскыл итәрлек тә бар. Буем кеби муеным да озын. Муенны бөгеп йөргәннән шулай озынайган булса кирәк. Хыялый адәмнәр кебек галстук кия башламасам, озын муенны серәйтеп йөрүе кыен булыр инде».*

Бабич бу дәфтәрендә үзенең физиологик яклары турында гына язып калмый. Үзенең социаль чыгышы, идеаллары, карашлары турында да байтак кына яза. Бу моментлар югарыда китерелгән мисаллардан беркадәр күренгән кебек мондый кисәкләрдә дә яхшы ярылып ята. Менә аның «Мулла йоклый» дигән мәкалә сыман язмасы:

*«Эч поша! Гомерем бигрәк тиккә – бушка үтә. Әле менә мәдрәсәдән кайтканнан бирле ничәмә айлар үтте. Яңадан мәдрәсәгә бару вакытлары җитте, шуннан бирле, мин сиңа әйтим, өч тиен көмешлек «йомыш» бетергәнем юк. Шөгыльләнеп уздырырлык эш тә юк шул... Хәер, эшлим дисәң, эш табыла ул. Мәсәлән, дәрес моталага кылу бу бик яхшы һәм дә бик мөкаддәс бер эштер. Фәкать турысын әйтик: ирендерә! Затән мәдрәсәнең үзендә дә «номер» ким сугылганнан куркып кына укыган кеше идем бит мин! Дөрес, романнар вә шигырьләр укырга мин бик яратам һәм аңа иренмим дә. Ләкин манигы куркыры (ягъни курку тыя. – Ред.) бар. Авылда кыйраәтханә (китапханә, уку йорты. – Ред.) юк. Үзең алырга акча ягы такыр. Гомерне тиккә җибәргәнче кыйраәтханә булса, каһәр ару гына булыр иде дә, нә әйтерсең, юк... (Кыйраәтханә мөселан шәһәрләренең барында бар булмас борын авылларда була башласа, Аллаһ күрсәтмәсен, йә кызыл кар явар!)*

*Гомерне бушка уздырмас өчен, йорт эшләре белән шөгыльләнер идем, аңа да иренәм. Юк, иренмим, эшлим дисәм дә, эшли алмыйм. Эшкә гыйлем җитешмәй. Авылда минем иптәшләрем җәй буе эшләп чыгалар, чөнки аларның аталары эшче, эшләтәләр, эшсез яткырмыйлар. Ә минем әти исә мулла, мине иркәләп кенә үстергән, бәләкәйдән эшләтеп өйрәтмәгән, шул сәбәптән эшкә сәләхиятем юк. Инде әтинең исенә төшкән-төшүен. Бәгъзе вакыт миңа: «Әнә, үзең кебек Нәҗметдин вә Сәйфетдиннәр умырып эшлиләр, син дә тик ятма инде, фәлән», – дип караса да, минем колакка керми, бәләкәйдән эшкә сондырмагач!*

*Сабан туена чыксам, халык, мине күрсәтеп: «Әнә, мулла углы мәхдүм чыккан, эшсез генә ашап яткан кеше көчледер ул», – ди һәм мине мәйдан уртасына сөйрәп чыгаралар. Шунда мине замандаш Нәҗмиләр күкрәккә күтәреп селкеп кенә сала. Беләсезме, бу никтән килә? Әлбәттә, билгеле, Нәҗмиләр алар яшьтән эшләп, кыймылдап үскәннәр. Шуңар күрә алар көчле, алар нык. Мин, бичара, эшсез үсү сәбәпле, көчем бик аз. Тәнем дә зәгыйфь. Ышкылып, бөгелеп кенә торам. Ялгыз мин генә түгел, бик күп мәхдүмнәр көчле һәм эшлекле булудан мәхрүмнәр... Бер философ, нигә мине дөньяга чыгарырга сәбәпче булдың, дип, атасына үпкә тоткан бугай. Шуңарга охшаш, әтигә мин дә әйтәм: «Нигә мине эшсез үстердең?» Әйтче, зинһар, мәкалә тозсыз, төзелеше майсыз булса да, рухы бөек түгелме?»*

Бабичның шушы дәфтәрендәге ике шигыре дә аның үзенә социаль яктан булган карашын күрсәтеп тора. Менә аның «Күңелсез чакта җырланган» дигән шигыре:

*«Юкка чыккан, юкка икмәкләрне керткән бәндә мин,*
*Бер зәгыйфь, көчсез, һөнәрсез, буйга беткән бәндә мин.*
*Чәчкә төсле күкрәп үскән иң кадерле чакларын,*
*Бер дә юкка алданып, тик исраф иткән бәндә мин».*

Менә аның «Күңелле чакта җырланган» шигыре:

*«Пакь туып, хак дин белеп, пакьлектә үскән бәндә мин,*
*Бәндәләргә «бәндә» булганннар эчендә алла мин,*
*Саф иман тапланмаса, тәкъдир аяктан чалмаса,*
*Нурлы йолдыздан да нурлы ялтырармын алда мин».*

Күренә: Бабич инде 1913 елны ук үзе турында төрле яктан төрле фикер йөртә, үзенең киләчәктә «Нурлы йолдызлардан нурлы булып» ялтыраячагы турында сүз ача. ■

безнең мирас №7 июль 2021

# Мәхәббәт тоткыны

Шәехзадә Бабич

Күбәләк дип кистерәлмим — сандугач тик таушы бар,
Сандугачкай һич дия алмыйм — күбәләктәй рәүше бар.

Сандугачның, күбәләкнең һәр икәүсен бергәләп,
Һәр икәүсен бергәләп кушкач, яралган бер мәләк;

Әйләнәмне әйләнеп чыкты сихерләп, көлгәләп,
Санки сызды әйләнәмдә сихри ямьнән дүнгәләк!

Дүнгәләк берлән мине әйләндереп, чорнап алып,
Дүнгәләккә күз нурын ялгап, мине сирмәп алып;

Сандугач күк таушы берлән бик матурлап, бер көлеп,
Күбәләк күк рәүше берлән китте фырлап, җилпенеп...

Мин дә киттем, күз нурына тартылып, сәрхуш булып,
Шул сихерле дүнгәләктә коршалып, мәхбүс булып! ■

Санки — **гүяки.** Сәрхуш — **исерек.** Мәхбүс — **тоткын.**

Бабич туган йортның тирә-ягындагы
Күәш елгасы һәм Әсән авылы күренеше

# Хөррият бүләге

## Шәехзадә Бабич

Исте җил... Сүнде бар ялган шәм,
Таралды һәм болыт, һәм томан.
Калыкты чын кояш, кипте яшь,
Капланды «кара көч» йөзтүбән!

Ябылды капусы сәкарьнең,
Ачылды җәннәте Ватанның,
**Чәчелде хуш һава, хөр һава...**
**Бу иде көткәне татарның!..**

И татар, калдың хөр һәм азат,
Хөрлеккә, көрлеккә алдың хак.
Артыңны – салкынны онытып,
Алга бак, кальбең як, ялкынлат!

Юлыңның артын яп – төрлесен,
Алдын ач – ак көннәр күренсен;
Өч йөз ел изелгән ак җаның
Терелсен, терелсен, терелсен!

Аяклан форсатта, хөр чакта,
Канатлан як-якта нур чакта!
Җитәрлек изелдең, яньчелдең,
Бәйләндең тозакка кол чакта!..

Өч йөз ел аһ ордың, Ватан дип,
Җан кыйдың, кан койдың, Ватан дип.
Шулай да ертылды намусың,
Сүгелдең: «Былчырак татар!» – дип.

Җитәрлек ерттылар йөзеңне,
Черттеләр золмәттә үзеңне.
Син хәзер Ватанның хөр углы,
Моннан соң ачык тот күзеңне!

Көн туды караңгы Ватанга,
Юл бетте хакларны таптарга...
Ватаның Русия – уртак мал,
Кер, татар, кер, татар, катарга!..*

Ябылды капусы сәкарьнең,
Ачылды җәннәте Ватанның,
**Чәчелде хуш һава, хөр һава...**
**Бу иде көткәне татарның!..**

*1917*

Сәкарь – тәмуг. Катарга – катына

# «Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, язучылар һәм сәнгать әһелләре июль аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

**12 июль –** журналыбызның редколлегия әгъзасы, ТРның атказанган фән эшлеклесе, РФнең хәрби-тарихи фәннәр академиясе (2009) һәм «Аурупа-Азия» халыкара гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, тарих фәннәре кандидаты, профессор **Альберт Әхмәтҗан улы Борһанов**ка (1956) 65 яшь;

**13 июль –** ТР ФА президенты, физик, физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, ТРның фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт премиясе лауреаты **Мәгъзүм Хәлимулла улы Сәлахов**ка (1951) 70 яшь;

**18 июль –** язучы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, «Сәхнә» журналының баш мөхәррире **Зиннур Зыятдин улы Хөснияр**га (Хөснетдинов, 1961) 60 яшь;

**22 июль –** ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, «Аурупа-Азия» халыкара гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы **Рәшит Акмал улы Гыйләҗев**ка (1951) 70 яшь.

**Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз!** ■

# Чын халык шагыйре

## Шәехзадә Бабич иптәшнең казаклар тарафыннан үтерелүе

Бөек Русия революциясе татарны сөйгән, татарның киләчәк көннәре өчен эченнән көйгән бик күп яшьләребезне үзенең көчле дулкыннарына эләктереп алып китте.

Дөресен генә әйткәндә, дәртле егетләребезнең күбесе шул революциягә читтән генә карап торучы булып кала алмадылар. Мәшһүр шагыйрьләребездән Шәехзадә Бабич та, шөбһәсез, шул дәртле егетләрнең иң дәртлеләреннән, татарны сөюче яшьләрнең иң ихласлыларыннан иде. Шул дәрте, татарның киләчәгенә булган ихласы аны революция дулкыннарына катышып китәргә, үзенең эчендәге иң тирән, иң кадерле көчләрен ярлы халыкның киләчәгенә корбан кылырга мәҗбүр иткән иде.

**« Мәшһүр шагыйрьләребездән Шәехзадә Бабич та, шөбһәсез, шул дәртле егетләрнең иң дәртлеләреннән, татарны сөюче яшьләрнең иң ихласлыларыннан иде.**

**Бабичның апасы Өммегөлсем ире Нәҗип белән**

Соңгы хәбәрләр шул мәшһүр шагыйребезнең Оренбург тирәсендәге Кызыл Мәсҗед дигән җирдә вәхши казаклар тарафыннан кызганычлы сурәттә үтерелгәнлеген белдерәләр.

«Кызыл Идел» газетасының язуына караганда, Бабич иптәш «Вакыт» матбагасы белән Оренбургта Кызыл Мәсҗед дигән җиргә барган. Кызыл Мәсҗедкә казаклар бик каты һөҗүм итә башлагач, матбаганың бөтен эшчеләре качып беткәннәр. Тик Бабич иптәш кенә, ничектер, шунда матбагада бүленеп калган. Шул арада күзләре акайган казаклар матбагага килеп кергәннәр һәм, аны-моны тикшереп тормыйча, бичара шагыйрьнең өстенә ташланып, аны төрле җәзалар белән җәзалаганнан соң, вәхши сурәттә үтергәннәр.

**«Яшь шагыйрьнең безнең дошман кулыннан вакытсыз корбан булуы татар өчен, бигрәк тә татарның ярлы сыйныфы өчен әйтеп бетерә алмаслык зур зыягъ, чөнки мәрхүм татарны, татарның ярлы сыйныфын чын күңеленнән ярата иде.**

---

Бабичны күреп белүчеләрнең сүзләренә караганда, мәрхүм әле яшь, таза бәдәнле, матур, музыка сөюче һәм чиктән тыш шат, һичбер вакытта кайгырмый торган бер егет булган. Аның һәрбер язган нәрсәсеннән тормышка аек һәм көлеп караш күренеп тора. Аның язган шигырьләре һәрвакыт көчле, һәрвакыт укучыларның күңелен күтәрә торган нәрсә булалар иде.

Шагыйрьләребезнең күбесе шушындый матур тормышка җылап караганда, матур айлы кичәләрдә безнең җансыз, рухсыз шагыйрьләребез җә дар агачына барып асылынырга, җә суга ташланырга хәзер торганда, үзләренең аһ-ваһлары белән шушындый матур тормышны ачуланганда, Бабич иптәшнең ялкынлы һәм күңелле шигырьләрен уку никадәр җанга рәхәт бер эш булса, шул ялкынлы шигырьләрне язучы кешенең гаять дәрәҗәдә кызганыч сурәттә кара йөрәкләр кулыннан үтерелү хәбәрен ишетү дә шул дәрәҗә күңелсездер.

Шөбһәсез, яшь шагыйрьнең безнең дошман кулыннан вакытсыз корбан булуы татар өчен, бигрәк тә татарның ярлы сыйныфы өчен әйтеп бетерә алмаслык зур зыягъ, чөнки мәрхүм татарны, татарның ярлы сыйныфын чын күңеленнән ярата иде.

*Шуңар күрә мәрхүм шушы юлда шаһит булды да.*
*Җәнабе Хак мәрхүмнең каберен нурлы итсен.*

*Кызыл Армия. – 1919. – 16 июнь.*

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

# Шәехзадә Бабич музее

Татарның мәшһүр шагыйре Шәехзадә Бабичның музее Башкортстан Республикасының Дүртөйле районындагы Әсән авылында урнашкан.

Музей 1995 елда шагыйрьнең 100 еллык юбилее уңаеннан ачылган.

Биредә 3 экспозиция залы бар. Беренчесендә Әсән авылының тарихы, танылган кешеләрнең тормыш юлы белән танышырга мөмкин. Икенчесе Ш.Бабичның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган. Өченче залда этнографик материаллар урын алган.



**Бабичның әтисе Мөхәммәтзакир хәзрәт**

**Әсән авылында Шәехзадә Бабич музее**

**Музейның өченче залыннан бер күренеш**

**Шәехзадә Бабичның дусты Зәкигә бүләк иткән күлмәге. Ул Зәкинең Бөре шәһәрендә яшәүче сеңлесе Зәйтүнә Галиевада сакланган.**

Шәехзадә Бабич әнисенең тегү машинасы

Бабичевлар гаиләсеннән калган ядкярләр

Әсән авылы күренеше ■

# Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

## Порт-Артурга таба

Мин, Мукденда ике көн кунганнан соң, Порт-Артурга юл тоттым. Анда да ике көн кундым; күрергә лаеклы җирләрен карап йөрдем.

Бу җирләр инде тулысынча японнар кулында. Мин гыйлем кешесе түгел, шуңа күрә болар хакында төгәл мәгълүмат бирә алырмын дип уйламыйм. Шулай да кыска гына итеп әйтәм: бу төбәкне җир йөзендәге гыйбрәтханә дип атарга мөмкин. Нинди гыйбрәтханә икәнен ачыклар өчен, бары тик шуны гына хәтерләтәм: руслар

---

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

бу ныгытманы төзү өчен йөз ун миллион сум акча сарыф иткәннәр. Йөз ун миллион сумга төшкән азапны уйлап, шулкадәр азап кергән ныгытманың соңыннан хәрабәгә әйләнгәнен күреп, кеше ничек шаккатмасын?! Әле моны җимерү өчен дә әллә ниләр сарыф ителгәндер! Никадәр җаннар фида ителгәндер. Боларның һәммәсен уйласаң, бу ныгытма гына түгел, гомумән, коточкыч олы хәрабәлек күз алдына килми калмый. Мин нык ышанып әйтәм: бу Кыяматкә кадәр варварлар дип атау дөрес дип саналган Тимур, Батый һәм Чыңгызлар бөтен гомерләрендә җимергән шәһәр-ныгытмаларның һәм алар юк иткән мал һәм җанның әгәр саны алынса, барысы бергә дә Порт-Артур югалтуы кадәр була алмас.

Әлеге җирләрне яулап алгач, японнар төзекләндерү эше белән һич шөгыльләнмәгәннәр. Ныгытма урынындагы хәрабә – музейханә диярсең – ничек бар шулай тора.

Бу җирләрдә озак вакытка кала алмавым сәбәпле, әллә ни әһәмиятле мәгълүмат бирә алмыйм. Әлеге җирләрнең Аллаһының кодрәте белән бар ителгән рәвеше бигрәкләр дә исең китәрлек. Тау сыртларының гаҗәеп күренеше, кыяларның төп-төз булып күккә үрләве, күз гиздерүгә, бик тирән уйларга сала.

Порт-Артур. Бу атаманың әйтелеше генә дә бик күп нәрсәне хәтерләтә. Беренчедән, ул – бөек Русия дәүләтенең борыны бик каты бәрелеп канаган урын. Инде ике йөз ел буе гел Көнчыгышта эчкә үрмәләп, Аллаһының колларын, миллионлаган инсанын кан-яшь түктергән залимнәрнең бер селтәнүдә илле ел кирегә, чокырга таба тәгәрәве.

Дөньяда бернинди исеме дә, дәрәҗәсе дә булмаган кечкенә генә бер кавемнең бөтен җир йөзендәге кавемнәрне дер селкетеп мәйдан уртасына килеп чыгуы таң калырлык һәм онытылмаслык хәл булды.

Болардан тыш, әлеге җирләрне күргәч, хәтергә киләчәк нәрсәләрне инде күз алдына китерергә мөмкин: замананың тәрәккыяте һәм егерменче гасырның мәдәнилеге күзлегеннән чыгып караганда, биеклекләргә күтәрелгән хөкүмәтләр, милләт фәкыйрьләренең көне-төне тир түгеп тапкан малларының, авызларына керергә торган икмәкләренең зур гына өлешен, мәдәният һәм мәгариф өчен дигән булып, кулларыннан тартып алалар. Күбесенчә таяк көче белән, җәберләп, каһәрләп тартып алалар. Авыл ярлысының соңгы самавырын, табак-савытын тартып алып саталар да шуннан тупланган акчаны соңыннан кечкенә бер төркемнең кәеф-сафасы өчен корбан итәләр. Аңа гына да канәгать булмыйча, читкә дә кулларын суза-суза, ахыр чиктә сугышларга сәбәп булалар. Аннары, тагын да шул ук бичара фәкыйрьләрне Ватанны сакларга чакыралар, миллионнарча адәм баласының канын коялар, көтү-көтү корбан бирәләр, төргәк-төргәк акчаларны Аллаһының тауларына алып менеп очыралар.

Мәдәнилек исеменә төренеп башкарылган вәхшилекне менә шул рәвешле хәтерләтеп торганга, гыйбрәтханә ул – Порт-Артур. Монда халык кан дәрьясына батты, миллионлаган акчалар туздырылды, ачлыктан, караусызлыктан күпме яшь балалар корбан китте. Хәтергә гел менә шулар килә. Дөресен әйтим, мин махсус барып, Порт-Артур коменданты Стессельнең[1] үзе һәм хатыны[2] яшәгән җирне карадым. Болар икәү кечерәк кенә, ләкин бик ышык, аулак, нык саклау астында торган җирдә яшәгәннәр икән. Әйләнә-тирәләрендә меңнәрчә яралы солдат булган. (Бөек кеше

---

[1] Порт-Артур шәһәренең рус-япон сугышы елларындагы (1904-1905) коменданты генерал Анатолий Михайлович Стессель (1848-1915) турында сүз бара *(тәрж.иск.)*.

[2] А.М.Стессельнең хатыны Вера Алексеевна Стессельнең туган елы билгеле түгел. 1919 елда атып үтерелә. Аның хакында мәгълүмат аз. Порт-Артурга багышланган әдәби әсәрләрдә ул нык куллы, үз дәрәҗәсен белә торган ханым – генерал хатыны итеп сурәтләнә *(тәрж.иск.)*.

**Порт-Артур. Эчке рейд һәм шәһәр күренеше. XX гасыр башы**

һәрвакыт бөек булып кала.) Командующий җәнапларының хатыны анда да вакытын бушка үткәрмәгән. Бер сыеры бар икән, шуның сөтен савып, һәр көн лазареттагы яралы солдатларга шешәсен ике сумнан сата икән. Шул рәвешле, форсаттан файдаланып, акча да эшләгән.

Мәдәнилекнең иң ялтыравыклы тарих битләрен тутырып торган вакыйгалар менә шулар. Дөресен генә әйтим: Порт-Артурда йөргәндә, минем күзләрем башка берни күрмәде. Кай тарафка гына карасам да, ул хәрабәләр минем баш миемне бораулады, теңкәмә тиде. Аз гына фикер йөртү сәләтенә ия булган кешенең уй-фикерен биредә башка нәрсә мәшгуль итә алмыйдыр да дип уйлыйм.

## Шанхай-Куан

Ике кич кунгач, Порт-Артурдан китеп барышлый, Лийайанг дигән җиргә тукталдым, аннан туры Шанхай-Куан шәһәренә киттем. Бу кечкенә генә, ләкин бик төзек шәһәрчек икән. Шанхай-Куан кайчандыр хәрби үзәк булып торган.

Шәһәрчек бик зур таш дивар белән әйләндереп алынган. Мин, килгәч тә, бер кунакханәгә тукталдым. «Аурупа кунакханәсе» дип атала иде, ләкин эчендә Аурупа белән бәйләнеше булырлык берни дә күрмәдем. Хуҗалары – озын чәчле кытайлар, берни аңларлык түгел, тел белмим. Чын-чынлап чит-ят җиргә килеп эләктем. Тик адәм баласына никадәр генә җиде-ят булса да, берәр чарасы табыла, чөнки максат – ни генә булса да – биредә төн куну. Иртән иртүк поездга утырып Тензингә [Тяньцзинь шәһәренә] китәргә уйлыйм. Кытай илендә поездлар төнлә кузгалмый, шул сәбәпле биредә көтәргә туры киләчәк.

Иртән тиешле сәгатьтә станциягә килеп җиттем, билетымны алып, вагонга кереп утырдым. Минем арттан ук бер кытай кешесе керде, каршымдагы урынга урнашты.

Йөземә карап-карап ала бу. Көтмәгәндә, бу кеше русча: «Сез «Өлфәт» газетасын чыгаручы Рәшит әфәнде түгелме?» – дип сорады. Мин: «Әйе», – дип җавап бирүгә, кытай кешесе урыныннан сикереп торды да минем әйберләремне җыя башлады. «Туктагыз, Сез нишлисез?» – дисәм дә, колак та салмады. Бары тик: «Әйдәгез, тизрәк, поезд кузгала», – ди иде. Бөтен әйберләремне күтәреп алды да вагоннан төште, артыннан төшәргә мәҗбүр икәнемне аңладым. «Аллаһым, бу нәрсә булды инде?» – дип уйлыйм, ни дияргә дә белмим. Калган әйберләремне алып вагоннан төштем генә, поезд кузгалып китеп тә барды. Бу кешенең кем икәнен дә белмим. Башта бер-ике сүз русча әйткән иде, аннары никадәр белгәне аңлашылды: русчасы шул ике-өч сүздән гыйбарәт икән.

Бу кеше башта минем әйберләремне бер арбачыга бирде. Аннары, кулымнан тотып, мине каядыр алып китте. Эчемнән генә: «Йа Раббым, бу нәрсә булды инде?» – дим. Ниһаять, бер өйгә килеп җиттек. Бик матур, ару җир. Бу кешенең тавыш-тыны юк, бары тик миңа карап елмая гына.

Мин дә карыйм, ләкин хәтеремә берни килми. Ара-тирә шатлыгын белдерә, елмая: «Дус, дус», – дип кабатлый. Табынга тәмле чәйләр, ашлар килде. Бер ярты сәгатьләп вакыт үткәндер, ләкин бу вакыт миңа ярты ел булып тоелды. Шул арада, ишектән бер кеше керде. «Әссәламу галәйкүм», – дигәненә: «Вә галәйкүм әссәлам», – дип җавап бирдем, ике куллап күрештек. «Әлхәмдүлилләһ алә динил-ислам», – диде дә, бик ачык йөз белән миңа карап: «Әнә йагъләмү әнтә рәҗүлүн алимүн хәйрүн кәсирүн [мин беләм, син бик хәерле галим кешесең]», – дип сүз башлады. Мин исә:

– Мин бу кешене таный алмадым. Кем бу кеше? – дидем.

– Петербург йәгъләмү..., – диде. Ягъни, Петербургта танышкансыз, дип әйтергә тели икән.

Шунда исемә төште: берничә ел элек, Петербургта яшәгәндә, кытай мөселманы булган бер генералны өемдә кунак иткән идем. Мине җилтерәтә-җилтерәтә поездтан төшереп өендә кунак итәргә теләгән кеше – менә шул иске танышым, ә инде бирегә килеп безгә тәрҗемәче булган кеше Шанхай-Куан имамы икән. Шулай итеп, мин кунакка килгән булып чыктым. Әлхәмдүлилләһ, бу җирләрдә дә безнең дин кардәшләребез яши икән.

Аһ, адәм углы йөз мең телдә шөкер итсә дә аздыр, никадәр нигъмәт эчендә мин! Бер кәлимә-и тәүхид мине кытай кешесенә дә кардәш иткән, шул кәлимә-и тайибә, ягъни изге сүз аркасында бер кытай мөселманы, зур шатлык хис итеп, мине өендә кунак итә, йөземә карап дустанә елмая. Боларны уйлап хәйран калмау мөмкин түгел. Бу җирләрдәге бер христиан кешесе Аурупадан килгән бер христиан өчен шулкадәр шатлык хис итәрме икән? Андый хәлнең булуы мөмкин түгел дип уйлыйм.

Без Шанхай-Куан имамы белән авырдан булса да гарәпчә сөйләшәбез. Имамның сөенечен сөйләп-аңлатып бетерерлек түгел. Сүз әйтергә җыенганда, имам әфәнде балкый дип әйтерлек дәрәҗәдә киң итеп елмая: «*Әлхәмдүлилләһ, әнтә галимун кәбирун күлли мүслимани ихвәтун әнтә йәзбәху илә-Чин йанзуру таййибун йәфраһу хайрун кәсир*». Бичара имамның бу сүзләр белән миңа менә шуларны әйтәсе килә: «Аллаһка мактау булсын, зур галим кеше Сез, Кытайдагы мөселман кардәшләрегезне күрергә барасыз. Бик яхшы, мин бик шат». Кулын йөрәгенә куеп: «Кальбуһу йәфраху кәсир», – дип, елмаюын дәвам итә. Иң башта әйтәсе килгән сүзем шул: мең йортлык шәһәрчек имамының гарәп телен белүе менә бары тик бу дәрәҗәдә генә. Йа Рабби, Исламият ни хәлләргә төшкән! Икенче яктан, өй хуҗасы да, имам да шулкадәр шат һәм канәгать иделәр, шундый олы хөрмәт күрсәттеләр ки, шөкер итәр өчен

телем дә, каләмем дә гаҗиз. Бер сәгать сөйләшеп утырдык. Бар нәрсә турында да сөйләштек. Шул ярым-ярты гарәпчә дә эшебезгә бик ярады.

Аннары мәчет һәм мәдрәсәләрне карарга дип чыктык. Бу шәһәрчектә кечерәк кенә ике мәчет бар. Берсе – кала диварларының эчендә, икенчесе – тышында. Икесенә дә мәдрәсә дә кушып салынган. Берсендә бары тик бер шәкерт укый, икенчесендә – өчәү. Шәһәрчек кечкенә генә, мөселман кешесе дә бик аз. Шулай булса да, Ислам билгесе булган азаны Мөхәммәди әйтелә.

Бераздан без, имам әфәнде белән бергә, Шанхай-Куан тирәсендә йөрергә дип юлга кузгалдык. Әйләнә-тирә киң сахра, ике сәгатьлек юлдан соң таулар башлана икән. Шанхай-Куанның көнбатыш тарафында тау өстендә кешеләр күренә иде. Имамнан: «Кемнәр ул анда?»– дип сорадым. Имам әфәнде: «Ләбәһ йасы», – диде. Монастырь икәнен, христианнарныкы булуын чамалап аңладым. Шул җиргә кадәр бардык. Зур гына монастырь, эчендә унлап кеше бар. Попларының рус икәнен күреп, бераз сораштырасым килде.

## Шанхай-Куан янындагы монастырь

– Бу монастырьны ник шәһәрдән болай еракка салдыгыз? – дип сорадым.

– Шәһәр эчендә булса, файдасы булмый, – диде. – Кытайлар нәфрәт белән карый. Синең христиан булырга күндергән кешеңне кире үзләренә аударалар. Монда исә, кулыбызга төшкәннәр аз булсалар да, нык булалар. Бала чакларында ук христиан итәбез дә, аннары өч ел буе берәүгә дә күрсәтмибез. Соңыннан рөхсәт итсәк тә, күрешү-аралашулары озакка сузылмый. Шуңа күрә безгә бәйлелекләре көчлерәк булып кала бирә.

– Бала чакларында ничек алай кулга төшерә аласыз?

– Саталар. Кайберләрен фәкыйрь аталар сата. Күбесенчә хунхузлар сата. Маньчжурлар да сата, ләкин сирәк.

– Бер баланы ничә акчага сатып аласыз?

– Кытлык һәм сугыш елларында очсыз була: 5-6 доллар, күп дигәндә 10 доллар. Башка вакытларда 50-60 доллар да түләп алабыз. Бездә бу хәл күп түгел, акчабыз да юк. Инглизләр һәм итальяннар бик күп ала. Америка кешеләре дә бик күп сатып алалар.

– Сезнең монастырь кешесе күпме? Биредә монастырь салынганга ничә ел булды?

– 25 ел булды. Монастырьда кеше күп түгел. Барыбызны бергә санасак, монастырь кешеләре һәм биредә тәрбияләнгәннәр бергә мең ике йөз чамасы булыр.

– 25 ел эчендә христиан булган кешеләрнең саны букадәрме?

– Әйе, барысы бергә букадәр.

– Еллык чыгымыгыз никадәр?

– Безнең чыгым бик аз, әйтәм бит, акчабыз да бик юк. Бөтен Кытай илендә бездән дә фәкыйрьрәк башка бер монастырь юктыр да. (Игътибарга лаек.) Елда утыз мең сум тирәсе акча тотабыз.

– Сезнең монастырегыз ник фәкыйрь?

– Бу тирәләрдә мөселманнар яши. Алар арасыннан христианлыкка күчүчеләр бөтенләй юк. Җәмәгатькә хезмәт күрсәтә алмыйбыз, шулай булгач, акча бирүче дә юк. Үзебез дә бик аз җыя алабыз.

– Мөселманнар христиан булмыйлармы? Балаларын сатмыйлармы?

– Балаларын катгый сатмыйлар. Христиан булган бер кеше бар.

– Бөтен Маньчжуриядә ничә монастырь бар?

– Безнеке – 28, инглизләрнеке бик күп, санын әйтә алмыйм. Аларның кешеләре дә күп, монахлары да бик күп.

– Бөтен Кытай илендә христианлыкка күчкән кешеләрнең санын беләсезме? Мондый статистика бар микән?

– Төгәл генә әйтә алмыйм. Безнең Маньчжуриядә бик аздыр дип уйлыйм. Бер миллионнан да артык түгелдер. Христианлыкны кабул иткән кешеләр дә тышкы яктан гына христиан булалар. Мәсәлән, берәүләр Кытай хөкүмәте тарафыннан дар агачына хөкем ителә. Әгәр шулвакыт христианлыкны кабул итсә, консуллыкларның ярдәме белән үлем җәзасыннан котыла. Мондый юл белән христиан булганнарның безгә әллә ни исләре китми, күбесе бераздан кире үз диннәренә кайта. Көньякка таба китсәк, Франция колонияләрендә христианлашу бик зур тизлек белән алга бара. Ул җирләрдә христианлыкка күчкән кешеләрнең саны инде ике миллион булгандыр яки шуңа якынлашадыр.

– Ул колонияләрдә христианлашуның артуына нәрсә сәбәп булып тора икән?

– Ул якларда күбесенчә Тибет кешеләре христианлыкны кабул итәдер дип уйлыйм. Андагы миссионерларда акча да күп, эшчән кешеләре дә күп, бөтен авылларны бер итеп йөреп торалар. Моннан тыш, ул якларда әфьюн куллану да киң таралган. Христианлыкка анда шул әфьюн кулланучылар күчә. Әфьюны беткәч, бер тартма әфьюн өчен шунда ук христианлыкны кабул итәләр. Нигездә, күндерү коралы да шул. Ул җирләрдә Француз хөкүмәте, консуллыклар христианлыкка бик зур ярдәм күрсәтәләр. Тункин[3] якларында, мәсәлән, мөселманнардан кала бөтен халык христианлашкан. Бөтен Франция колонияләрендә хөкүмәт кытайларның чәчләрен мәҗбүри рәвештә кистергән.

Шулай сөйләшеп алганнан соң, миссионер җәнаплары белән саубуллашып, китеп бардык. Кичке азан вакытында Шанхай-Куанга кайтып җиттек. Шулай итеп, өй хуҗасы Даут әфәнде миңа зур сый-хөрмәт күрсәтә, имам әфәнде дә янымнан китеп тормый.

Шул көнне кичен Шанхай-Куан халкы мәчеткә җыелган иде. Мине шунда чакырдылар. Сүз биргәч, мин, фарсы телендә чыгыш ясап, Кытай мөселманнарының яшәү рәвешен бераз тәнкыйтьләдем. Арабызда булган Али Мәүләви Сахиб Зат исемле бер Һиндстан кешесе мин сөйләгәннәрне кытай теленә тәрҗемә итте. Мин бер сәгать сөйләдем, аннан соң Али Мәүләви Сахиб тә «Кытайларда гыйльме кыйраәт, тәҗвид һәм махрәҗләрнең[4] булмавы диннең зәгыйфьлегеннән килеп чыга» рәвешле сүзләр кулланып, тәҗвид гыйлеменең һәм Коръән укуның фарзы кифайә[5] булуын да хәтерләтеп, бу мәсьәләдә бөтен Кытай голәмәсенең Аллаһ каршында җаваплы булуын искәртеп чыгыш ясады.

Җыелыш тәмам булганнан соң, кытай мөселманнары арасында гөрелте кубып алды. Мин башта аңламый тордым. Мәүләви Сахиб аңлатып бирде: алар да голәмәне гаеплиләр икән. «Безне голәмә шушы хәлгә китерде», – дип зарланышканнар. Имам әфәнде, минем яныма килеп: «Мүслимун күллүһум йәфрах», – диде. «Мөселманнар барысы да Сезнең чыгыштан канәгать калды», – дип әйтергә теләве булды инде.

*Төрекчәдән* ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

[3] Гарәп хәрефләре белән текстта Тункин рәвешендә язылган булса да, без бирედә Чунцин провинциясе турында сүз бара дип уйлыйбыз *(тәрж.иск.)*.

[4] Коръәне Кәримне уку гыйлеме, кагыйдәләре һәм авыз куышлыгында авазлар (бу очракта гарәп теле авазлары) ясала торган урын *(тәрж.иск.)*.

[5] Фарзы кифайә – барлык мөселманнарга үтәмәскә дә мөмкин булган фарыз гамәл. Ул фарызны мөселманнарның бер өлеше үтәсә, калган өлеше гөнаһтан котыла дип санала. Мәсәлән, җеназа намазы шундыйлардан *(тәрж.иск.)*.

Безнең мирас №7 июль 2021

# Ризаэддин Фәхреддин милләтләр үсеше турында

Лилия Байбулатова

Ризаэддин Фәхреддин

1917 елда Оренбургта чыга торган «Шура» журналында Ризаэддин Фәхреддин «Карт милләтләр үләләр, яшь милләтләр туалар» исемле мәкалә бастыра. Мәкалә авторының үз алдына ике бурыч куйганлыгы ачык күренә. Беренче бурыч – иҗтимагый фәннәрне үстерүдә көнчыгыш галимнәренең көнбатыш галимнәренә караганда алга китүе, икенче бурыч – милләтне саклап калу юлларын күрсәтү.

Риза Фәхреддин ни өчен мондый бурычлар куя соң?

Беренче бурыч болай ачыклана. Автор сүзләренчә, XIX гасыр ахырында-XX гасыр башында көнбатыш галимнәренең үзләрен җәмгыятьне өйрәнү фәненә нигез салучы итеп күрсәтүләре дөрес түгел, чөнки 500 ел элек гарәп галиме Ибне Хәлдун үзенең «Мөкаддимә»сендә дәүләт яшәешен кеше тормышы белән чагыштырып аңлаткан. Шулай итеп, көнбатыш галимнәре күптән билгеле булган белемнәрне яңа фән итеп күрсәтергә теләсәләр дә, бу чынбарлыкка туры килми. Әмма көнбатыш галимнәре бу фәнне үстерүгә зур өлеш керткәннәр, дип яза Риза Фәхреддин. Шул ук вакытта ул, бер яктан, Ибне Хәлдунны якласа да, икенче яктан, галим аның дәүләт яшәеше теориясенә тәнкыйть күзлегеннән карап, кимчелекләрен күрсәтә. Мәсәлән, Ибне Хәлдун фикеренчә, һәр дәүләт 100-120 елдан соң юкка чыга. Риза Фәхреддин, үз чиратында, бу фикер белән ризалашмыйча, һәрбер дәүләтнең яшәү вакыты башка сәбәпләргә нигезләнгән, дип әйтә. Шуны да искәртеп китәргә кирәк, Р.Фәхреддин бу мәкаләдә дәүләт белән милләт төшенчәләрен бер итеп күрә, алар арасында аерма тапмыйча, бертигез куллана. Шул яктан ул милләт яшәешенең сәяси теория тарафдарларына якын тора. Әлеге теорияне беренче булып XVIII гасыр голланд философы Гуго Гроций аңлата һәм аның нигезендә милләтнең сәяси берлек мәгънәсе ята, ди. Әлеге берлек башка бер дәүләт эчендә үзбилгеләнүгә омтыла һәм аның вәкилләрен уртак тел, билгеләр, дәүләткә һәм аның кануннарына лояль караш берләштерә.

Дәүләткә һәм милләткә булган карашыннан чыгып, Ризаэддин Фәхреддин икенче төп темасын да ача: ул – милләтне ничек саклап калырга?

Үз алдына галим мондый сораулар куя:

1. Зур милләт, һичшиксез, югалырга тиешме?
2. Милләтнең бетүе нинди нәтиҗәләргә китерә?
3. Милләтнең көчсезләнүендә һәм бетүендә нинди сәбәпләр ята?
4. Милләт бетүдән сакланып буламы?

Шул сорауларга җаваплар Ризаэддин Фәхреддиннең милләт үсеше теориясен тәшкил итә.

Куелган сорауларга ул болай җавап бирә:

1. Милләт бетүдән куркырга кирәкми, бу гадәти хәл, кайбер очракларда кирәкле дә. Милләтнең үлүе кеше үлеменә охшаш, ул ике очракта да тышкы һәм эчке элемтәләрнең өзелүенә бәйле.

2. Милләтнең үлеме аның кешеләре дә юкка чыга дигән сүз түгел, киресенчә, алар исән калырга һәм тагын да куәтләнергә мөмкин. Риза Фәхреддин фикеренчә, һәрбер милләт эчендә вак яшь милләтләр яши һәм карт милләт үлгәндә, алар, аның варислары буларак, элек куелган максатларга ирешәләр, җәмгыятьне, фәннәрне яңарталар. Димәк, бер милләтнең үлүе икенче бер яңа көчле милләт барлыкка килүгә сәбәп була.

3. Милләт үлүенең сәбәпләре нәрсәдә?

А) Нәселдәнлек югалу. Ягъни бер милләт икенче бер милләт арасына кереп, аның эчендә югала, икенче милләт исә, шул сәбәпле яңарып, зураеп китә.

Ә) Икътисадый сәбәп. Бу сәбәпне Ризаэддин Фәхреддин ике яктан ачып бирә. Беренчедән, ул икътисадны гореф-гадәтләр белән бәйли. Гореф-гадәтләрен онытып барган халык төшенке була, эшләргә теләге, алга таба үсешкә омтылышы булмый, шулай итеп, тормышы бозыла һәм артка таба тәгәри.

Р.Фәхреддин икенче бер хезмәтендә икътисады фәкыйрь булган халык гореф-гадәтләрен дә саклап кала алмый, дип билгеләп үтә. Ул киләчәктә аларның кайбер күренешләрен төрле музейларда гына күрә алачагын искәртеп уза. Икенче яктан, Ризаэддин Фәхреддин салымнарның артуын, тимер юл билетларына бәяләрнең күтәрелүен дә милләтнең юкка чыгуына икътисадый сәбәп итеп күрә. Моны ничек аңлатырга була? Безнеңчә, ди ул, халык өстендә зур салымнар булганда, тимер юл билетларына бәяләр күтәрелгәндә, кеше күбрәк үзенең көндәлек тормышын кайгырта, гаиләсен ашатырга-эчертергә акча эзли, шуңа күрә аның милләт, мәдәният турында уйланырга вакыты юк, еракта яшәүче милләттәшләре белән аралашырга мөмкинлеге аз, димәк, милләтнең эчке элемтәләре югала башлый һәм милләт үләргә мөмкин.

Б) Әхлаксызлык. Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләрендә әхлак мәсьәләсе еш күтәрелә һәм күпчелек очракта ул аны гаилә темасы белән бәйләп күрсәтә. Галим фикеренчә, әхлак гаиләнең нигезендә ята һәм аннан башка ул бетә. Шул ук вакытта милләтнең нигезендә дә гаилә ята дип саный Р.Фәхреддин. Димәк, гаиләнең әхлаксызлыгы милләтнең бетүенә сәбәп була.

В) Зәгыйфь, кечкенә милләтләрне кимсетү. Көчле, зур дәүләт яки милләт аның янындагы кечкенә милләтне кимсетә башласа, бу исә зур милләтнең бетүенә сәбәп була. Р.Фәхреддиннең билгеләп үтүенчә, бу очракта зур милләтнең юкка чыгуы тиз булмый, ә кайвакыт ул тукталып калырга да мөмкин. Мәсәлән, әгәр дә зур милләтнең аны алыштырырлык варисы булмаса яки ул кечкенә милләткә золым кылудан туктаса, милләтнең таралуы кичектерелеп тора.

4. Милләтне саклап калу, аны инкыйраз юлына чыгармас өчен бердәнбер юл – алдарак күрсәтелгән сәбәпләрдән сакланырга кирәк. Ул очракта милләт яки дәүләт озак һәм яхшы яши. Шулай ук киләчәк буыннарга милләтләрнең ни өчен үлгәннәрен аңлатырга кирәк, бу исә алар үлгән милләт юлыннан бармас, ул җибәргән хаталарны кабатламас өчен әһәмиятле.

Шулай итеп, йомгак ясап, Ризаэддин Фәхреддин милләтне сәяси-мәдәни берәмлек итеп күз алдына китерә, дип әйтә алабыз. Милләт белән дәүләт аның өчен бертигез, шул ук вакытта һәрбер милләт мәдәниятен саклап калырга һәм алга таба үсеш өчен икътисадын үстереп, башка милләтләр белән катышмаска тиеш. ■

# Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

## Беренче дәрес

## Аллаһы Тәгаләнең барлыгы, берлеге, мәңге булуы. Кадәм[1] вә бәкыс[2]

**Мөгаллим:** Беләсезме, балалар, бу бүлмә ничек атала?
**Шәкертләр:** Сыйныф дип атала.
**Мөгаллим:** Ә бу өй ни дип атала?
**Шәкертләр:** Мәктәп дип атала.
**Мөгаллим:** Сез бу мәктәпкә ни өчен җыелдыгыз?
**Шәкерт:** Укыр-язар өчен җыелганбыз.
**Мөгаллим:** Тагы нәрсә өчен?
**Шәкерт:** Дин өйрәнер өчен.
**Мөгаллим:** Дөрес, сез монда укыр-язар һәм дин өйрәнер өчен килгәнсез. Ата-аналарыгыз сезне монда шуның өчен җибәргән. Мин хәзер сезгә дин дәресе бирә башлаячакмын. Мин сездән бәгъзе нәрсәләр сорармын. Сез барыгыз да бердән җавап бирмәссез. Парталарыгызда селкенми, тавышланмыйча гына утырыгыз. Сораган сүзне белгән кеше кул күтәрер. Без бу бүлмә ничек атала дигән идек әле?
*(Шәкертләр кул күтәрәләр.)*
**Мөгаллим:** Йә, Габдуллаһ, торып син җавап бир.
**Шәкерт:** Сыйныф дип атала.
**Мөгаллим:** Хәзер сез нәрсәгә утыргансыз?
**Шәкерт:** Партага утырганбыз.
**Мөгаллим:** Ә мин нәрсәгә утырганмын?
**Шәкерт:** Урындыкка утыргансыз.
**Мөгаллим:** Шулай, мин – урындыкка, сез партага утыргансыз. Ә әнә теге такта ни дип атала?
**Шәкерт:** Сыйныф тактасы дип атала.
**Мөгаллим:** Менә мин синнән сорыйм әле: бу парта, урындык, өстәл, сыйныф такталарын кем ясаган?
**Шәкерт:** Агач остасы ясаган.
**Мөгаллим:** Ә бу мәктәпне кем салган?
**Шәкерт:** Агач (таш) осталары салганнар.
**Мөгаллим:** Соң бу парта, өстәл, урындык, сыйныф тактасы, мәктәп үз-үзләреннән генә ясалганнармы?
**Шәкерт:** Юк, үзләреннән генә ясалмаганнар. Аларны агач осталары ясаганнар.

[1] Кадәм – алды чиксез.
[2] Бәкыс – ахыры чиксез.

**Мөгаллим:** Алай икән. Бу нәрсәләрне агач осталары ясаганнар икән. Соң менә бу кырлар, болыннар, зур куе урманнар, чылтырап аккан матур чишмәләр, елгалар, көзге кебек ялтырап яткан күлләр, биек таулар – боларны кем ясаган дип беләсез? Әллә болар үз-үзләреннән ясалганнармы?

**Шәкерт:** Юк, бернәрсә дә үз-үзеннән генә ясалмый.

**Мөгаллим:** Соң аларны кем ясаган? Әллә балта осталары ясаганнармы?

**Шәкерт:** Юк, балта осталары аларны ясый алмыйлар.

**Мөгаллим:** Соң кем ясаган аларны?

**Шәкерт:** Аллаһы Тәгалә ясаган.

**Мөгаллим:** Бик дөрес әйттең, афәрин! Җир, җирдәге таулар, урманнар, чишмәләр, күлләр, елгалар, болыннар – барысын да Аллаһы Тәгалә ясаган.

Җирдәге адәмнәр, хайваннар, кош-кортларны да – барысын да Аллаһы Тәгалә ясаган. Әнә теге күкне, якты кояш, якты ай вә чекрәеп торган йолдызларны – барысын да Бер Аллаһы ясаган. Икенче төрле әйтсәк – Бер Аллаһы яралткан. Ярый, Габдуллаһ, син утыр әле. Яле, шәкертләр, бердән җавап бирегез: җир, җирдәге бөтен үсемлекләрне, таулар, күлләр, елгалар һәм диңгезләрне, инсаннарны, хайваннарны, кош-кортларны, күкне, күктәге кояш, ай вә йолдызларны кем яралткан?

**Шәкертләр:** Аллаһы Тәгалә яралткан.

**Мөгаллим:** Йә, Гариф, син торып җавап бир әле? Бөтен дөньяны, дөньяда булган безгә күренгән вә күренмәгән нәрсәләрне кем яралткан?

**Шәкертләр:** Бөтен дөньяда булган, безгә күренгән вә күренмәгән нәрсәләрне - барысын да Бер Аллаһы яралткан.

**Мөгаллим:** Бик яхшы! Миңа тагы бер кат әйт әле! Бу парталар, урындык, өстәл, сыйныф такталарын кем ясаган дигән идек?

**Шәкерт:** Агач остасы ясаган.

**Мөгаллим:** Өстәл, урындык, парталар элек булганмы, әллә агач остасы элек булганмы?

**Шәкерт:** Агач остасы элек булган.

**Мөгаллим:** Шулай шул. Агач остасы элек булган. Ул агач остасы бу нәрсәләрдән элек тә әллә нәрсәләр ясагандыр әле. Ясаган кеше, әлбәттә, ясаган нәрсәләреннән элек була. Шулай ук менә җир, күк, җирдәге вә күктә булган бөтен нәрсәләрне, ягъни бөтен дөньяны яралткан Аллаһы Тәгалә дә Үзе яралткан дөньядан элек булган. Ул һәрвакыт булган, һәрвакыт бар. Йә, миңа сөйлә әле! Синең өстеңдәге бишмәтең гел шулай матур көенчә торамы?

**Шәкерт:** Юк. Гел болай тормый. Бервакыт искерә, туза.

**Мөгаллим:** Ә парта, урындык, өстәлләр нишлиләр?

**Шәкерт:** Бервакыт сына, ватылалар.

**Мөгаллим:** Ә кешеләр, хайваннар?

**Шәкерт:** Бервакыт үләләр. Алар гел үлеп торалар.

**Мөгаллим:** Шулай шул, без белгән нәрсәләр барысы да бервакыт ватыла, җимерелә, бетәләр. Кешеләр, хайваннар да үләләр, үлеп торалар. Ә Аллаһы Тәгалә алай түгел – Ул һәрвакыт булып торачак, һичбер вакыт бетмәячәк.

Яле, шәкертләр, барыгыз бергә минем артымнан әйтегез: «Аллаһы Тәгалә һәрвакыт булган, һәрвакыт бар, һичбер вакыт бетмәячәк!»

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАР КИТАБЫ

# *Әхмәд Ләбиб Каран (1887-1964) шигырьләре*[1]

**Әхмәд Ләбиб Каран**

### Милли мохтарият

Татар бәхете йолдызын күрсә күзем:
Кытыкланам, шатланам, көлә йөзем.
Йөрәгем ярсый, ашкынам, күп сүзем;
Сөйләргә телим, тотлыгам бит үзем.

Аһ, яратам шул милләтем Татарны!
Бу татарлык бер көн чәчкә атармы?
Атар, әлбәт! Бу милләт тик ятармы?!
Яңа туган кояш көндез батармы?

---

[1] «Яшь вакытым җырлары» мәҗмугасыннан (Истанбул: М.Сиралар матбагасы, 1959. – 96 б.) кайбер шигырьләр.

Ирек сөйгән халык кол булмас тагын!
Онытмас ул зинданда кичкән чагын!
Ирке өчен Татар агызыр канын!
Татарлык дип үлер, аямас канын!

Татарлык дип тырышырмын – тырышсам!
Җаным-канымны аямам – сугышсам!
Дошманларын парчалармын – йолыксам!
Бөтен дөньяны ватармын – кызышсам!

Аһ, Татарлык! Синең өчен җан атармын!
Табынсам мин ялгыз сиңа тапармын!
Бөтен хөрмәт синеңдер, син – анамсың!
Барчабызга бер генә зур санәмсың!

(санәм – табыну сыны, сурәте. **– Х.М.**)

Истанбул, 21.11.1917

## Чын ирек өчен ярсу

Илкәемдә аударылу (инкыйлаб. **– Х.М.**): бак менә!
Чын ирек  бит Татар халкына!
Чын ирекне алыр өчен халкыма,
Йөрәккәем кан түгәм дип талпына.

Очкычлардан бомба яуса башыма,
Туплар, танклар чыкса минем каршыма,
Чын ирекне алыр өчен халкыма
Каршы барыр идем шуның барысына!..

...Илдә ак көн өчен йөрәк ашкына,
Карамастан алдына һәм артына.
Корбан булсам халкым, илем бәхтенә –
Ятар идем мәңге рәхәт, шат кына.

Истанбул, 01.01.1918

## Татар берлеге

Башкорт, мишәр, типтәр димә – барысы да Татардыр!
Казакъ, кыргыз, нугай, үзбәк – барчасы да Татардыр.
Барчасының зур ханлары олуг Чыңгыз атадыр,
Бу халыкны бер-берсендән аеры санау хатадыр.

Чуаш, чирмеш, ар, мукшыны бер дә читкә типмәгез!
Тарих буенча бездәндер, аны инкарь итмәгез!
Казан ханында бер идек, бик җыракка китмәгез,
Алар безгә якын килсә, бер дә  читкә этмәгез.

Чыңгыз, Бату заманында безләр бергә булганбыз,
Бер атаның балалары, бер анадан туганбыз.
Бердәм булып яшәгәндә – без бик батыр булганбыз,
Дошманларны өлкәбездән җыракларга куганбыз.

Конья, 16.02.1946

## Зәңгәр Туг (байрак, әләм. – Х.М.)

Без зәңгәрне бик сөябез, зәңгәр – безнең төсебез,
Зәңгәр белән билгеләнгән безнең милли көчебез.
Алтын Урда корылганда алтын белән зәңгәр төс
Бер (? һәм. – **Х.М.**) дә бүре башы килгән Чыңгыз ханнан безгә төс.
Шулар белән төзелгән шул Алтын Урданың көче,
Шуңа күрә зәңгәр булган өлкә тугының төсе.
Искедән бик күп милләтләр зәңгәр тугка баш игән,
Шуның өчен Татарлар да зәңгәр төсне бик сөйгән.
Һәм дә бу төс Татарларда сөю төсе саналган,
Шуның өчен бу төс бездә миллиләшеп дан алган.
Байлык тоткан матур кызлар өстенә зәңгәр кигән,
Моны сөйләүче мин түгел, Татар җырлары дигән!
«Йөгерә-йөгерә җиләк җыя зәңгәр күлмәк кигәне,
Зәңгәр күлмәк кимәс иде, бардыр аның сөйгәне» –
Менә бу җыр сөйләп бирә: зәңгәр – сөю төсебез,
Зәңгәр Тугка гашыйк булсак – туар безнең көчебез.
Безнең Туг бер җилбердәр, бирсә бер күләгә безгә,
Без дә хуҗа булыр идек үз матур өлкәбезгә!

Конья, 12.11.1946

## 15 октябрь

Әй зур Татарның баласы! Төшенчәләр ноктәдер
(үткен, мәгънәледер. – **Х.М.**)
Бер хәтерлә, нинди көндер унбишенче октябрь!
Мең биш йөз илле икедән бирле халык коллыктадыр,
Дүрт йөз ел инде чын ирек кояшы болыттадыр.

Шул көн урыслар кулына төшкән Казан каласы
Ул көн аңа корбан булган бик күп Татар баласы.
«Чын ирек!» – дип җан биргәннәр сансыз Татар баласы.
Ул көн тоткын булган барча Татар кызы, анасы.

Шуңа күрә иң караңгы көндер унбиш октябрь,
Бу көнне без онытмабыз, чөнки Татар уттадыр…

Истанбул, 15.10.1947

## Шагыйрь Габдулла Тукайга

Әй Тукай, сөекле шагыйрь, безне бик тиз ташладың,
Бер кеше гомеренең әл дә яртысын да ашмадың.
Шуңа күрә яшь вакыттан зур булырга башладың,
Кыска гомереңдә безгә күп изгелек багышладың.

Шул гомереңә гел изгелек сыйдырырга тырыштың,
Яхшы ният белән көлдең, сөя-сөя орыштың.
Милли көрәшләр эченә кулда каләм керештең,
Зур батырлыкларың белән мәңгелеккә ирештең.

Без аз, алар күп димәдең, күпкә каршы көрәштең,
Һәр кара көч белән чыгып, батырларча тырыштың.
Милләтнең иң иске хисләрене сызып серләштең, –
Шуңа күрә бөтен милләт йөрәгеңдә җирләштең.

Син үлсәң дә, без яшәтәбез сине, син кирәксең,
Чөнки син безгә һәрвакыт иң көчле бер терәксең.
Милли хисләрең белән син безнең өчен йөрәксең,
Бөтен Татар милләтенә Тәңредән бер бүләксең.

Истанбул, 17.04.1948

## Соклану

Керфекләрең күләгә салган нур чишмәсе күзең,
Җефәк чәчәк чәчкәйләрең бер үбәм дип үрелә.
Ак күнемнең шатлык биргән өметләре күземә,
Шул матур елтыр күзеңнең тирәнендә күренә.
    Матур гына бер елмаеп, карап куйсаң үземә,
    Өстемә нур тулкыннары шундук килеп түгелә.
    Өстем-башым, эчем-тышым  бөтен нурга төренә.
    Шул вакыт торган йирләрең охшый оҗмах түренә.
Әй чибәр гөл, сөйкемлекәй, инан минем сүземә!
Син бар йирдә әле хури (хур кызы. – **Х.М.**) да күренмәс күземә.
Бөтен дөнья матурлары җыелып килсә үземә,
Кояштыр! Әйләнеп бакмамын һичберсенең йөзенә!
    Аһ, матур гөлсең, сылукай, ниләр булды үземә?
    Өндә, төштә, өйдә, тышта күренәсең гел күземә.
    Сине уйлап, хыялланып, ач үзәгем өзелә!
    Әйтче, зинһар, өметләнү ярыймы соң үзеңә?

Истанбул, 27.05.1918

*Шигырьләрне басмага филология фәннәре докторы, профессор*
***Хатыйп Миңнегулов*** *әзерләде.* ■

# Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә

Габдерәхим Утыз-Имәни

## Сыйфате җәһәннәм

Җәһәннәм васфидин бераз дәваһи,
Бәян әйләй, ишет, әй, мәрде гами.
Чыкар андин зөбанилар би-тәһдид,
Сорарлар гасыйларны сәувык тәшдид.
Монадилар чыкубән нәгъра әйләр,
Фәлән ибне фәлән дип сәхте сөйләр.
Мокамигълар билән катигъ сорарлар,
Җәһәннәм кагрига илтеп салурлар.
Укур «Зукъ иннәкә әнтә әл-газизени»,
Вирүрләр ширбәти маи хәмимени.
Улур агзындаги тешләр Ухуд дик,
Тире йуганлыгы өч көнчә йулдик.
Би-әнвагъ нәкаль тәгъзиб итәрләр,
Хәлас эстәб мөнаҗәтләр әйтерләр.
Җавап килгәй сезә һәйһат вә һәйһат,
Хоруҗ йукдур, иман йук сөммә һәйһат.
Ишеткән соң бони мәюс улурлар,
Кыйлан эшләригә надим улурлар.
Нәдамәтлә тәәссеф нәфигъ вирмәз,
Җавабыңа бакарса шәфкать ирмәз.
Җәһәннәмнең гакабы васфи бетмәз,
Тәмам әйтәй дисәм, ахырга йитмәз.
Вәләкин һәр кешени тотса ул нар,
Кыйлан әгмальләридүр канча микъдар.

Зийадә кем улумаз имди ул эш,
Кемигә рәхәт ирүр, кемгә тәшвиш.
Гаҗәпдүр сәндин әкнүн ләһү вә ләгъбең,
Беләлмазсән кайу халәтдә булганың.
Казаи сәбкать итүбдүр кайсы хальга,
Тәфәккер салмайурсән бу маәлга.

---

Ахыры. Башы журналның 5 нче (2021) санында.

Беләй дирсәң казаның сәбкатыни,
Тәфаттикъ ит хәятың хаслатени.
Мөяссәр улса сәңа хәйр вә тагать,
Бәшарәтдүр сәңа килгәй сәгадәт.
Әгәр улса мөяссәр фисык вә гыйсйан,
Ишарәтдүр маәлең улды хирман.
Тәфәккер әйләсәң бу хәсби халең,
Белүрсән кем нәчүк улгай мәалең.

*Тәрҗемәсе:*

## Җәһәннәм сыйфаты

Җәһәннәм сыйфатыннан бераз куркыбрак
Бәян итәм сиңа, ишет, и белдексез.
Чыгар аннан сатлык җаннар курку белән,
Сорарлар гөнаһлылардан мәҗбүрилекнең көчен.
Хәбәрләрне белдерүчеләр, чыгу белән акырып,
Фәлән углы фәлән дип каты әйтерләр,
Дәрәҗәләренә карап каты сорарлар,
Җәһәннәм чокырына илтеп салырлар.
Укыр: «Бу газапны таты! Дөреслектә, син изгеләрдән».
Бирерләр кайнар суның ширбәтен.
Авызындагы тешләр булыр Өхед (тавы) кебек,
Тире юанлыгы өч көнлек юл кебек.
Женесләренә карамыйча җәза бирерләр,
Котылу теләп, мөнәҗәтләр әйтерләр.
Җавап килер: «Сезгә кайгы да кайгы!..
Чыкмак юктыр, иминлек юк, тагы кайгы!»
Ишеткәннән соң моны, өметләре өзелер,
Кылган эшләренә үкенерләр.
Үкенү белән кайгыга файда булмас,
Җавабын караса, рәхимлек килмәс.
Җәһәннәмнең газабын тасвирлап бетерерлек түгел,
Барысын да әйтим, дисәм, ахырына җитмәссең.
Әмма әгәр кеше төшсә ул утка,
Кылган гамәлләре никадәр – шулкадәр янар.

Беркемнән дә читтә калмас инде бу эш (бу тәртип):
Кемгә нигъмәт бирелер, кем куркуга төшәр.
Гаҗәптер сиңа бүген күңел ачу, уен-көлке:
Белә алмассың нинди хәләттә булганыңны.
Каза кылып узасың кайсыбер хәлгә,
Фикереңсалмыйча ахыргы язмышыңа.
Беләм дисәң казага калдыруның өстенлеген,
Аңлатып бир тормышыңның үзенчәлеген.
Җиңел булса сиңа изгелек һәм Аллаһка гыйбадәт кылу,
Шатлыклы хәбәр – сиңа килер бәхет.

Әгәр җиңел булса сиңа бозыклык һәм җинаятьчелек,
Билгеседер бу ахырда булачак бәхетсезлек(нең).
Фикерләп карасаң бу ирешелгән хәлеңне,
Белерсең үзең – ничек булыр ахыргы язмышың.

## Сыйфаты җәннәт вә әүсаф нигъмәһа

Җәһәннәм васыфидин белдең бераз халь,
Биһишт әүсафига әйзан колак сал.
Аның тәүсыйфыни күреп һәрас ит,
Биһишт әүсафига бакып һәвәс ит.
Биһишт әһле тәнәгъгымда дәмадәм,
Улумаз анда һәргиз хәсрәт вә гамь.
Мөнабирләр кызыл якутдин улмыш,
Ки ак энҗү хәййамлардин дәкелмеш.
Босутлар сапфиридин чук дүшалмыш,
Араиклар ләб әнһарда тулмыш.
Җәваниблар тулу гыйльман вә вилдан,
Мөзәййән хурлари якут вә мәрҗан.
Мөрәссәгъ башларида таҗ дөрран,
Могаттар хуш нәма гаять мөзәййан.
Абариклар могаййандин дәүр итәрләр,
Эчеп-йийеп шатлыкдан зәүкъ итәрләр.

Мөнәззәһләр мәшәкъкать хөзн-ү-гамьдин,
Бәдәнләрдә кәсәл йук бер әлемдин.
Мосаффи ак көмешдик саф тәнләр,
Тәләззездә улур тагать идәнләр.
Тәбагыйзь би-тәхасод содк-у-киндин,
Мөнәззәһдүр тәмами холкы бәддин.
Ки сиксән мең улур хадимлар анда,
Улур хазир тәмамының уңында.
Бу нигъмәтнең зәвалидин иминләр
Моәббәд ула әсхабе йийинләр.
Егетләрдүр карыйлык килмәисәр,
Сахибы җавидан дәүре улмәисәр.
Утыз өч яшендә ула җөмлә адәм,
Буе алтмыш зәрагдин улды әтмам.
Кәлямендә укый аяте рахман,
Биһишт әһле сыйфатын дир мөгаййән...

***

Биһиштнең һаәте дөрлү гөлгун,
Либенләре көмешдер, бәлки, алтун.
Зәгъферандин тәраби мөшек тыйни,
Сәмәрләри тәнәввогъ улды ләүни.
Арыклари акар мишек колләсидин,

Киярләр хуш ләтаиф хөлләсидин.
Дәхи разразлари якут-зөбәрҗәт,
Вә гәр нигъмәтләрин кем әйләйүр гад.
Дәрәхтеләр сайәси вар шөйлә васигъ,
Кидәр ракиб кеше сад салда саригъ.
Осуле ул дәрәхтенең энҗү-алтын,
Сәмәри һәрбери улмыш дигәр кәүн.

*Тәрҗемәсе:*

## Җәннәтнең һәм аның нигъмәтләренең сыйфатлары

Җәһәннәм сыйфатыннан бераз хәлен белдең,
Инде җәннәт сыйфатларына колак сал.
Җәһәннәм сыйфатларын күреп, борчылып алдың,
Җәннәт сыйфатларына карап, күңелеңне күтәр.
Җәннәт кешесе туктаусыз нигъмәт эчендә яши,
Аңарда булмас һичбер вакыт хәсрәт һәм борчылу.
Дингә өндәүчеләр кызыл якуттан киенгән,
Һәм дә ак энҗе чатырлары төзелгән.
Келәмнәре гел атластан түшәлгән,
Тәхетләре елга ярына урнашкан.
Як-яклары тулган җәннәт хезмәтчеләре белән,
Хур кызлары якут, мәрҗән белән бизәнгән,
Башлары энҗеле таҗ белән бизәлгән,
Хуш ислеләр, сөйкемлеләр, бизәнгәннәр,
Матур чүлмәкләр белән түгәрәк ясап әйләнерләр,
Ашап-эчеп, шатланып ләззәтләнерләр...

Гөнаһсызлар түземле кайгы-хәсрәт һәм сагышка,
Гәүдәләрендә булмас бер алҗау, авыру.
Сафланган ак көмеш кебек саф тәннәре,
Ләззәтләнеп яшәрләр гыйбадәт кылучылар.
Үзара дошманлык, көнләшү, ачу тоту, яшертен дошманлыктан –
Гөнаһсыздыр барысы да бу явыз холыктан.
Һәм сиксән мең булыр хезмәтчеләре анда,
Барысы да хәзер булып торыр уң ягында.
Бу нигъмәтнең югалмавы ышанычлы,
Мәңгелек була ул аның ияләренә.
Егетләргә картлык килми монда,
Мәңгелек ияләре алар, беркайчан үлмәячәк.
Утыз өч яшендә була барлык кешеләр,
Буе алтмыш зәрагтан (аршыннан?) булыр тәмам.
Сөйләмендә укыр ул аятен Аллаһның,
Җәннәт иясе сыйфатын ачык күрсәтер.

***

Җәннәтнең дивары  төрле төстә,
Кәрнизләре көмештер яки алтын.
Зәгъфераннан туфрагы, хуш исле туфрак,
Җимешләре төрле төсләрдә булыр.
Арыклары агар муксус тау түбәсеннән;
Киярләр хуш йомшак өс киемнәре.
Түшәлгән ташлары да якут-зөбәрҗәт,
Башка нигъмәтләрен кем санаган аның.
Агачлар күләгәсе булыр шундый киң, –
Атлы кеше барыр (аның буенча) йөз ел ашыгып.
Тамыры ул агачның – энҗе-алтыннан,
Җимешләре һәрберсе булыр төрле төстә.

## Сыйфат җәннәте тәгами

Тәгамлари тойур вә һәннү сәлви,
Сәмәрү һәм ләбән сыйнфа ля хәйси.
Шәраблари ула анда Сәлсәбилдин,
Кәлүр гяһ каәслар пор гәсәлдин.
Беригә вирелүр куәте йөз ир дәк,
Теләрсә гәр ушанда йимәк-эчмәк.
Җимагъ итмәк теләрсә, анча куәт,
Табарлар һәм йөз ирдәк тәндә форсат.
Әгәрчә итгами чәндан йийәрсә,
Тәгаввотдин күренмәс һичнәрсә.
Чыкар тәнләридин тәгърыйк хушбу,
Калур хали мотаһһәр батыйн мохәллү.
Теләрсә йийгали моргы пәрәндә,
Төшәр бөрйан улуп саф уңләрендә.
Мәшәккатьсез кәлүр алга сәмәри,
Йитәр торган йиридин суынсали.

*Тәрҗемәсе:*

## Җәннәт азыкларының сыйфаты

Азыклары: кош ите һәм җиңел бүдәнә кошыныкы,
Җимеш һәм сөт – ачымый торганнар.
Шәрабләре оҗмахтагы Сәлсәбил чишмәсеннән,
Килер ул бал тулы савытларда.
Бер кешегә бирелер йөз ирнең куәте,
Әгәр теләсә анда ашап-эчәргә.
Якынлык кылырга теләсә, шуның кадәр куәт,
Йөз ирдәге мөмкинлек-көчне табар.
Ризыкларны никадәр күп ашаса да,
Тәрәтендә күренмәс һичнәрсә.
Чыгар тәннәреннән бары хуш исләр,

Калыр бары чиста, бизәлгән гәүдә генә.
Ашарга теләсә очкан кош итен,
Пешеп төшәр ул чиста тәлинкәләргә.
Мәшәкатьсез килер алга җимешләр
Өлгерә торган җиреннән – еллар буе.

## Сыйфаты ли-хур әл-гайне вәл-вилдан

Укулды мосхаф эчрә васыфы вилдан,
Бәян улди дәхи хур вә гыйльман.
Аларның васыфыдур якут вә мәрҗән;
Мотаһһәрдур күрүмәз хәйз илә кан.
Улумаз гайт вә бул вә бозакдин,
Борын сеңгермәк вә хәмлә вәләддин.
Вәкагъдин соң тәмам әбкар улурлар;
Бер иргә хуридин биш йөз вирүрләр.
Риваятьдә кәлебдүр җәннәт әһеле,
Вәләд дугсун дийү мәйл итсә күңле,
Дугар фил-халь, улур камил шәбаби,
Улур бер сәгатьтә хәмлә вә фәсали.
Бу нигъмәтләр өчен, әй мәрде пакьдин,
Тойурма карныңи нан вә гамәкдин.
Бу дөнья тәркидүр мөһре Кыямәт,
Таләб кыйлгай кеше булмаз сәгадәт.

*Тәрҗемәсе:*

## Хур кызларын һәм җәннәт хезмәтчеләрен сыйфатлау

Укылды Коръән эчендә җәннәт хезмәтчеләренең сыйфатлары,
Бәян ителде монда да хур һәм җәннәт хезмәтчеләре хакында.
Хур кызларының сыйфаты – якут һәм мәрҗән;
Чисталардыр, күрем вакытында күренмәс кан.
Булмас тизәге, бәвеле һәм төкереге,
Борын сеңгерүе һәм балага – йөккә узуы.
Андый хәлдән соң озак кына юынырлар;
Бер иргә биш йөз хур кызы бирерләр.
Риваятьтә килде: әгәр җәннәт иясе(нең)
Бала тусын, дип бик теләсә күңеле,
Туар ул бик тиз, камил булыр яшь бала.
Булыр бер сәгатьтә йөккә узу һәм бала тудыру,
Бу нигъмәтләр өчен, и саф дин кешесе,
Тутырма карыныңны икмәк һәм тоз белән.
Бу дөньяны ташлау – Кыямәтнең билгесе,
Дөньяны эстәгән кеше бәхетле булмас.

*Текстны журналга филология фәннәре докторы*
***Әнвәр Шәрипов** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# Тәңре юлында

**Тәлгат Галиуллин**

*(Әхәт Гаффарның шул исемдәге повесть һәм хикәяләр җыентыгының кулъязмасы турында)*

Ә.Гаффар – соңгы елларда драматургия, проза һәм публицистика жанрларында гаять актив эшләгән урта буын вәкиле. Язучының әсәрләренә көтелмәгән борылышлар, вакыйга һәм хәлләр яңалыгы, үзенә бер хәрәкәт, интеллектуальлеккә омтылыш хас. Тәнкыйть күбрәк аның теленә «бәйләнде» (катлаулы, чуар, ахыргача эшләнеп бетмәгән җөмләләр, рустан калькалар һ.б.). Телне баетып, шомартып-бизәп булса да, аның ана сөтеннән килә торган байлык икәнлеген онытырга ярамый. Төрткәләүләрнең файдасы тимәде дип булмый, Ә.Гаффар телгә, өслүбкә зуррак игътибар бирә башлады, бу хәл әлеге кулъязмада да күренә. Тәнкыйть кирәкле шәйдер, күрәсең, Тукаебыз белмичә әйтмәгәндер.

Кулъязма «Бишек» һәм «Тәңре юлында» исемле ике повестьтан һәм хикәяләрдән тора. Хикәяләрнең байтагы укучыга таныш. Шуңа сүзне повестьлардан башлыйк.

«Тәңре юлында» – әфган темасын үзәккә алган повесть. Кайбер тәҗрибәләр булса да (бигрәк тә драматургиядә), безнең әдәбият өчен тема тулаем яңа. Һәм әйтергә кирәк, Ә.Гаффар шактый кызыклы сюжет сызыгы тапкан. Бер яктан, ирсез калган, берәүгә дә кирәксез сугышта газиз улын югалткан Кадрия язмышы, икенче яктан, Әфганстанда сугыш вакыйгалары тәгәлләнү, совет солдатларының чит илне чакырылмаган кунаклар булып ташлап китүләре һәм шуңа бәйле хәлләр. Хатынның ире һәм улы турында уйланулары, физик һәм рухи ялгызлыгы, кемнедер юксынуы-сагынуы психологик нечкәлек белән бирелгән. Авторның әлеге сугышка бәясе усал, кырыс, заманча. Тематик яңалык бәхәс уятмый. Шул ук вакытта повестьны авыр укыла торган өзекләрдән, сюжет үсешенә берни бирмәстәй диалоглардан коткарырга кирәк дип уйлыйм. Аннан соң Кадриянең Казаннан ялга килгән иргә барып «ябышуы» да, әлеге чикләвекченең Әфганстанда һәлак булган улының командиры булып чыгуы да уйдырмарак яңгырый. Уйланасы бар, шартлылык та ышандырырга тиеш. Повесть исеменең («Тәңре юлында») мәгънәсе артык тирәндер, күрәсең, асылына төшенүе кыен. Ул Әфган җиренә сугыш алып килгән безнең армиягә карыймы (без бит басып керүне күп еллар буена изге бурычны үтәү дип күрсәтеп, халыкны алдарга тырыштык), әллә шунда газиз башларын салган солдатларны олылаумы, яки башкачамы? Сорауларның тууы табигый, әмма әсәр тукымасында аңа җавап та табылырга тиеш дип уйлыйм.

Бу яктан икенче, дөресрәге, кулъязманы ачып җибәргән «Бишек» повестеның исеме җисеменә күбрәк туры килә. Ул туган якны да, һәркемнең балачак бишеген дә символлаштыра.

«Бишек» авторның иң соңгы әсәрләреннән берсе булса кирәк. Шактый кызыклы, катлаулы структуралы, психологик күзәтүләргә, диалогларга бай. Дөрес, анда бәхәс уята торган өлешләр дә җитәрлек. Мәсәлән, ул бик күптәнге хәлләрне искә алу, эрудицияне күрсәтеп алу рухы белән башланып китә. Ә.Гаффар, тулаем алганда, бик динамик язучы булса да, урыны-урыны белән озын, тасвирлы сөйләм юлына төшә. Шактый баналь урыннар җитәрлек. Аларын сипләве кыен булмастыр.

Әмма төп мотив – Аитның, спортчы-штангачының тиктомалга авылга, ташландык йортка кайтып төшүе, шунда урнашып калырга карар кылуы ышандырмый. Бу – психологик яктан аклап, раслап бетерелмәгән сәер алым. Автор бик олы мотивлар эзли-эзли дә, фәлсәфәсен,

үзе дә сизмәстән, бик гади бер гамәли хәлгә кайтарып калдыра: егет авыру хатынын ташлап качкан икән ләбаса! Катлаулы итеп төзелгән сюжет (элекке мәхәббәтен – артистка Сөмбелне очратуы, антик дөньядагы шикелле тану-танымау мотивы) кинәт кенә чишелә дә куя: хатыны үлгән дигән телеграмма килә, герой алдында яңа перспектива ачыла – кем әйтмешли, сарыклар да исән, бүре дә тук.

Хикәя – иң катлаулы, авыр өлкәләрнең берсе. Ә.Гаффар бу жанрны үстерүгә шактый өлеш кертеп килә. Кульъязмада тәкъдим ителгән «Акчураның җир үбүе», «Чакма ташы» һәм «Яңа көн» хикәяләренә тормышны үзенчә сурәтли белү, чынбарлыкны образлы күрү хас. «1945 елгы хат» та ышандыра.

«Әҗәт» хикәясе татар карчыгының эчке дөньясын, ышануын, изгелеген, сафлыгын, төрле буыннар арасындагы җанлы җепләрне, тормыш фаҗигасын табигый ачуы белән кульъязмада миңа иң ошаган әсәр булды. Ә.Еникинең атаклы «Әйтелмәгән васыять» хикәясе белән янәшә торырлык әсәр.

Хәзер автор колагына әйтеләсе берише теләкләргә күчик.

«Түгәрәк алан маҗаралары» әкияте, «Рубик шакмагы яки Көтүче генералы» хикәяләрен балалар өчен чыгарылачак китапка тәкъдим итү кулайрак булыр. Хәер, беренчесе – артык абстракт, тоташ символикага корылган әсәр. Минемчә, ул сюжетны автор элегрәк драма әсәрендә кулланган иде инде.

«Ау» хикәясенең нигез өлгесе итеп алынган вакыйга артык ясалма тоела. Аңа драматизм, ышандыру көче җитми.

«Эт» әсәре үзәккә тормышта гел очрап торган һәм әдәбиятта төрле ситуацияләрдә инде күп тапкырлар яктыртылган вакыйганы эченә ала. Яшь эт үзен аңламаган хуҗасын тешли, соңгысы аны атарга алып чыгып, шуңа көче җитмичә, ташлап кайтып китә. Хикәянең реаль нигезе бар. Әмма ике нәрсә ризасызлык хисе уята. Берсе – ике көпшәле, яхшы мылтыклы кешенең шыр наданлыгы (өч айлык этнең әле өлгереп җитмәгәнлеген һәркем аңлый булыр), икенчесе – шәфкатьсез адәмнең этен атмыйча кайтып китүе психологик акланып җитми, эшләнеп бетмәгән дигән тойгы калдыра.

«Гөмбә»не хикәя дип атау дөрес булмас. Аның нигезендә берничә новеллалык, берсе өстенә берсе өелгән төрле типтагы вакыйгалар ята.

Сөйләүченең гөмбәгә баруы, гомерендә беренче тапкыр ялангач хатын күрүен искә төшереп ләззәтләнүе, табигатьнең илаһи бер күренешенә тап булуы. Һәм шунда ук «Акчураның җир үбүе» хикәясенә этәргеч биргән балага уза алмый интеккән хатын фаҗигасы. Боларны бер күчкә өю хикәяне төрле-төрле сөйләкләргә бүлгәләгән. Авыр укыла торган ярым мемуар, ярым публицистик бернәрсә килеп чыккан.

«Янгын» хикәясендә озын диалоглар күп (драматургия белән мавыгуыннан килгән бу нәрсә аның бериш әсәрләренә хас), әмма мәгънәле, җор бетем табылган.

«Күпер»нең башы артык тасвирлы, сюжеты бераз китапчарак булса да, анда коеп куелган характер бар. Булачак китапның кәефен бозмас дип уйлыйм.

«Үрдәк көне» чынында ике мөстәкыйль сюжеттан, ике кисәктән тора. Аларны кушу, якынайту турында авторга уйлап карарга кирәктер.

«Бер йотым су»ның мәгънәсе дә бар, авторның нияте дә изге: вакытын кая куярга белмичә, китапханәдәге бар китапны укып, язу-сызу эшенә керешкән пожарникны хатыны ярдәмендә фаш итү ята нигезендә. Кызганыч ки, артыгын кыланулар, озын сөйләмнәр әсәрнең кыйммәтен төшерә.

Тулаем алганда, кульъязма дөнья күрер дип ышанам. Әмма андагы әсәрләрне җиз иләк аша үткәреп, тагын бер эшләп чыгарга кирәк дигән иманда калам.

*1990 ел, июль* ■

ШИГЪРИ МИРАС

# Мамадыш шагыйре

*Сәяф Шәйхи (Сәяф Гарафетдин улы Шәйхиев) 1941 елның 1 сентябрендә Татарстанның Мамадыш районындагы Урта Сон авылында туган. Шигырьләрен мәктәптә укыганда ук яза башлый. Күпсанлы шигырьләре, хикәяләре төрле район һәм республика газета-журналларында, аерым җыентыкларда дөнья күрде.*

*С.Шәйхи 2012 елның октябрендә вафат булды.*

**Сәяф Шәйхи**

# Сәяф Шәйхи

## Татар җаны

Чит-ят тарафларда
Татар җаны яши.
Көннәр, еллар үтә тезелеп...
Туган җирләрендә,
Басу буйларында
Каеннары көтә өзелеп.
Авыл башларыннан
Ындыр артларыннан,
Карашларын төбәп юлларга...
Бер кайтырлар әле,
Күренерләр, диеп,
Өметләнеп килер елларга.
Буразналар көтә,
Алсу таңнар көтә,
Болын чәчәкләре көтәләр;
Изге туган якның
Тальян моңнары да
Сезне көтеп гомер итәләр.
Татар җаны нигә
Таралдың соң болай,
Ник калдырдың туган төбәкне?..
Күпме еллар инде,
Җавап өмет итеп,
Шушы сорау борчый йөрәкне.

## Туган телем

Каләмемнән саркып
Ак кәгазьгә күчә
Йөрәгемнән чыккан моңнарым...
Туган телем аша
Сезгә ирештерәм,
Үз телемдә яңгырый җырларым.
Туган телем минем,
Кабатланмас телем,
Тукай белән үтте юлларда,
Гаделсезлек кысты.
Телем кысрыкланды
Җаннарга шом иңгән елларда.
Ләкин бирешмәде
Газиз телем минем,
Горурлыгын саклап калалды,
Сүнеп барган тарих
Күге офыгында
Алсу шәфәкъ булып яналды.
Туган телем минем,
«Тәфтиләү»ле телем,
Кошлар моңыннан да моңлырак,
Үткәннәргә карап,
Бүгенгедә яшим,
Үткәнебез булган җырлырак.
Үткәннәргә карыйм
Еллар арасыннан,
Мәңгелек җил сыйпый иңемнән,
Вакыт чыңлап тора,
Хатирәләр кайта
Тарих төбе, Болгар илемнән. ■

# Тугры Шәйхи шигырьләре

*Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров) 1905 елның 15 гыйнварында элекке Казан губернасы Мамадыш өязе (хәзер Татарстанның Мамадыш районы) Тулбай авылында туган.*

*Ул 1980 елның 10 июнендә Казанда вафат булды һәм үзенең язма васыяте буенча туган авылы Тулбай авылы зиратына җирләнде.*

**Маннуровлар гаиләсе**

## Көтә халык

*(Казанда Тукай һәйкәле ачылган көнне)*

Казан уртасында һәйкәл тора,
Тирәләре гөлгә күмелгән.
Һәркем аңа табан башын бора
Һәм сәламли ихлас күңелдән.
Исәнме! – дип,
Мин дә дәшәм аңа,
Ишетәм тагын меңнәр әйткәнне.
Һәм кысардай булам кочагыма
Күптән көткән шушы һәйкәлне.
Аксакаллар,
Чал әбиләр булсын –
Бар да килгән аны күрергә:
Юк,
Онытмый халык үз җырчысын,
Сөеп саклый күңел түрендә.
Казан уртасында һәйкәл тора,
Саф чәчәкләр анда көн саен.
Горурланып һәркем башын бора
Һәм сәламли бөек Тукаен!
Инде көтә халык,
Әйтә халык

Күңелендәге изге уйларны:
Мулланұры белән Ямашына
Һәм Сәйдәше белән Такташына
Мәйданнарда һәйкәл булганны!

*1958*

## Балан чәчәк ата

Тын гына бер җәйге кич иде ул,
Урталары булыр июньнең.
Агыйделдән иде без барган юл,
Чикләрендә башкорт җиренең.

Тар бормага килеп керде «Тукай»,
«Аккош муйны» дигән җир икән.
Бер тугайны узсаң,
Тагын тугай, –
Әйлән дә гел шунда йөр икән!

Менә кинәт ак кар өртмәләрдә
Яңа тугай безгә күренде.
Һәм пароход өсте көтмәгәндә
Нечкә хуш ис белән күмелде.

Йөгерәбез палубалар буйлап:
– Нинди татлы!
– Нинди үткен ис!
– Исерергә була моны сулап!
– Яшәрергә хәтта мөмкин ич!

Кызын җитәкләгән егет чаба.
Күзе эзли.
Үзе абына:
Могҗизаны гүя хәзер таба!
Һәм китерә сөйгән ярына.

Үрелә ул ярга палубадан,
Маңгаена төшә чәчләре.
Һәм кызына дәшә:
– Балан! Балан!
Аңкый икән балан чәчәге!..

Әллә кайчан узган хәсрәтләрем,
Ник борчыйсыз мине сез һаман?
Мин дә сиңа балан чәчәкләрен
Өзеп биргән идем бер заман.

Саф хисләрем билгесе бу... – диеп
Мыдырдадым авыз эчемнән...
Кабатлана чәчәк
Һәр яз килеп.
Ә син кайда?..
Ник югалдың күңел күземнән?..

Тын гына бер җәйге кичтә шулай
Агыйделдән бара идек без,
Тугай саен сайрый яңа тургай,
Шул моңнарга тала идек без...

Кинәт безнең палубалар өсте
Балан исе белән күмелде.
Һәм яшь егет, сәрхуш булган төсле,
Ялкынланып ярга үрелде.

Өз син, егет, минем өчен дә өз
Аңкып торган балан чәчәген.
Ак күбәләк итеп чәчен тез,
Матурла син Ләйләң чәчләрен...

Сезне күргәч, мин сокланып китәм:
Яшьлегемә кайткан күк булам.
Ләкин...
Ул йозаклы бакча икән,
Керәлмичә тышта тик торам...

Ә баланнар шаулап чәчәк аткан,
Нинди хуш ис, нинди үткен ис!
Юлдашларым әйтә төрле яктан:
«Яшәрергә хәтта мөмкин ич!»

*1960* ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# Мамадышның мәшһүр рәисләре

**Ринат Хәйруллин***

**Мамадышның атаклы рәисе Хәлим Сәлахов**

*Мамадыш районының зур, күркәм авылы Түбән Ушма белән борынгы тарихлы Урта Кирмән авыллары арасында элек-электән бәйләнеш булган. Беренчесе – уртасыннан ук «Әби патша» юлы узуы белән «аграк», икенчесе, олы юллардан читтә булуы сәбәпле, «караңгырак» саналса да, ике авыл арасында элемтә беркайчан да өзелмәде. Килен төшерү, кода-кодагыйлык элемтәләре аша Түбән Ушма белән Урта Кирмән халкы арасында рухи күпер салынды. Колхозлар илнең төп таянычы булган чорда әлеге күпер матди эшләр белән дә ныгыды. Чөнки Урта Кирмәндә оешкан Киров исемендәге күмәк хуҗалык белән төрле елларда Түбән Ушманың гаярь егетләре Вагиз Гарифуллин һәм Хәлим Сәлаховлар җитәкчелек итте. Әлеге язмам алар турында.*

## Вагиз Гарифуллин: «Биштәр белән ташымасыннар, йөк машинасы җибәрәм»

Сугыш колхозларны нык талый. Бу елларда «ир заты» дип куелган колхоз рәисләре арасында тол хатын-кызлар артыннан чабучылары да булды, кайберләренең «яшел елан»ны үз итүләре дә сер түгел. Үзәге Урта Кирмән

---

*** Ринат Хәйруллин** – Мамадыш районындагы Урта Кирмән урта гомумбелем бирү мәктәбенең тарих укытучысы.

булып, Арташ, Алан һәм Калатау авылларын үз эченә алган Киров исемендәге колхоз да моңа искәрмә булмый. 1960 нчы еллар башында районда иң артта сөйрәлүче хуҗалык санала ул. Эшләп тапканы колхозчыларга түләргә җитми, терлекләрне ашатырга азык юк. Шундый түбән күрсәткечләре белән «дан казанган» колхозга 1966 елда рәис итеп Вагиз Гарифуллин билгеләнә. Карап торышка кырыс булып күренгән олы гәүдәле бу кеше колхозчыларда ышаныч тудырып, алар күңеленә юлны тиз таба. Урта һәм яшь буын белгечләр белән дә тиз аңлаша: «Мактауны өмет итмәгез, аңа күнегәсе түгел, ә менә тәнкыйтькә өйрәнергә туры килер», – ди ул. Шуның белән үзенең бу авылга узгынчы булып түгел, ә җиң сызганып эшләргә килгәнлеген белдерә. Үзе бик кешелекле, ярдәмчел булып чыга. Ул вакытта эштән кайтучы хатын-кызларның биштәргә печән-салам тутырып кайтулары бик популяр була. Өлкән буын әле дә хәтерли: кайбер рәисләр арттан килеп биштәр бауларын кискән яки ут төрткән очраклар да була. Ә Вагиз бу күренешләргә күз йома, хәтта бервакыт, биштәр белән кайтучы хатыннарны узып китеп, алар каршына, төяп кайтырга дип, йөк машинасы җибәрә.

Вагиз Гарифуллинның Урта Кирмәнгә эшкә килү вакыты ТАССРда авыл хуҗалыгын интенсификацияләү елларына туры килә. Ул колхозның җитештерү куәтен үстерү өчен күп нәрсә эшли. Рәис, авылда механикалаштырылган төзелеш бригадасы оештырып, киң масштаблы төзелеш эшләре башлап җибәрә. Заманча итеп салынган фермаларда яшь малларга азык пешерү өчен пар казаннары куелу зур яңалык була, нәтиҗәдә, терлекчелек табышка эшли башлый, бозауларның үлеме кими. Терлекчеләрне, ат арбаларына утыртып, ул вакытта алдынгылардан булган «Кызыл флаг» һәм «Спартак» колхозларына алып бара, башкаларның тәҗрибәсен өйрәтә. Игенчелектә дә механикалаштыру көчәя: кырларда куәтле тракторлар һәм комбайннар пәйда була, химияләштерү, җирләрне ясалма сугару оештырыла. 1930 нчы еллардан калган икмәк амбарлары урынына өр-яңа, иркен складлары булган амбарлар төзелә, көчле ташуда су баскан машина-трактор паркы да яңа урынга күчерелә.

1971 елга кадәр генә эшләсә дә, терлекчелек биналары белән беррәттән, социаль объектлар төзетү белән дә шөгыльләнә рәис. Мәктәп директоры Әлфәт Рәфыйков белән киңәшеп, заманча гыйлем йорты салу эшен башлап җибәрә. Эшне Вагиз Гарифуллин оештырган төзүчеләр бригадасы башкара. Кече Кирмән, Түбән Яке, Югары Яке, Уразбахты, Арташ, Алан һәм Норма балалары өчен бик кирәкле мәктәп була ул.

## Хәлим Сәлахов: «Төзелешкә – миллионнар»

24 яшьлек югары белемле белгечне 1976 елның көзендә район авыл хуҗалыгы идарәсенә баш агроном итеп билгелиләр. Бу хезмәтендә 9 елга якын эшләү чорында аңа 1977, 1980 һәм 1981 елгы корылыкларны, 1978 елгы көзге яңгырлар сәбәпле, урып-җыюны һәм терлек азыгы әзерләүне төгәлли алмауны да, шул ук кышның 50 градус салкыннары нәтиҗәсендә, барлык төр җитештерүнең бер мизгелдә түбән тәгәрәвен дә күрергә туры килә.

ТРның атказанган авыл хуҗлыгы хезмәткәре, Мамадыш шәһәренең почетлы гражданины, инде 70 нче көзенә якынлашучы Хәлим Шиһабетдин улының сөйләр сүзләре күп. 1985 елның март аенда Киров исемендәге хуҗалыкка рәис итеп билгеләнә ул. Яңа җитәкчегә ел уңай килми: җәй бик коры бу-

лып, көзе тоташ яңгырлар... Шул сәбәпле терлек азыгы әзерләү дә, шәхси хуҗалыкларны печән һәм икмәк белән тәэмин итү дә мактанырлык булмый. Халык төшенкелеккә бирелә, ярым-йорты гына ашатылган терлекләрнең продуктлылыгы түбән тәгәри.

Иң күзгә ташланганы – юлсызлык: авыллар арасында да, урамнарда да көзге-язгы вакытта гына түгел, җәйге яңгырларда да йөрерлек түгел. Салынып бетеп тә ачылмаган клуб халыкны кабул итә алмый. Күңел ачу чаралары мәчетне үзгәртеп корылган бинада уза. Электр белән тәэмин ителеш тә начар хәлдә була. 60 нчы елларда уздырылган линияләр бик тузган, әзрәк җил исүгә, авыл караңгылыкка чума. Ике авылда да балалар бакчасы юк.

Сүзне Хәлим аганың үзенә бирик:

«...Эшне бригада җыелышларында терлекчеләр һәм игенчеләр белән очрашулардан башлап җибәрдем, – дип искә ала ул. – Башта бераз шүрләтте. Районның күпчелек хуҗалыкларында ике катлы мәдәният йортлары, балалар бакчалары гөрләп эшләп торганда, таш түшәлгән юллары булганда, ни өчен бу хуҗалык шул хәлдә калган? Моңа бит һәркөнне үзен хезмәткә багышлаган халык гаепле түгел. Эшләп-эшләп тә тормыш-көнкүреше көйләнмәгән колхозчыдан ничек эш сорыйсың? Бу мәсьәләләр бик уйландырды, моның ниндидер чишелешен табарга кирәк иде. Уйлана-эзләнә торгач, әлеге чишелеш табылды. Хуҗалык белгечләрен алмашу булмады, аларның фикерләрен тыңлау, дәрәҗәләрен күтәрү бик файда китерде. Халык уянды, хезмәткә караш үзгәрде. Булган терлек азыгын экономияле тотып, амбар төпләрен кырып-себереп булса да язга чыктык. Терлекчелектә хуҗалык исәбендә эшләүче звенолар төзеп эшләү, һәрдаим халык арасында булу беренче елда ук уңай нәтиҗә бирде. Ул елда терлек азыгы, фураж җитми, дигән сүзләр безгә ят иде инде. Авылда яшьләр күп, чыгарылыш класс укучыларын кызыксындырып хуҗалыкта калдыру да уңайга булды. Эшли башлаган елымда ике белгеч эшкә килде: Галиев Рөстәм – агроном, Хәмизуллин Рөстәм – инженер. Алар үз яннарына башка белгечләрне, яшьләрне тарттылар, күңелдә бераз ышаныч, горурлык хисе туды.

1985 елның Октябрь бәйрәмендә, Колхозара төзелеш оешмасының авыл төзелеш бригадасы көче белән салынган ике катлы мәдәният йортын, тәвәккәлләп, җаваплылыкны үз өстемә алып, ачтык. Бу төзелеш бригадасы алга таба терлекчелек биналары, ике фатирлы йортлар төзеде. Колхозчылар, аерым бригадалар көче белән ике авылда да балалар бакчасы, Урта Кирмән авылында мәктәп янкормасы төзү төгәлләнде.

1987-1989 нчы елларда колхоз буенча акча кереме 3 миллион сумга якынлашса, шуның 1 миллион сумы төзелеш эшләренә тотылды. Шул елларда җылы гараж төзелде, ферма, машина-трактор паркы, амбар территорияләре бетон плитәләр белән әйләндереп алынды.

Әмма халык өчен иң кирәкле, иң четерекле мәсьәлә юл иде. Авыл урамнарында һәм Арташ авылына юл юк, язгы-көзге пычракта фермадан сөт җибәрүдәге кыенлыклар йөрәкне авырттыра. Арташ авылына юл күтәрү мәсьәләсен колхоз көче белән хәл итәргә булдык. 1987 елның җәендә 3 км озынлыктагы юл үзебезнең ДТ-75 нигезендәге 5 бульдозер белән өелде. Авыш җирләргә, «Су эррозиясенә каршы ныгытмалар ясау» дәүләт программасы кысаларында, Усали Сельхозхимиясе көче белән, юл катокланды һәм тигезләнде. Җыйнак елга һәм үзәнлекле урыннарга боҗралар урнаштырып, күперләр яса-

дык. Ходайның рәхмәте булгандыр, бу бик очсызга төште, югыйсә хәзер район җитәкчелеге әлеге эшебезгә шикләнеп караган иде. Әмма иң авыры алда иде әле – Кирмәнкә елгасы аша 20 метрлы күпер салырга кирәк!

1987 елда район башкарма комитеты җитәкчесе С.М.Исрафилов Зәй Гидромонтаж оешмасының күпер төзүчеләрен алып килеп таныштырды. Күпер салу кыйммәткә төшәчәк, чөнки ул безнең хуҗалыкка гына кирәк иде. Икенче көнне район башкарма комитеты җитәкчесе шалтыратып, акча һәм планга кертү ягыннан булыша алмыйм, үз көчегез белән генә төзегез, сездән була ул, күпкә арзангарак та төшәчәк, дип, үз фикерен белдерде. Сүз белән булса да канатландыргач, мөмкинлекләрне барлап, тәвәккәлләргә булдык. Кышкы чорда техника ремонтында эшләүче Насыйбуллин Рәис абый белән Әхмәтҗанов Рәис хуҗалыкта булган калын стеналы корыч торбалардан күпернең терәк баганаларын эретеп ябыштыра башладылар. Бу иптәшләр үзләре проектлаучы, үзләре эшләүчеләр булдылар – күперне төзеп чыктылар. Күпернең түшәмәсе имән яркалардан салынды. Халык теленә аның исеме «Рәисләр күпере» булып кереп калды.

1988 елда дәүләтнең «Хуҗалыкларга юллар төзүдә ярдәм итү» программасы гамәлгә ашырыла башлады. Хуҗалыгыбыз, Яр Чаллы шәһәрен авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итүче буларак, Чаллы шәһәренең «КамГЭСстрой» планына кертелеп, ике авылның урамнарына, алдан язып үтелгән Арташ белән Урта Кирмән арасындагы юлга вак таш түшәлде. Шул вакытта әлеге дә баягы күпердән йөге белән 30-50 тонналы автомашиналар йөрде. Күпер чыдады!

Ел саен зур күләмле төзелешләр алып барганлыктан, хуҗалык бу өлкәдә, игенчелектәге кебек, иң алдынгы була. Икмәк пешерү цехы, урта мәктәпнең өстәмә янкормасы, мәдәният йортында эчке бизәлеш һәм колхозчыларга, бигрәк тә яшьләргә торак йортлар салу юнәлешендә күп көч һәм акча тотыла. Район кулланучылар җәмгыяте белән берлектә эшләү махсус инвентарьлар табуны уңай хәл итә. Ул елларда район кулланучылар җәмгыятенең Киров исемендәге колхоз базасында кече фермалар оештырып, авыл хуҗалыгы продуктлары җитештереп, аны үзләрендә үк эшкәртеп, халыкка әзер продукт тәкъдим итүе республикада алдынгы тәҗрибә була.

1993 елда хуҗалыгыбыз республикада бөртекле-кузаклы культуралардан уңыш алу буенча икенче урынны алды. Ул елның җиңүчесе Актаныш районының «Аеш» күмәк хуҗалыгы иде. Аның рәисе – бергә укыган дустым һәм хезмәттәшем Дамир Әмин улы Җәмилев. Аның белән очрашкач: «Без Сөн елгасы буенда, тигезлектә уңыш алабыз, сез таулы-ташлы басуларда ничек эшлисез, ничек югары нәтиҗәгә ирешәсез?» – дип гаҗәпләнгән иде.

Совет хакимияте таркалу елларында халык дингә кайта башлады. 1991 елда Арташ авылында, ә 1993 елда Урта Кирмәндә, хуҗалык көче һәм халык ярдәме белән, мәчетләр төзелде. Ул елларда манарага ай табу бик авыр иде. Әлеге мәсьәләне якташыбыз, эзтабар язучы Шаһинур Мостафин Казанның «Кабан арты» мәчете имамы ярдәме белән уңай хәл итте.

***

Үземнең мисалда шуны әйтә алам: кешенең иң өлгергән, камилләшкән чоры утыз бишләрдән соң башлана. Хезмәткә дәрт, төпле фикер, халыкның тормыш фәлсәфәсен аңлап, игелекле хезмәт итү теләге шул чорда туа. Шулар тормышка ашса, син бәхетле һәм хөрмәтле буласың. ■

Безнең мирас №7 июль 2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ, Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ 80 ЯШЬ

# Сүз һәм сурәт

## Шагыйрь Гәрәй Рәхим: «Йөрәкләр турында язасы бар иде...»

Язучылар һәм җырчылар Гәрәй Рәхимнең (рәсемдә – сулдан беренче) шаян холыклы икәнен беләләр, шуңа күрә аңа еш кына: «Әй Гөргери, Гөргери, әйдә, безне көлдер, и...», – дип эндәшәләр. Ә ул ялындырмый... Уртада – җырчы Георгий Ибушев һәм каләмдәше Шаһинур Мостафин. 17 сентябрь, 1999 ел. *Мидхәт Шакирҗанов фотосы*

Фикердәшләр урманда: Гәрәй Рәхим (баскан), сулдан беренче – Разил Вәлиев, Туфан Миңнуллин һәм Фәндәс Сафиуллин

Татарстан Язучылар берлегенең шигърият остаханәсе утырышында. Рәсемдә (сулдан уңга): Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташ, … , Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов, Шәмсия Җиһангирова. 14 гыйнвар, 1985 ел. *Николай Седов фотосы*

Гәрәй Рәхим каеннар арасында

Татарстан язучылары Куйбышев (хәзер – Самара) өлкәсендә яшәп иҗат итүче яшь каләм әһелләре арасында. Икенче рәттә сулдан: Хәсән Сарьян, Гәрәй Рәхим, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Мәдинә Маликова, Мөнип Газар (Язучылар берлегенең пропаганда бүлеге мөдире), Саҗидә Сөләйманова һәм Лирон Хәмидуллин. 1960-1970 нче еллар

Калмык шагыйре Давыт Көгелтдинов Казанда кунакта. Рәсемдә: утырганнар (сулдан) – Давыт Көгелтдинов, Мөдәррис Мусин (КПСС өлкә комитетының мәдәният бүлеге мөдире), Лирон Хәмидуллин; басканнар – Шамил Маннапов һәм Гәрәй Рәхим. 1981 ел

«Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә. Гәрәй Рәхим, газетаның баш мөхәррир урынбасары Саимә Ибраһимова һәм Рөстәм Мингалим. 18 декабрь, 1967 ел

Татарстанның халык шагыйре Рөстәм Мингалим янына каләмдәш дуслары Гәрәй Рәхим һәм Ләбиб Лерон хәл белергә килгән. 13 декабрь, 2010 ел

**Редакциядән: Танылган каләмдәшебез, Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, басмабызның редколлегия әгъзасы Гәрәй Рәхимнең (Григорий Васильевич Родионовның) 15 июльдә гомер бәйрәме. Әдипне күркәм юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек, тигезлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!** ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# КАРА ТӘКЪДИР

*(Ачы язмышлы шәхесләр)*

**ЗАҺИТОВ ГАЗИ (1921-1953)**

Башкортстанның Мишкә төбәгендәге Яңакош авылында татар гаиләсендә туган.

1945 елның 30 апрелендә ул (Кантария белән Егоровтан алда), каты яраланган килеш (пуля йөрәк астыннан үтә), Рейхстаг түбәсенә Җиңү байрагын элә.

Дәвалангач, авылына кайта. 1947 елда Гази Заһитов Авыл Советы рәисе итеп билгеләнә. Аннан ул баш механик була. Техника өчен кирәк-яраклар алырга барганда сәер шартларда һәлак була.



**ИБРАҺИМОВ ГАЛИМҖАН (1887-1938)**

Татар әдибе. Уфа губернасының Эстәрлетамак өязендәге Солтанморат авылында мулла гаиләсендә туган.

1937 елның 29 августында ул Ялтадагы торак йортында кулга алына, авыр хәлендә Казанга озатыла һәм Пләтән төрмәсенә ябыла. 1938 елның 21 гыйнварында Пләтән төрмәсе хастаханәсендә вафат була.

**ИБРАҺИМОВ ВӘЛИ (1888-1928)**

Кырымтатар сәясәтчесе, дәүләт эшлеклесе, Кырым АССРның эшче-крәстиян халык комиссары (1921-1924), Кырым АССР Үзәк башкарма комитеты рәисе (1924-1928). Кырымның Бакчасарай шәһәрендә туган.

Вәли Ибраһимны, ялган шаһитлар ярдәмендә, кеше үтерүдә гаепләп, төрмәгә утырталар һәм 1928 елның 9 маенда атып үтерәләр.

---

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

**ИЛЬЯСОВ ГАЛИ (1900-1970)**

Татар режиссеры. Әстерханда туган.

Ул 1937 елда нахакка гаепләнеп кулга алына һәм 1956 елга чаклы зинданда интегә.

Улы – артист Дэллюс Ильясов (1922-1981)

**ИЛЬЯС РАХМАН (1908-1943)**

Татар язучысы. Казан губернасының Зөя өязендәге (хәзер Апас районына керә) Карамасар авылында игенче гаиләсендә туган.

Харьков тирәсендә барган сугышларның берсендә, 1943 елның 23 августында һәлак була.

**ИПЧИ ГОМӘР (1897-1955)**

Кырымтатар драматургы, театр директоры. Кырымның Бакчасарай шәһәрендә вак сәүдәгәр гаиләсендә туган.

1937 елда НКВД тарафыннан гаепсезгә кулга алына һәм аны 12 елга зинданга ябып куялар. Әмма унике елы тулгач та, Ипчине төрмәдән чыгармыйлар. Аны тагын 5 ел сөргендә тоталар, шунда чакта Сталин портретын яндырган өчен, аны психик авырулар хастаханәсенә озаталар. Ул шунда 1955 елның 11 гыйнварында вафат була.

**ИСӘНБӘТ НӘКЫЙ (1899-1992)**

Татар драматургы, шагыйрь, галим.

Ул булмаган «Җидегәнчелек»тә гаепләнеп, зинданга утыртыла. Иреккә чыккач та, байтак вакыт хакимият тарафыннан эзәрлекләнә.

*Текстны басмага* ***Рабит Батулла*** *әзерләде.* ■

# Истә, һаман да истә!

***Композитор
Рафаил Бакировның
туума 75 ел***

Композитор, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1987), ТРның (1997) һәм РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе Рафаил Мулланур улы Бакиров 1946 елның 7 июлендә Магнитогорскида туган.

Ул баян классы буенча Магнитогорскидагы 1 нче балалар музыка мәктәбен, Фирганә музыка училищесын, читтән торып Казан дәүләт консерваториясенең халык уен кораллары бүлеген (1970, Ильяс Шәрипов классы) тәмамлаган.

Р.Бакиров 100дән артык татар һәм башкорт халык җырын баян, халык уен кораллары ансамбле, оркестр өчен эшкәртә.

Кайбер китаплары: «Яшь баянчы» (ноталар китабы, 1985), «Уралда туган моңнар» (җырлар, 1992), «Яшь баянчы» (музыка мәктәбенең өлкән сыйныфларында укучы балалар өчен, 1992).

Р.Бакиров 2021 елның 30 апрелендә вафат булды.

---

***Артистка
Асия Хәйруллинаның
туума 100 ел***

Артистка, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1971), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1958) Асия Хәсән кызы Хәйруллина 1921 елның 20 июлендә Татарстан АССРның Апас районындагы Ясашно-Барышево авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, ул Спас педагогика училищесына укырга керә. Асия Хәсән кызы соңрак Мәскәүдә Дәүләт театраль сәнгать институтының (ГИТИС) актерлык факультетында укый – О.И.Пыжов, Б.А.Бибиков, М.П.Чистяков, Б.М.Седой, О.А.Якубовский кебек сәхнә осталарыннан белем ала.

1950-1971 нче елларда ул Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры труппасында эшли, төрле рольләр башкара. 1962 елдан – Казан театр училищесында, ә 1970 елдан исә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтында укыта, «Дөрес сөйләшергә өйрәнегез» исемле дәреслек яза.

А.Хәйруллина 2004 елның 4 ноябрендә вафат булды.

---

***Җырчы
Рафаэль Сәхәбиевнең
туума 70 ел***

Опера җырчысы, педагог, ТАССРның атказанган артисты (1980), ТАССРның халык артисты (1987) Рафаэль Әхәт улы Сәхәбиев 1951 елның 8 июлендә ТАССРның Түбән Кама районындагы Шәңгәлче авылында туган.

1976 елда ул Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый һәм шул ук елда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисты булып эшли башлый. 2001 елдан – доцент. 1997 елдан Казан дәүләт консерваториясенең опера классында белем бирә. Опера театрында утыздан артык роль башкара. Алар арасында Хан (Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсы), Тукай (Әнвәр Бакировның «Тукай» әсәре) һәм башка рольләр бар.

Р.Сәхәбиев 2019 елның 29 ноябрендә Казанда вафат булды.

***Рәссам Зифа Мөхәммәтҗанованың туууына 70 ел***

Рәссам-график, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1994), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исемендәге премиясе лауреаты, 1994 елдан ТР Рәссамнар берлеге әгъзасы Зифа Васил кызы Мөхәммәтҗанова 1951 елның 19 июлендә ТАССРның Биектау районындагы Бимәр авылында туган.

1973 елда ул Казан сәнгать училищесын тәмамлап, Татарстан дәүләт китап нәшриятында эшли башлый, иллюстрацияләр ясый. 1984 елдан – «Азат хатын», 1987 елдан исә «Ялкын» журналлары белән хезмәттәшлек итә. Хезмәтләре «Книжная графика Татарии» (Казан, 1981), «Большая Волга» (Чабаксар, 1985), «Советская Россия» (Мәскәү, 1985) күргәзмәләрендә катнашты.

З.Мөхәммәтҗанова 2016 елның 8 февралендә Казанда вафат булды.

***Артист Фатих Колбарисовның тууына 100 ел***

Артист, ТАССРның атказанган артисты (1968), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1958) Фатих Әкрам улы Колбарисов 1921 елның 10 июлендә Башкортстанның хәзерге Мишкә районындагы Субай авылында туган.

1937-1939 нчы елларда ул Академия театрында ярдәмчел составта эшли башлый. 1941 елда Татар дәүләт академия театры каршындагы студияне тәмамлый һәм театрдагы төп составка күчә.

Ф.Колбарисов башкарган рольләрнең кайберләре: Анжело («Анжело», В.Гюго), Качкинский («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт), Михаил («Дошманнар», М.Горький), Батырхан («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Саттаров («Чикләвек төше», Г.Ахунов), Паскуалино («Бәйрәм кичендә», Эдуард де Филиппо) һ.б.

Ф.Колбарисов 1981 елда Казанда вафат булды.

***Композитор Латыйф Хәмидинең тууына 115 ел***

Композитор, педагог, дирижер, казакъ профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе, Казакъстан ССРның халык артисты, К.Байсеитова исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Казакъстан ССРның дәүләт гимны авторы Латыйф Габделхәй улы Хәмиди 1906 елның 17 июлендә Казан губернасының Зөя өязендәге (хәзер Кайбыч районы) Бүәле авылында туган. Латыйф Габделхәй улының балачагы Үзбәкстанда уза.

Ул Солтан Габәши киңәше белән Казанга кайтып, 1922-1925 нче елларда Казан музыка училищесында (виолончель классында) белем ала.

1932 елдан Казакъстан Совет Социалистик Республикасында хезмәт итә башлый – Казакъ драма театрының музыка бүлеген җитәкли.

Л.Хәмиди 1983 елның 29 ноябрендә Алма-Ата шәһәрендә вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# «Ярмәк вагы»

Илдус Диндаров

«Ярмәк вагы» биюе

Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Иске Ярмәкне телгә алуга, иң әүвәл келт итеп күренекле шагыйрь Зыя Ярмәки, аның атаклы «Ак каен» җыры искә килеп төшә. Әйе, әйе, «Яфраклары яшел ак каенның хәтфә җәйгән төсле һәр ягы…» дигәне!

Соңгы вакытларда исә ул татар авылын «Ак каен» җыр һәм бию ансамбленнән башка күз алдына да китереп булмый. Халыкара дәрәҗәгә күтәрелгән шәрәфле исем-аты шул мәшһүр «Ак каен»ыннан алынган бит аның. Быелтыр алтын юбилеен бәйрәм иткән чын сәнгать коллективының даны-шөһрәте Советлар Союзы, бөтен Русия чикләрен үтеп чыккан. Аның барлык мактаулы исемнәрен санау гына да шактый вакытны алыр иде. Ул – Бөтенроссия «Түгәрәк уен» татар фольклоры фестивале, Идел буе халыклары фестивале һәм башка конкурсларның җиңүчесе. Һәвәскәр артистлары Оркыя һәм Наил Галимуллиннар, Диния һәм Ринат Сәгыйровлар, Әлфия Баһаветдинова, Әсгать Сәгыйров, Айгөл Галиуллина, Динар Гарипов, Гөлчирә Вәгыйзовалар башкаруындагы «Сабантуй», «Печән өмәсе», «Боз китү», «Солдатка озату», «Аулак өй» кебек зур сәнгать югарылыгында театральләштерелгән тамашалар, җырлы-биюле күренешләр залдагыларның күңелен тулысынча биләп, сокландырып кына калмый, утырган җирендә тыпырдарга, кушылып җырларга мәҗбүр итә. Халкыбызның җәүһәргә тиң йолаларын күз алдында җете, оста җанландыру галәмәте инде бу. Димәк, ансамбль үз максатына ирешә, тамашачының кайнар мәхәббәтен яулый.

Җырга-моңга искиткеч хирыс, дәртле биюләргә гаять маһир һәвәскәрләр аеруча «Ярмәк вагы» дип аталган утлы-ялкынлы биюне камилләштереп, зур осталыкка ирешкәннәр. Аны хәзер ансамбльнең визит карточкасы, бүгенгечә әйтсәк, бренды дияргә мөмкин. Үзешчәннәр коллективының җитәкчесе Наил Галимуллин әйткәнчә, еллар үткән саен чарлана, алымнары остара төшкән халыкчан бию ул.

Әле узган ел азагында гына Самара шәһәрендә Идел буе халык хорының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең берләштерелгән концертында янә тамашачыларның мәхәббәтен яуладылар әлеге атаклы бию белән. Сихәтле тәэссоратка бирелеп, рухи ләззәт алып, әсәрләнеп карыйсың аны.

«Ак каен» ансамбле

Ансамбль җитәкчесе Наил Галимуллин чираттагы иҗади бүләк белән

Кызганыч, уртак концертны алып баручылар әлеге үзешчәннәрнең шул иҗади табышын, әлеге дә баягы «Ярмәк вагы»н «Себерчә бию» дип белер-белмәс ялгыш игълан итеп, кәефне төшерделәр. Югыйсә Самара татарларының гасырлар сынавын үткән бию традицияләренә нигезләнгән «Ярмәк вагы» бит бу! Икенче төрле әйткәндә, Ирландия халкының «степ», украиннарның «гопак», русларның «яблочко», полякларның «краковяк» биюләре янәшәсендә бер үк дәрәҗәдә халыкара танылу алган бию үрнәге. Шуңа күрә күптән түгел район үзәге Камышлыга барып чыккач, Самарадагы шул күңелсез хәлгә ишарәләп:

– Башка халыклар «үзләштергәнче», «Ярмәк вагы»на тизрәк авторлык таныклыгы алырга вакыт түгелме икән сезгә, – дидем район җитәкчесенә, уенын-чынын кушып.

– Дөрестән дә, шулай итмичә булмас, ахры, – дип киң итеп елмаеп, бер үк вакытта ярмәкләр өчен горурланып, әлеге фикер белән килеште район башлыгы Рафаэль Баһаветдинов.

Рафаэль Баһаветдинов үзе дә авыл егете, күрше Чирмешән районыннан, фермердан күтәрелгән кеше. Милли җыр-биюнең кыйммәтен, асылын, тәмен-зәвыгын яхшы белә. Мәдәният дөньясындагы хәлләрдән дә хәбәрдар. Шуңа күрә дә 2020 ел азагында танылган «Ак каен»ның оешуына 50 ел тулу тантанасын истә калырлык итеп, зурлап үткәрүне ихластан хуплаган. Бөтен район белән, шартына китереп билгеләп үткәннәр ярты гасырлык юбилейны. Ата-бабалардан калган җырга-моңга, бию сәнгатенә чын мәхәббәт, халыкчан талант, иҗади зур тырыш хезмәт нәтиҗәсе шул бу. Тел белән сөйләп-аңлатып бетереп булмый аны, үз күзләрең белән күрергә кирәк «Ярмәк вагы»н! ■

# ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

*Күренекле җырчы, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Гали Ильясов. Киң диапазонлы тенор тавыш иясе. Джакомо Пуччининың «Богема»сында – Рудольф, Сергей Рахманиновның «Алеко»сында – чегән егете, Александр Бородинның «Князь Игорь»ендә – Владимир Игоревич, Александр Даргомыжскийның «Русалка»сында – Дон Карлос, Джакомо Пуччининың «Турандот»ында – принц Калаф – музыка белән бәйле шәхесләр әлеге җитди партияләрне башкару өчен нинди диапазон кирәклеген яхшы беләләр. Һәм... һәр татар белгән бихисап популяр җырлар авторы да ул... Татар иленнән меңләгән чакрым ераклыкта туып-үскән, армия хезмәтенә алынгач кына җырлый башлаган (анда да татарча түгел) Гали Ильясовның татар күңеленә сары май булырлык көйләр язуы беренче карашка сәер дә тоела. Нури Арсланов сүзләренә язылган, «яратса, яр итә белгән, вәгъдә бирсә, көтә белгән» кызлар турындагы «Татар кызы», Җәвад Тәрҗеманов сүзләренә язылган, сөйгән ярларга иң купшы багышлау булырлык «Синең өчен», бүген дә Казаныбызның гимны итеп башкарырлык, Мәхмүт Хөсәен сүзләренә иҗат ителгән «Идел вальсы», Әнгам Атнабаев шигыренә язылган легендар «Әнкәй, синең куллар»... – татар халкының «җыр генофонды» түгелмени булар?!.*

**Галинең (сулдан беренче) сабый чагы**

Гали абый Ильясов белән әниемнең әнисе Корбанбикә әбием – икебуын туганнар. Әбиемнең әнисе Мәһиҗамал – Ильяс бабайның яшь хатыныннан туган кызы, Гали абыйның (чын исеме – Әхмәтгали) атасы Миңлегани – олы хатыныннан туган улы.

Бу туганлыгыбыз турында мин студент чагымда гына белдем. Югыйсә Саба төбәгендәге Ильяс бабам нәселе яшәгән Юлбатка балачакта әбиемә ияреп ел саен бара идем. Андагы туганнар бер җәй дә калмый елкы чалалар һәм зур мәҗлес ясыйлар иде. Ничектер, сөйләшенмәгән дә, Гали абый белән очрашылмаган да, күрәсең. Хәер, Гали абыйның әтисе Гани ага Юлбаттан 14 яшендә читкә чыгып киткән, балалары да Ерак Көнчыгышта туганнар. Гали абый Казанга 60 нчы еллар уртасында гына кайткан бит. 1959 елда – Хабаровскида музыка училищесын, соңрак Мәскәү консерваториясендә Б.Беркович классын тәмамлап, 1965 елда Татар дәүләт филармониясендә солист-вокалист булып эшли башлаган.

Гали Ильясов хатыны Сания белән

Гали Ильясов күренекле дәүләт эшлеклеләре Минтимер Шәймиев, Фәрит Мөхәммәтшин, Әсгать Сәфәров белән

Гали абыйның дәүләт эшлеклеләре белән дә, коллегалары белән дә мөнәсәбәтләре яхшы булган. «Йомышы төшеп обкомга барса, аны кабул итми калмыйлар иде», – диде бер чордашы. Юлында очраган һәркем белән уртак тел табуы балаларча самимилегеннән, үзенә генә хас сөйкемлелегеннән булгандыр. Минем 80 нче еллар азагында-90 нчы еллар башында аның белән аралашканым булды. Йөзе җитди булганда да, күз читеннән бер «хыянәтче» елмаю күренеп тора иде аның. Мактаулы исемнәре дә вакытында бирелеп, шәһәр үзәгендәге фатиры да вакытында алынган, Казан артистлары арасында ул чорда еллар буе чиратта торып кына алып булган автомобиль дә иң беренче анда булмадымы икән әле, чөнки Гали абыйның ул автомобиле белән бәйле мәзәкләре дә миллион. Юл кагыйдәләрен бозгалагандыр инде, ләкин ул хакта кисәтүчеләргә: «Мастер ничек йөрисен үзе белә!» – дип кенә җибәрә торган булган ул.

Гали абыйның «музасы» – Сания апа. Гаилә көнкүрешен ул алып барганлыгы көн кебек ачык. Гомере буе ресторанда эшләгән чибәр бу ханым Гали абыйны тормыш мәшәкатьләреннән тулаем азат иткән. Аның белән бераз аралашып калдым. Олыгайгач та прическасыз, макияжсыз килеш кеше алдына чыкмады Сания апа. Янып торган матур күлмәкләр кияр, йөзеннән елмаю китмәс иде. 2016 елның ноябрендә җырчының Болак буендагы озак еллар яшәгән йорты диварында истәлек тактасы ачканнан соң (Гали абый 2000 елда вафат булды, Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнде), Сания апа безне өенә мәҗлескә чакырды. Алтын йөгертелгән кашыклар белән әллә нинди затлы ризыклар ашадык. Хәзер ризык белән кеше шаккаттырып булмый да… ләкин табынны күз камашырлык затлы итеп ул чакта аягына катлаулы операция ясатып, ике култык таягында йөргән 80 яшен тутырган ханым корган иде. Гали абыйны, аның коллегаларын, дусларын да шулай каршылап яшәгән бит инде ул. Бу ике «кояшлы» бер-берсенә тиң булганнар.

***

Үзләре турындагы мәзәкләргә сәламәт карашлы, юмор хисе булганнар шәп тә кешеләр соң! Татар дәүләт филармониясендә иң күп мәзәкләр Гали абый турында булмадымы икән әле… Минем хәтергә сеңеп калган берсе бар. Бервакыт Гали абый аягын сындырган һәм аңа Казанның травмотология хастаханәсендә катлаулы операция ясаганнар. Хастаханәдә чакта, таеп китеп, шул ук аягын тагын бер җирдән сындырган. Бу хакта белеп алган коллегалары Филармониядә, «аһ-ваһ» килеп, шул турыда озак сөйләшкәннәр. Татарстанның халык артисты, виолончелист Лариса Маслова бертуктаусыз: «Мин аңламыйм, ничек ике җирдән сындырырга була?» – дип кабатлый икән. Ничек булганын кабат-кабат аңлатканнар аңа. «Мин ничек сынганын аңлыйм, ләкин шундый кыска аякны ничек ике җирдән сындырып булганын аңламыйм!» – дигән Лариса ханым.

*Журналга* ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

*Җуелмас хәзинә*

# «Хәмдия» җыры

***«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».***

***Габдулла Тукай***

## *Хәмдия*

*(Татар халык көе, М.Фәйзи сүзләре)*

Тәрәзәләрдән ай караган,
Түшләренә мәрҗән кадаган.

Кушымта:
*Хәмдиянең ак калфагы*
*Яңа каралган чагы;*
*Хәмдиягә сүз әйтмәгез –*
*Зиһене таралган чагы.*

Яр гынай булып яралмаган,
Җаннар көйдерер өчен яралган.
*Кушымта.*

Су буйларына чыклар төшкән,
Иртә үк тә генәй суга кем төшкән?!
*Кушымта.*

Синең ләй миңа буласың юк,
Мәхәббәтем сиңа ник төшкән?!

Кушымта:
*Хәмдиянең ак калфагы*
*Яңа каралган чагы;*
*Хәмдиягә үпкәләмим –*
*Зиһене таралган чагы.*

Мирхәйдәр Фәйзи 1923 елда үзенең өченче музыкаль әсәрен – «Ак калфак» драмасын яза. Композитор Җәүдәт Фәйзи «Халык җәүһәрләре» җыентыгында: *«Кайбер иптәшләр бу драмада «Хәмдия» көенең тарихы язылган дип уйлыйлар. Бу дөрес түгел. М.Фәйзи бервакытта да әсәрләрендә көйләрнең чын тарихларын язуны максат итеп куймаган. Көйләр аның әсәрләренә музыкальлекне көчәйтер өчен зарури компонент буларак кергәннәр»,* – ди.

Хәмдия – «Ак калфак» драмасының героинясе. Ул – аксөяк мирзаның иркә һәм чибәр кызы. Хәмдия үзенә атап җыр чыгаруларын тели:

– Аһ, «Тәфтиләү»ләр, «Ашказар»лар, «Мәдинәкәй»ләр кебек минем дә үз көем булса!.. Мин исемемә көй чыгаручы егетне мәңге иркәләр идем. Аһ, никадәр телим үз атыма бер көй булуын, – ди.

Җыр чыгаручы кем генә булса да, ничә яшьтә булса да, аңа кияүгә чыгарга вәгъдә бирә. Күңеле белән җырны күзе төшеп йөргән мирза улы Шаһтимер чыгарыр дип уйлый. Ләкин җырны көтүче егет Бакый чыгара.

**Драматург Мирхәйдәр Фәйзи. Орск, 1910 ел**

Көтүчене түбән катлау дип санаган аксөяк кыз, бу җырны ишеткәч, гарьләнә. Шундый гүзәл җырны гади көтүче егет чыгарганга ышанасы да килми. Бакыйдан көнләшеп йөргән Шаһтимер көтүче егетне пычак белән чәнчеп үтерә. Бакыйның үлгәнен күргәч, кыз акылыннан язар хәлгә килә. Аның мәхәббәтен кабул итәргә әзер була инде ул. Әмма... «Ак калфак»та да, «Галиябану»дагы кебек, мәхәббәт язмышы аянычлы тәмамлана.

Драма сәхнәгә куелганга кадәр «Хәмдия» исемен йөрткән җыр булмаган. «Ак калфак»тагы «Хәмдия» көе халыкка күптән билгеле булган «Шакир солдат» көенең бераз үзгәртелгән варианты икән.

Композитор Җ.Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» китабыннан бер өзек: *«Карт музыкант Мөхәммәт Яушевның әйтүенә караганда, «Шакир солдат» революциягә кадәр төрле инструментларда уйнала торган көй булган. Аны «Сәйяр» драма труппасы каршындагы милли оркестр да еш башкарган. 1924 елда Казанда «Ак калфак» драмасы сәхнәдә куелганда, Бакый белән Хәмдия мәхәббәтләре әнә шул «Шакир солдат» көенә җырланган икән. Соңыннан гына ул «Хәмдия» исеме белән йөри башлаган».*

«Шакир солдат» җыры егерменче елларда «Талга басып» исеме белән дә билгеле була.

*Талга басып, тал тибрәтеп,*
*Сайрый сары сандугач.*
*Җырлау түгел, җыларсың да,*
*Өзелеп-өзелеп сагынгач,* –

дигән кушымта белән җырлаганга аны шулай атаганнар булса кирәк.

Әлеге җыр Илһам Шакиров, Рафаэль Ильясов, Салават Фәтхетдинов, Идрис Газиев, Азат Нургалиев, Мубай һ.б. репертуарында (текст һәр җырчыда беркадәр үзгә) бар.

Тәртип радиосы

***(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.)*** ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# Көлке куа килә...

## Туфан Миңнуллин (1935-2012)

**Туфан Миңнуллин.**
***Н.Хаҗиәхмәт шаржы***

### Психологик хикәя

Түбән оч Зиннәт сугыштан кайтты. Күрше хатыны Зәйнәп аның хәлен белергә керде. Сугыш турында, сугышка Зиннәт белән бергә киткән ире хакында сорашты. Зиннәт үзе аз сүзле кеше булганга, аның өчен күбрәк хатыны Мәфтуха сөйләде.

Зәйнәп Зиннәтләрдән чыгып барганда, аңа икенче бер күрше хатыны очрады.

– Ничек соң, Зиннәтниләр сөйләде? – дип сорады.

– Зиннәт түгел, Мәфтухасы кайткан сугыштан, ул бөтенесен сөйләп бирде, – диде Зәйнәп.

## Камил Камал (1963-2001)

### Көнләшү

«Яратмыйсың, сөймисең, – дип
Битәрли беркөн кичен, –
Башкаларны иркәлисең,
Ә мин кем синең өчен?»

Битәрләсә битәрләсен,
Селтәдем кулым гына.
Ул бит минем хатын түгел...
Ул – минем улым гына.

*1995*

## Кашаф Кәрим

### Мәкаль

Полковник Лопатин солдат казармасына керүгә, кулына ак кулъяулык алып, бүлмә җиһазын сөртеп карый.

– Рядовой, нишләп тумбочкаларыгыз пычрак? – дип сорый ул дневальныйдан. – Йә, әйтегез әле, бу шакшылык турында нинди мәкаль бар, исегезгә төшерегез әле.

– «Дуңгыз шакшыны үзе табар» дигән мәкаль искә төште, иптәш полковник.

*1992*

## Илдус Гыйләҗев (1946-2018)

### Кычытканны сагыну

Оят җирне капламыйча
Йөрсәң «борчак пешереп»,
Каезлыйлар иде элек
Ыштаныңны төшереп.

Концерт карыйм. Мир каршына
Купме шәрә кыз чыккан.
Әттәтәгә биетергә
Юкмыни соң... кычыткан?!

**Илдус Гыйләҗев.**
***Н.Хаҗиәхмәт шаржы***

***Рафаэль Сәхәбиевнең (1951-2019) тууына 70 ел***
***Мәшһүр артист турында ике мәзәк***

## Рәдиф Сәгъди

### Арада бер син бар...

Яшь җырчы Рафаэль Сәхәбиев белән карт җырчы Усман Әлмиев башкаланың Бауман урамында очрашкан.

– Карале, энем, беркөнне концертыгызны карадым... – дигән Усман Әлмиев.

– Ничек соң, концерт ошадымы? – дип сораган яшь җырчы.

– Бик начар, энем. Арада бер син бар... – Карт җырчы пауза ясап ала.

Рафаэль үсенеп киткәндәй була.

– ... син дә бик начар... – дип тәмамлый сүзен Усман Әлмиев.

### Сөйләшәсең бит әле...

Язучылар берлегендә ел әйләнәсендә иҗат кичәләре бик еш булып тора. Хәбир Ибраһимга язучы булуы гына җитмәгән, җырларга да ярата икән. Бер мәҗлестә «Ак калфакның табылган чагы» дигән затлы җырны башкарып, тәки ахырына кадәр җиткерә бу. Әллә үз итеп, әллә күңеле төшмәсен, дип, тыңлаучылар гөрләтеп кул чаба моңа. Үзеннән бик канәгать калган Борнаш малае Хәбир, тагы да мактанасы, тагы да мактау сүзләре ишетәсе килепме, опера җырчысы Рафаэль Сәхәбиев тирәсенә елыша да:

– Ничек соң, Рафаэль туган, тавышым бармы минем? – дип сорый.

– Нишләп булмасын тавышың, сөйләшәсең бит әле! – дип җавап бирә аңа мәшһүр җырчы.

*Сәхифәне* ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2021

# *Без барыбыз да – балачактан*

*«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!*

## Әхсән Баян (1928-2013)

### Малай чакта төшкән сурәт

Сәрвиназ, үзенең ике яшь туларга ике ай калган чакта төшкән сурәтен карагач, әйтте:

– Бу карточканы мин малай булганда төшергәннәр, – диде.

Сурәттә аның чәче малайларныкы төсле кыска иде.

### Киселгән болыт

Һавада самолет калдырган ак тасмага карап, Сәрвиназ:

– Дәү әни, кара, болытны кискәннәр! – диде.

## Нияз Акмал (1954-2007)

### Киләләр дә...

Киләләр дә гел әйтәләр:
– Әнисенә охшаган!
Күрәләр дә гел әйтәләр:
– Әтисенә охшаган!

Нәрсә генә әйтсәләр дә,
Һәммәсенә ышанам:
Әнигә дә охшаган мин,
Әтигә дә охшаган!

### Чи чия чәйни-чәйни

*(Тел көрмәкләндергеч)*

«Чак-чак кына чирдән терелеп чыккан чакта чияле тау читенә чыгып чи чияне чәйни-чәйни чигәләрем чатнап чыкты» дигән чакта ничә «ч» бар? Чутлап чык.

### Бозау оек бәйли

*(Такмак)*

Безнең песи бигрәк уңган,
Комганга су тутыра.
Бозавыбыз мич башында
Оек бәйләп утыра.

### Табышмак әйтәм – җавабын тап

Сыер нигә ята?
*Җавап: Утыра алмаганга.*

***

Каз судан чыккач нишли?
*Җавап: Коры җиргә баса.*

***

Ат нигә улак янына бара?
*Җавап: Улак үзе килмәгәнгә.*

## Мөдәррис Әгъләмов (1946-2006)

### Бишек җыры

Кояш инде тәгәрәп
Төште таулар артына:
Әлли-бәлли-бәү, диеп,
Әнә, Чулпан яктыра –
Әлли-бәлли-бәү, диеп...

Дәү әниең эләргә
Биләүләрен чайкады.
Әлли-бәлли- бәү, диеп
Тәрәзәдән ай карый –
Әлли-бәлли-бәү, диеп...

Дәү әтиең шым гына
Йөри аяк очында...
Әлли-бәлли-бәү, диеп
Көйлимен баш очында –
Әлли-бәлли-бәү, диеп...
Урамдагы йортлар да,
Тәрәзәдә утлар да,
Әлли-бәлли-бәү, диеп
Чакыралар йокларга,
Әлли-бәлли-бәү, диеп.

Әлли-бәлли, йокла тыныч,
Әлли-бәлли, уян көнем;
Әттәңне дә сөендереп,
Әннәңне дә сөендереп,
Уян көлеп,
Әлли-бәлли-бәү... бәү... бәү...

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

# ИЮНЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында




● Тарих фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Индус Разак улы Таһировның «На пути к истине» дигән яңа китабы дөнья күрде.

● 1-3 июнь көннәрендә «Мәдәни җомга» газетасы һәм «Безнең мирас» белән «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре, шулай ук «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, галим Ленар Гобәйдуллин Башкортстанның Дүртөйле, Борай, Балтач, Тәтешле һәм Яңавыл районнарына сәфәрдә булды. Сәфәр вакытында алар, район һәм мәктәп китапханәләрендә, мәчетләрдә, мәшһүрләребез Ш.Бабич, Н.Нәҗми, Батырша, Г.Чокрый, Ә.Атнабай, И.Юзеев, С.Сөләйманова, Н.Фәттахның туган авылларында, күренекле шәхесләребезгә нисбәтле музейларда булып, халык белән очрашты.

● 11 июньдә ТР Дәүләт Советы бинасында Татарстан Президенты сайлануга 30 ел (12 июнь, 1991) тулу уңаеннан фотокүргәзмә ачылды. 1991-1992 нче елларда төшерелгән тарихи фотоларны Татарстанның Беренче Президенты, ТРның Дәүләт Киңәшчесе М.Ш.Шәймиев ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов һәм ТР Дәүләт Советы рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин белән бергәләп карады.

● 13 июньдә Тәтеш районының Зур Әтрәч авылында «Әтрәч укулары» булып үтте. Республикабызның дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит Мифтахов, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, «Безнең мирас» журналы баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Тәтеш муниципаль район хакимияте башлыгы Рәмис Сафиуллин, «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы вәкилләре һәм авыл халкы катнашында узган әлеге чараны Тәтеш районы имам-мөхтәсибе Инсаф хәзрәт Җәләлетдинов ачты. Чарада катнашучылар зур Әтрәч авылындагы укуларны рәсмиләштерүгә күп көч куйган Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин рухына да дога кылды.

● Түбәндә уздырылган Бөтенроссия «Ел гаиләсе» бәйгесенең «Авыл гаиләсе»

номинациясендә Төмән өлкәсенең «Хиләл» мөселман яшьләре берләшмәсе әгъзасы, җәмәгать эшлеклесе Раил Бәширов гаиләсе җиңде.

● 16 июньдә «Әдәби кафе»да («Татмедиа», Декабристлар урамы, 2) Республиканың М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрь Ләбиб Леронның «Мәхәббәтнең канат җиле» дигән яңа китабын тәкъдим итү чарасы үтте. Анда әдипнең каләмдәшләре һәм дуслары Р.Батулла, З.Мансуров, Р.Вәлиев, М.Галиев, Т.Галиуллин, Р.Зәйдулла, Г.Морат, Ә.Мушинский, А.Хәмзин, Р.Садриев, А.Тимершаех, Г.Булатова, Й.Шәрәпова катнашты һәм чыгыш ясады. Чараны шагыйрьнең кызы, «Тәртип» радиосы хезмәткәре Айсылу Лерон алып барды.

● 18 июньдә Мамадышта генерал-лейтенант Н.П.Афанасьевка (1902-1979, 1946-1950 нче елларда СССР Хәрби кочләренең баш хәрби прокуроры һәм СССР генераль прокуроры урынбасары вазыйфаларын башкара) бюст ачу тантанасы булды. Чарада ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов, Мамадыш районы хакимияте башлыгы А.П.Иванов, Н.П.Афанасьевның оныгы Т.Соколова, скульптор А.Чебаненко, Татарстанның халык язучысы М.Галиев, Халыкара Х.Г.Андерсен премиясе лауреаты, язучы Р.Газизов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон һ.б. катнашты.

● 19 июньдә Брест крепостеның легендар сакчысы – Советлар Союзы Герое Петр Гавриловның туган авылы Әлбәдендә (Питрәч) «Әлбәден хәрби уеннары» фестивале ачылды. Фестиваль барышында халык игътибарына Бөек Ватан сугышы вакыйгалары реконструкциясе тәкъдим ителде. Бирелә махсус декорацияләр – Брест крепостеның Көнчыгыш форты, Гаврилов капониры һәм Кобрин капкалары, окоплар һәм блиндажлар күчермәләре төзелгән иде.

● 20 июньдә Апаста XIII Республикакүләм театраль Сабантуй булып узды. Театр әһелләре катнашында үткән әлеге чарада бертөркем татар язучылары да катнашты.

● Июньдә Казанның «Халкыбыз мирасы» нәшриятында татар милләтенә һәм татар теленә нисбәтле яңа җыентык – «Үз җиремдә – үз телем» дигән китап басылып чыкты. Басманың проект авторлары – Рөстәм Сәрвәров һәм Рөстәм Җамалиев, мөхәррире – Рәшит Минһаж, бизәлеш мөхәррире – Азат Яшәр, корректоры – Фирая Маликова. ■

# МИРАСВОРД

Агач гөмбәсе, ку

Хөсрәүнең сөйгәне

Тавыш (иск.)

Язучы ... Фәләх

Татарстандагы район

Шумер-аккад мифологиясендә – кояш Алласы

Борынгы сугыш коралы

Мәҗит ...

... карагы

Мәшһүр тегү машинасы маркасы

Киләсе ел (диал.)

Урта Азиядә: идарәче

Мөселманнарда өлкән рухани

... Сәхәбетдинов (көрәшче, тренер)

Борынгы Рим мәсәлчесе

Френкель, Сибелиус

... Сараи

1908 елда Казанда чыккан татарча педагогик журнал

Сәдака

Агач чиләк (диал.)

Җәяр өчен әзерләп куелган түгәрәк камыр

Оят, намус (иск.)

1908-1909 нчы елларда Казанда чыккан юмор-сатира журналы

Чәй чынаягы, касә (иск.)

Тәүфикъ ...

«... чәчәге» (Мөхәммәт Мәһдиев)

Игътибар, әһәмият (иск.)

... Сакаева

Шагыйрь Ямаш ...

Ги ... Мопассан

Әмирхан Еникинең һөнәре

Грек хәрефе

«Көмеш ... тулпар атым» (җыр)

... Вахит

Тәбәнәк, кыска (диал.)

Цирк клоуны (иск.)

Актер Ричард ...

Аудару

Грузия каласы

Озын кунычлы милли аяк киеме

...-ера

Тыгыз киҗе-мамык тукыма



**6 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:**
**Сулдан уңга:** Дәүләт, «Ра», Рөстәм, уа, Туфан, «Каиб», мари, киле, Магас, Яков, Анри, «Ваем», фрак, Гобәйди, ар, алап, Нур, Мостафин, Агиш, угыз, Нодар, ыра, да, Олуг, Гаяз.
**Өстән аска:** Мәргән, ука, «Ургыл», Гамбәр, ыру, Дәрзаман, Гази, Насрый, Үрсу, дао, Латакия, филс, атан, Тимбикова, пагода, бивак, «Фидая», афиша, телмәр.

*Рәис Габдулла төзеде.*

# «Безнең мирас»
## елъязмасы / июль

Абдулла Алиш музее. Болгар

**770 ел элек (1251)**

Каракорым каласында җыелган корылтайда Чыңгыз хан оныгы Мөнке бөтен империянең төп ханы – каһан итеп сайлана һәм тәхеткә утыра.

**500 ел элек (1521)**

Халык Казанда Ширгали (Шәехгали) ханга каршы баш күтәрә. Ханны төшереп, аның урынына Сәедгәрәй (Сәхибгәрәй) ханны куялар.

**245 ел элек (1776)**

Күренекле сәяхәтче-галим Ив.Ив. Георгиның «Россия дәүләтендә яшәүче барлык халыкларның тасвирламасы» дигән китабы дөнья күрә. Китапта татарлар турында да гаять бай мәгълүмат тупланган.

**110 ел элек (1911)**

Баку шәһәрендә Хаҗи Ибраһим Касыйм мөхәррирлегендә «Мәгълүмат» дип аталган газета нәшер ителә башлый. Әмма берничә саны дөнья күргәч, исламчылык фикерләре тарата, дигән сылтау белән, басманы чыгару тыела.

**95 ел элек (1926)**

Июль ае башында Гадел Кутуй, татар шахтерларының хезмәте вә тормыш-көнкүреше белән танышу өчен, Донбасс якларына сәфәргә чыга.

**80 ел элек (1941)**

13 июльдә Муса Җәлил белән Абдулла Алиш армиягә алына.

**30 ел элек (1991)**

Чаллы каласында «Мирас» фондының шәһәр бүлеге ачыла. Аның төбәк шурасына фольклорчы галим Фатих Урманчеев белән публицист язучы Фаяз Дунай сайлана.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

## Содержание. Июль 2021

**И останется в мире слово моё...:** Шаехзада Бабич.

**Историческое наследие:** «Янаул (Ирнур) – татарская деревня в Республике Марий-Эл». Ф.Мусин; «Татарская лодка». Н.Гариф; «Кто он Тогайка Беляков?». Р.Марданов.

**Татарский мир:** «Узник любви». Ш.Бабич; «Настоящий народный поэт». Р.Шарафиева.

**Религиозное наследие:** «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Ризаэддин Фахруддин о развитии нации». Л.Байбулатова.

**Литературное наследие:** «Стихи Ахмада Лябиб Каран (1887-1964)».

**В глубинах памяти:** «Знаменитые председатели Мамадыша». Р.Хайруллин; «В памяти, до сих пор в памяти!».

**Художественное наследие:** «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

## Алхәбәр:

**«Болгарга сәяхәт. Язучы Тәүфыйк Әйди завод яшьләрен оештырып алып барган иде. 30лап кеше басуда кунып, арып-талып, белем алып кайттык». Рәсемдә уртада – Нурихан Фәттах һәм аның хатыны Руфинә Фәттахова. 19 июнь, 1966 ел. («Нурихан Фәттах көндәлегеннән». *Р.Фәттахова*)**

- **Себер сүзе.**
  **Фәүзия Бәйрәмова**
- **Әдип абый – әдәп үрнәге.**
  **Эльмира Шәрифуллина**
- **Нурихан Фәттах көндәлегеннән.**
  **Руфинә Фәттахова**
- **«Аркаим»га сәяхәт.**
  **Лирон Хәмидуллин**

# *Әсән авылы — фотоларда*

**Ш.Бабич музеенда. Баш мөхәррирләр – Ләбиб Лерон, Вахит Имамов, Рөстәм Галиуллин һәм музей җитәкчесе Миләүшә Әсләмова**

**Ш.Бабич исемендәге урта мәктәп**




**Татар шагыйре Шәехзадә Бабичның туган авылы – Башкортстан Республикасының Дүртөйле районындагы Әсән күренешләре**

**Ш.Бабич туган нигез янында әдәби парк**

**Ш.Бабичның туганнары. Алда утырганнар: Фәтхелкадыйр гаиләсе белән. Артта басканнар: Нәҗибә, Фәсәхәт һәм Рәфига Бабичевалар**

# ПИТРАУ

*Мамадыш районының Җөри авылындагы Питрау мизгелләре. 2019 ел. Рамил Гали фотолары*

**ИНДЕКС:**
**ТАТАРСТАНДА – П2343**
**РОССИЯДӘ – П7074**
**beznenmiras.ru**

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»***
***журналына башкача язылу:***

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»*** журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.